Безнен МИРАС

06
июнь 2018

ФӘННИ-ПОПУЛЯР, ӘДӘБИ-НӘФИС һӘМ ДОКУМЕНТАЛЬ ЖУРНАЛ

ШАМИЛ ШӘЙДУЛЛИН. «ТУГАН АВЫЛЫМДА САБАН ТУЕ».

«ҮЛЕМСЕЗ ПОЛК»

9 май көнне Казан шәһәрендә узган «Үлемсез полк» урам йөрешенә Татарстан Республикасы Президенты Рөстәм Миңнеханов, Татарстан Дәүләт Киңәшчесе Минтимер Шәймиев, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин, Татарстан Республикасы Премьер-министры Алексей Песошин, республика министрлыклары һәм ведомстволары җитәкчеләре, төрле иҗтимагый оешмалар вәкилләре һәм гражданнар да актив катнашты.

Каләм! Кальбеңдә ни сер бар – гаян ит,
Килеп кичмешләр әхвален бәян ит.

Дәрдемәнд

Безнең МИРАС 12 +

06 (294)

июнь 2018

1991 елның апреленнән башлап «Мирас», 2012 елның маеннан, «ТАТМЕДИА» АҖ тарафыннан кабат гамәлгә куелып, «Чын мирас» исемнәре белән чыкты. 2014 елның маеннан «Безнең мирас» итеп үзгәртелде.

92

ЭЧТӘЛЕК



56 *Иршад Гафаров* «CODEX CUMANIKUS» – ТӨРКИ МИРАС.



68 *Рухия Ахунҗанова* АЛТЫНГА ТИҢ КИҢӘШЛӘР

ДӨНЬЯДА СҮЗЕМ КАЛЫР...

3 **Фәннур Сафин**

ТАРИХИ МИРАС

4 **Нурсолтан.** *О.Иванова*
8 **Татарлар алгарыш юлында.** *И.Таһиров*
15 **Шыгырдан таңы.** *П.Салихов*
20 **«Хатын-кызның күрке – яулык».** *Т.Шәйхнурова*
24 **Мансур авылы**
26 **Кулаткы суфилары.** *И.Сафин*
30 **Татарстанда вакытлы матбугат.** *Г.Рәхим*

ТАТАР ГАМЕ

35 **Безнең заман каһарманы.** *Р.Батулла*
42 **Карантау итәгендә.** *Р.Сәгъди*
47 **Галимҗан Ибраһимов туганы.** *Ф.Фәтхи*
50 **Өч армия, максат – бер.** *Ә.Сафуанов*

ТӨРКИ ДӨНЬЯ

54 **Үзбәк халкының сөекле шагыйре**
56 **«Codex cumanikus» – төрки мирас.** *И.Гафаров*

ДИНИ МИРАС

60 **Ислам дөньясы.** *Г.Ибраһимов*

ӘДӘБИ МИРАС

64 **Аяз Гыйләҗев һәм мин.** *Ф.Кутлу*
68 **Алтынга тиң киңәшләр.** *Р.Ахунҗанова*
72 **Сандугач.** *Г.Галиев*
77 **Олпат галим.** *Р.Ганиева*
78 **Абай.** *З.Рәмиев*

ОЧТЫ ДӨНЬЯ ЧИТЛЕГЕННӘН...

80 **Җамал Вәлиди**
84 **Җ.Вәлиди турында.** *Х.Гали*

Баш мөхәррир
Лемон Лерон улы ЛЕРОНОВ
(Ләбиб Лерон)
(843) 222-09-83 (17-91)

Баш мөхәррир урынбасары
Ленар Гобәйдуллин
(843) 222-09-83 (17-91)

Киңәшче идарә
Ирада Әюпова
(ТРның мәдәният министры)
Разил Вәлиев
(ТР Дәүләт Советының Мәгариф, мәдәният, фән һәм милли мәсьәләләр комитеты рәисе)
Илдар Гыйльметдинов
(Татар федераль милли-мәдәни автономиясе Советы рәисе)
Айрат Зарипов
(Матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр буенча Республика агентлыгы җитәкчесе)
Андрей Кузьмин
(«ТАТМЕДИА» АҖ генераль директоры)
Рөстәм Мөхәммәдиев
(«Татнефть» ААҖ генераль директоры урынбасары, «Рухият» фонды рәисе)
Васил Шәйхразиев
(ТР премьер-министры урынбасары, БТК Милли Шурасы рәисе)
Лотфулла Шәфигуллин
(«ТАТТЕЛЕКОМ» АҖ генераль директоры)

Редколлегия
Ислам Әхмәтҗанов
Марсель Әхмәтҗанов
Альберт Борһанов
Рәдиф Җамалетдинов
Фәнзилә Җәүһәрова
Ринат Закиров
Фәйзелхак Ислаев
Зиннур Мансуров
Ким Миңнуллин
Гөлчәчәк Нәҗипова
Данил Салихов
Сөмбел Таишева
Рафаил Хәкимов
Ирек Шәрипов

Җаваплы мөхәррир
Фирдәвес Зарифуллин
(843) 222-09-83 (17-93)

Бүлек мөхәррир
Ләйсән Данилова
(843) 222-09-83 (17-92)

Дизайнер һәм биткә салучы
Диләрә Нәүрүзова
(843) 222-09-83 (17-93)

Корректор
Дания Фәйзуллина
(843) 222-09-83 (17-92)

Гомуми мәсьәләләр буенча мөхәррир
Рәдиф Сәгъдиев
(843) 222-09-83 (17-91)

Редакция һәм нәшрият адресы:
420066, Казан шәһәре,
Декабристлар урамы, 2 нче йорт
Электрон почта:
yanamiras@mail.ru

«Наше наследие»
Ежемесячный научно-популярный, литературно-художественный журнал (на татарском языке)

ХӘТЕР САНДЫГЫ

86 **Истә, һаман да истә!**

СӘНГАТИ МИРАС

88 **Әз-мәз үзем турында.** *Р.Шәрәфи*
92 **Рәшит Ваһапов ядкәрләре**

ТЕЛ КҮРКЕ – СҮЗ

98 **Миллият сүзлеге.** *А.Тимергалин*

ХӘТЕР САГЫНДА

100 **Татарстан Республикасының Милли китапханәсе**
104 **Гаилә-нәсел мохитендә символлар һәм тамгалар теле.** *Ф.Нәбиуллин*
110 **«Совет мәйданы» – тарихыбызның өч чоры**
112 **Киез итекләр иле**

116 **«Безнең мирас» хәбәрләре**
118 **Мирасворд**
119 **«Безнең мирас» елъязмасы.** *Июнь*

Заказ №Е-1273. Тираж – 2180 данә. Формат 70 X 108 1/16
Басарга кул куелды: 24.05.2018
Журнал айга бер тапкыр чыга. Бәясе ирекле.

Журнал 2012 елның 17 апрелендә Федераль элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсендә ПИ №ФС77-57844 нче таныклык белән теркәлде.

Чыганак-текстларда авторларның стиле, шул чор лексикасы һәм орфографиясе саклана.
Мәкалә авторларының фикере редакция фикере белән туры килмәскә дә мөмкин. Редакциягә юлланган язмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый. Материаллар бары тик электрон вариантта гына кабул ителә. Журналга кергән язмаларны редакция рөхсәтеннән башка күчереп бастыру тыела. Типография гаебе белән киткән хаталар өчен редакция җавап бирми. Андый хаталар булса, техник контроль бүлегенә 519-44-61 телефоны белән хәбәр итә аласыз.

Бу санда Л.Гобәйдуллин, Л.Лерон төшергән, авторлардан һәм Татарстан Милли музееннан, «Татар энциклопедиясе» томнарыннан алынган фотосурәтләр, җиде томлык «Татар тарихы»ннан рәсемнәр файдаланылды.

«ТАТМЕДИА» акционерлык җәмгыятенең «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды. Адресы: 420066, Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 2 нче йорт.

Тышлыкның 1 нче битендә – «Туган авылымда Сабан туе».
Шамил Шәйдуллин рәсеме

Безнең мирас №6 июнь 2018



Фәннур Сафин

(27.06.1948 – 31.12.1992)

Егетлекне сынау өчен...

Куркыныч ул кайчак дөнья:
Кара төндә кем күрер? –
Ялгызакны талыйм, диеп,
Эт өрер, бүре йөрер.

Өстеңә бүре килгәндә,
Араларга кем керер?
Ялгызакны талыйм, диеп,
Эт өрер, бүре йөрер.

А, юк! Араларбыз!
Егет кеше
Һәммәсенә өлгерер.
Егетлекне сынау өчен,
Эт өрер, бүре йөрер...
Эт өрер, бүре йөрер... ■

НУРСОЛТАН

Ольга Иванова

– Әгәр хуҗам миңа үз фикеремне белдерергә рөхсәт итсә... – дип, Нурсолтан, инде ишек тоткасына ябышкан көе, әкрен тавыш белән әйтеп куйды.

– Сөйлә, – диде Мәхмүд хан, аның ягына башын бормыйча гына.

– Кол хатыннарны ерак биләмәләргә озатып торуыгызны үтенер идем. Ул чакта аларның эчендә күпереп яткан яла-гайбәтләрдән безне дошман күрүчеләр файдалана алмас иде, хуҗам. Һәм тагын, кодрәтле хан, барысын да түкми-чәчми иремә сөйләргә рөхсәт итсәгез икән. Хәлил солтанга мин дөреслекне ачарга телим, чөнки, үз вакытында Сәрби ханым белән килешү сүзләре таба алмавымнан тыш, минем бер гаебем дә юк.

– Ләкин бу мөмкин түгел, Нурсолтан, син үзеңә-үзең каршы киләсең!

– Юк, хуҗам! Минем бары тик явызлык һәм мәкер белән тулы теләсә нинди кайтавазларны алдан кисәтеп-кисеп куясым килә. Хәлил солтанның язмыш ору-кагуларына, шул җөмләдән яла һәм ялганга каршы тора алуын телим! Улыгызга Казан Иле хакиме булырга язган икән, ул гомер буена безнең аркабызга ышыкланып яши алмаячак. Ышаныгыз, аның күңеле кителмәсен өчен барысын да эшләрмен. Ирем мине аңлар һәм ул чакта, җыен көнче-дошман бәндәләрнең сүзләре аңа килеп ирешүгә үк, зур бер ялган өрәгенә әверелер, Хәлил аны күңеле белән дә, акылы белән дә кабул итмәячәк...

Ахыры. Башы журналның 1 нче (2018) санында.

Нурсолтан әле һаман, ханның соңгы карарын көтеп, башын игән килеш басып тора. Ниһаять, хан телгә килде:

– Яхшы, ризамын, бу эштә тулысынча сиңа ышанам, Нурсолтан. Ә хәзер бар, Хәлилең көтеп зарыккандыр.

Яшь хатын артыннан ишек ябылгач та, Мәхмүд хан үзенең тугрылыклы киңәшчесенә йөзен борды:

– Бу балага сокланып туя алмыйм! Күрдеңме, никадәр кыюлык, акыл һәм исәпле эш йөртү осталыгы, ә бит аңа әле нибары уналты яшь кенә! Ә ун, егерме елдан соң нинди акыл-зиһен хәзинәсе ачылыр?

– Сезнең белән килешәм, хакимем. – Шептәк бәк карт Мәхмүд алдында башын иде. – Хәлил солтан бу хатын белән бөек хан була алачак!

***

Ибраһим солтан инде җиденче ай хан даругаларын тәфтишләп-тикшереп йөри, ә атасы һаман аны пайтәхеткә чакырып алырга ашыкмый. Хан кушмыйча, Казанга кайтырга хокукы булмаганга, Ибраһимның җен ачулары чыга. Ә бит шул арада башкалада ул озак еллар көткән вакыйга булуы ихтимал! Хәтта иң ерак шәһәрчекләрдә дә җирле бәкләр һәм морзалар, карт хан бик каты хаста икән, сарай кешеләре дә аны берничә көн күргәннәре юк, имеш, дип сөйләнәләр. Ибраһим атасы үлгән вакытта Казанда булуның никадәр мөһим икәнлеген аңлый. Шулчакта гына ул уңышка исәп тота ала, шулчакта гына Хан бүреген үз башына кию мөмкинлеге туачак. Әгәр ул башкалага карачылар үзләренең ханы итеп Хәлил солтанны танып өлгергәч кенә кайта алса, кануни хаким белән көрәшү күпкә катлаулырак булачак. Мондый көрәштә башыңны югалту да бик җиңел, ә Ибраһим үз гомеренең кадерен белә, бик белә. Атасының үҗәт холкын йомшартырга теләп, Ибраһим Алатыр, Чалым һәм үзе булган башка төбәкләрдән озын-озын хисап хатлары яза, ахырдан бер үк үтенечен кабатларга онытмый: хатыным, балаларым белән күрешү өчен, Казанга кайтып килергә рөхсәт итсәңче, дип сорый. Әмма Ибраһимның тыштан күренеп торган күндәмлеге дә, түбәнчелек белән үтенүләре дә Мәхмүд ханның күңелен йомшартып, кече улын башкаладан ераграк тотарга карар кылуын үзгәртерә алмый.

Эшсезлектән интеккән солтанга көз башында Казаннан, мордва кенәзләре идарәсендә булган Мукшы шәһәрчегенә барырга, дигән әмер килде. Ибраһим, теләмичә генә, ханлыкның төньяк чигенә юл алды. Мукшыда аны лыҗырдык көз һәм «ни арба, ни чана» дигән юл өзеклеге каршы алды, шунда ул өч айга тоткарланып калды. Ибраһим солтан бу күрексез, күңелсез якны каһәрләде, үзенең түшәмгә төкереп ятуына эче пошты. Әлеге шартларда аның көн саен көрәш эчендә кайнап, яңадан-яңа мәкерле ятьмәләр үреп шомарган акылы да тупаслана, мүкләнә башлаган кебек иде.

Кышкы юллар төшү белән, солтан, атын иярләп, әнисе Камал бикә яшәп яткан Акташ биләмәсенә чапты. Мукшыдан Казан хакимлегенә баш игән чуашлар бишеге Акташка кадәр ике көнлек кенә юл. Киң болыннар белән уратып алынган, төрле телләрдә сөйләшеп-аңлашып яшәүче ике авылы булган бу биләмәне хан кайчандыр икенче хатынына бүләк итеп биргән иде. Берара Камал бикә иренең шундый юмарт бүләге белән мактанып йөрде әле, тик озак та үтми, Акташның шул биләмә чикләреннән кая да булса чыгу катгый тыелган сөрген урыны икәнлеге аңлашылды. Мәхмүд хан ханбикәне, бердәнбер улы Ибраһимга, өлкән агасы Хәлилне читкә этәреп, Казан тәхетен алып бирү теләге белән янганы өчен, шулай акылга утыртмакчы иде. Әмма бу җәза борынын бик югары чөйгән бикәне барыбер җиргә төшерә алмады. Унике яшендә анасыннан аерыл-

ган Ибраһим солтанны Акташтан килгәләгән хатлар котыртып торды. Мәкер-хәйләдә азу ярган Камал бикә хатларын ике юл белән җибәрә иде. Берәүләре яшь солтан кулына ханның гадәти хат алышу хезмәте аша керә, – боларында, имештер, малаеның саулыгы, укудагы уңышлары белән кызыксынып торучы кайгыртучан ана сүзләре генә. Билгесез юлчылар китереп, яшертен рәвештә солтанның ишек астына ташлаганнары исә бөтенләй бүтән – аларда Камал бикә улына үзенең аксөяк чыгышы һәм тиздән Казан тәхетенә дәгъва итәргә тиешлеге турында армый-талмый искә төшереп тора. Ибраһим үсә төшкәч, анасы әлеге хатларда яшь солтанга фикердәш-көрәштәш булырдай бәк һәм карачыларның исемнәрен атый башлады. Ни Камал бикә, ни Ибраһим бу мәктүпләрнең бер өлешен хан шымчылары кулга төшерә алганын сизмәделәр, әмма яшь солтанга барып җиткән кадәресе дә дары шартлаган кебек тәэсир итә иде.

Инде ир-ат булып җитешкәчтен, Ибраһим солтан әллә ничә тапкыр әнисе янына барып кайтты. Ул бу турыда, канәгатьсезлек белдермәсен һәм катгый тыю салмасын өчен, атасына әйтеп тормады. Шул кыска вакытлы гына очрашып-күрешеп алулар да аның теләкләренә үзгә бер көч өсти иде. Анасы аңа юл күрсәтүче йолдыз, ышанычлы сердәш булды. Аның янында Ибраһим, саклык турында да онытып, иң фетнәчел уйларын ачып сала, ә Камал бикәнең башында умарта күче кебек гөжләп торган гадәттән тыш киңәшләр аның йөрәген кузгата, хыялына ирешер юлны кыскарта. Тик бу елларда, солтанны бөтен барлыгы белән җәлеп иткән яшерен көрәш бик күп вакытны алганлыктан, Ибраһимның анасы белән еш очрашып тору мөмкинлеге чикләнә төшкән иде. Соңгы тапкыр ул аны ел ярым чамасы элек күргән икән. Инде менә, бер яманлыкның бер яхшы ягы була, дигәндәй, Камал бикә янына барып чыгу җае тагын чыкты.

Кышкы салкын иртәдә, Мукшы шәһәрчеге җиргә иңәргә җыенган кебек тәбәнәк, беренче кар кунган өйләре белән артта калуга, Ибраһимның иңбашлары турайды. Соңгы өч ай буе араларында яшәргә туры килгән җирле кенәзләрне ни дәрәҗәдә җене сөймәгәнен, куралмаганын ул беркемгә, хәтта эчтән генә үз-үзенә дә әйтә алмады. Алар алдында ул бөтен вак-төяк бәхәсләрен, ызгыш-талашларын гадел хәл итә торган кайгыртучан, киң күңелле хуҗа булып уйнарга мәҗбүр булды. Инде боларның барысы да артта калды, ә алда аны анасы белән күрешү көтә. Анда менә кыланып торасы да, алдыңны-артыңны карап сөйләшәсе дә түгел. Бу уйлар солтанны юл буена җылытып барды.

Икенче көнне Ибраһим солтанның күз алдында Акташның ап-ак кар белән өретелгән бакча уртасында оеп утырган матур-нәфис корылмалары калкып чыкты. Солтан һәрвакыт тимер капка янында сураеп торган сакчыларның юклыгын күреп гаҗәпсенде. Җил өреп тараткан карлы сукмактан төп ишеккә килеп, өйгә керде. Әнисенең йокы бүлмәсенә чуар бохар келәме җәелгән баскыч алып менә, Ибраһим аның буйлап очып кына узды. Өйдә кеше-кара юклыгы, гадәти булмаган тынлык аның күңеленә шом салды. Менеп җитүгә, бикәнең бүлмәләрендә ниндидер аңлаешсыз шаушу һәм хатын-кыз тавышларын ишетеп алды. Ишекне киң итеп ачкан иде, шунда ук анасының кочагына килеп керде. Камал бикә, боеручан тавыш белән җикереп, күн сандыкларны тутырып маташкан хезмәтчеләрне куып чыгарды. Улының кулыннан эләктереп, аны, сабый чагындагы сыман җитәкләп, бүлмә эченә тартып кертте.

– Балакаем, сине монда Аллаһ үзе җибәргәндер. Мине Казанга кадәр озатып кайта аласыңмы?

– Казанга кадәр?! Мин ялгыш ишетмәдемме, мөхтәрәмә бикә?

– Бикә? – Хатын, борынын җыерып, күкрәген калкытып куйды. – Түбәннән очасың, кадерле Ибраһим солтаным, мин, – инде ярты ай була, – Казан ханшасымын!

– Сез ни сөйлисез, әни?

– Белмим, син монда кайдан килеп чыккансыңдыр, яраткан улым, әмма мөһим хәбәрләр сине урап узган икән. Башкалада Сәрби карчык үлгәнгә уникенче көн китте, димәк, инде минем, чып-чын ханша булып, аның урынын биләгәнемә дә шул гомер дигән сүз. Көндәшемнең үлеме кайчандыр ирем япкан ишекләрне миңа кабат ачтырды. Ханшага, әлбәттә, Казанда, хаким ире янында яшәү тиешле. Мәхмүд хан ул хакта хәбәр салырга онытты булса кирәк, әмма мин, Казанга кайтып, аңа көтелмәгән бүләк ясарга җыендым. Теге тинтәк Агиш углан сүземне тыңларга һәм, тиешле ихтирам күрсәтеп, дәрәҗәле сак белән пайтәхеткә озатырга теләмәде. Миңа иремнең ул тугры этен куып җибәрергә һәм, кайтып үз урынымны алуга ук, аны зинданга ябу белән куркытып калырга туры килде. Бүген иртә таңнан бирле, Акташтан каравылсыз ничек китәргә инде, дип баш вата идем, безнең күктәге хуҗабыз Аллаһ Сөбханә вә Тәгалә догаларымны ишеткән дә сине монда җибәргән. Үземнең солтан-улым сагы астында мин, димәк, аерым хөрмәт-дәрәҗә белән Казан капкасыннан кайтып керәчәкмен. Казан халкы кайчан да булса күргән тантаналардан минеке иң купшысы булуын телим. Барысы да күрсен: мин – гади ханша гына түгел, мин – булачак ханның анасы!

– Әй әнием, авызыгызга бал да май, сүзләрегез хәлвәдән татлырак! Бу кадәр куанычлы һәм йөрәгемне җилкеткән яңалыкларны күптән ишеткәнем юк иде. Тик мин Сезнең кадәр үк гайрәтле түгелмен шул. Хан миңа Казанга кайтырга рөхсәт бирмәде әле. Башкалада пәйда булсам, ул моңа ничек карар?

Камал бикә, нәфис парча түфли кигән аягы белән калын яшел келәмне тукылдатып, уйга калды. Ниһаять, ул һаман да матур куе тузгак чәч белән бизәлгән бәләкәй башын тәвәккәл генә чайкап алды да:

– Дөрес фикер йөртәсең, улым, ханга карышыр вакыт түгел әле! Зур кодрәткә ия хакимебез авыру һәм хәлсез, дип ишеттем, әмма карачылар элеккечә үк аны берсүзсез тыңлыйлар икән. Күрәсең, күп еллардан килгән гадәт үзен сиздерә. Каршы торган өчен сине юк итү Мәхмүдкә кыен булмаячак, ул һәрвакыт нык ихтыярга ия һәм, ачуы килгәндә, йөгәнсез иде. Хәлил солтанда кадерле иремдәге сыйфатларның яртысы да булмавы – безнең бәхеткә. Шулай хәл итәбез, улым: син мине Алатырга хәтле озатып куясың, андагы бәк күп яхшылыкларым өчен бурычлы, ул мине Казанга озатып куярга сак бирер. Син әлегә шунда калып, миннән киләсе атчабарны көтәрсең. Мин хан сараеннан хәбәр салып торырмын. Ә менә бу йөзекне алгач, – Камал бикә каратуткыл кулын бизәгән кандай кызыл кашлы калын йөзеген күрсәтте, – көн-төн, атларны алыштыра-алыштыра, башкалага очып кайтырга тиешсең. Барысы да синең никадәр тизрәк кайтуыңа бәйле булачак!

Урысчадан ***Мөдәррис Вәлиев***
тәрҗемәсе ■

Редакциядән:

Журналыбызның киләсе санынннан башлап сез «Казан ханбикәләре» трилогиясенең мавыктыргыч дәвамы – «Гәүһәршад» романы белән таныша аласыз (Ольга Иванова әсәре, Мөдәррис Вәлиев тәрҗемәсендә).

Безнең мирас №6 июнь 2018

ТАТАРЛАР АЛГАРЫШ ЮЛЫНДА

Индус Таһиров

Республикабызның игълан ителүенә 100 ел тулу тантанасына әзерлек башланды. Дәүләтчелегебезнең тирән тамырларын ныклап ачыклау, аның нигезләрен барлау вакыты җитте.

Билгеле ки, безнең иң зур югалтуларыбызның беренчесе – 1552 елны Казаныбызның яулап алынуы, дәүләтебезне югалту. Югалту никадәр авыр булса да, аны кайтару аннан да авыррак. Шушы коллык чорында «күпме михнәт чиккән безнең халык, күпме күз яшьләре түгелгән». Тукай бу сүзләрне үзе дә канлы яшьләре белән язган.

Кичә бөек булып, ничәмә-ничә шанлы дәүләтләр төзегән халыкның канына сеңгән шул дәүләтчелек. Ул һәрвакыт үзен сиздерә килгән. Татарларның башка халыкларга ярдәм кулын суза килүләре, алар арсында аң-белем таратулары да юкка гына түгел. Ул әнә шул дәүләти канның хәрәкәттә булуының бер күренеше. Әлеге кан буыннан-буынга бирелә килгән һәм үзе өчен иң зур авырлыклар туганда да ныклап белдереп килгән, аның татарлыгын уята торган көч булган.

Ул бигрәк тә тарихның кискен борылышлары вакытында хәрәкәткә килә, аның тарихи хәтерен, дәүләти тойгыларын уята.

Беренче рус революциясе татарны, Тукаебыз язганча, уятты бишенче елның бер таңында. Әйе, бу революция татарның милли аңын уятты, аның максатын ачыкларга мөмкинлекләр ачты.

Дәүләтчелегенең формалашуына татарлар зур әзерлек белән киләләр. Зур, әлегәчә тиешенчә бәяләнә алмаган яңарыш юлы аша үтәләр.

Мәкаләмнең асылын баштарак яңарыш сүзен кулланып билгеләгән идем. Ләкин шунда ук төзәтмә кертергә кирәк, дип таптым. Чөнки татар беркайчан да искермәгән, һәрвакыт яңарып торган. Аның учагы беркайчан да сүнмәгән, авыр һәм хәвефле чорла-

рында да пыскып булса да яна торган. Ә илдәге күтәрелеш, бигрәк тә революция елларында, гөрләп яшәп килгән. Аны, күпме генә тырышсалар да, беркайчан да, беркем дә диненнән һәм теленнән биздерә алмаган. Ул Ислам диненә, Аллаһ Тәгаләгә һәрвакыт тугрылыклы булып калган. Нәтиҗәдә, үз башына төшкән барлык авырлыкларны, кысрыклау-җәберләүләрне җиңеп килгән.

Шунлыктан «яңарыш» сүзен «алгарыш» төшенчәсе белән алыштыру дөресрәк булыр. Чөнки ул татарның рухи яңарыш кичереп, алга баруын аңлата торган төшенчә.

1914 елның 17 сентябре көнне Казан хәрби-цензура комитеты үзенең бер җитди белешмәсендә, татарларның нәрсә уйлаганнарын, кәефләренең ничек икәнен белү өчен, аларның соңгы утыз елда иҗтимагый фикерләренең нинди шартларда үскәнлегенә һәм татар интеллигенциясенең дөньяга яңача карашларының барлыкка килүенәниләр сәбәп булганлыгына, аларга нәрсәләр йогынты ясавына күз ташлау кирәк, диелгән. Документ авторының сүзләренә караганда, татарлар суд, дин, мәктәп автономиясен һәм татар телен кайбер хөкүмәт органнарына кертү турында хыялланганнар.

Документ авторы алгарышның юл башында Исмәгыйль Гаспралы торганлыгына, аның Кырымда ысул җәдиткә нигезләнгән мәктәп ачып, дәреслек төзүенә һәм, гомумән, аның киң колачлы эшчәнлегенә зур урын бирә.

Чыннан да, бу шәхеснең татар алгарышына керткән өлеше гаять зур. Ул турыда күп язылды һәм язылачак та.

Тик алгарышның төп сәбәпчесе ил күгендәге зур тизлек белән куера барган революция болытлары була.

Ә алгарыш исә барлык куәте белән 1905-1907 ел революциясеннән башлана. «Без бишенче елның бер таңында уяндык», – дип язган Тукай һәм һичшиксез хаклы да булган. Чөнки шуннан башланган чор – татарның гасырлар буе җыелган потенциалын яңа сыйфатка төреп, барлык мөмкинлекләрен хәрәкәткә китергән чор. Аның тарихи хәтере уяна, ул үзенең үткәнен барлый башлый.

Шушы барлауның нигезендә мәшһүр Шиһабетдин Мәрҗани тора. Аның артыннан, аңа ияреп, Һади Атласи, Гайнетдин Әхмәров, Ризаэддин Фәхреддинов, Газиз Гобәйдуллин кебек зыялыларыбыз тарихыбызны ныклап тикшерү юлына басалар. Борынгы кулъязмаларны, рус елъязмаларын ныклап өйрәнеп, тарихыбызның төбенә төшүгә юл салалар.

Шул ук вакытта татарның дистәләгән берсеннән-берсе сәләтлерәк язучылары, журналистлары да калкып чыга. Утыздан артык газет-журналлары барлыкка килә. Меңләгән тираж белән төрле проблемаларга багышланган китаплар бастырыла башлый. Аларны матди-финанс ягыннан тәэмин итүчеләр милләтнең инде ныклап аякка баскан эшмәкәрләре була.

1909 елда, рәсми мәгълүматларга караганда, Казанда мөселман телләрендә 8062000 бит тәшкил иткән 449 исемдәге 3115 данә китап бастырыла. 1912 елны барлыгы 361 татар китабы чыгып, аның 69 проценты Казанга туры килә.

1913 елны Россиядә татар телендә 340 китап бастырыла. Шул ук вакытта әрмән телендә – 257, грузин телендә – 232, украин телендә – 228, чуаш телендә – 56, казакъ телендә – 40, үзбәк телендә – 37, беларусь телендә нибары 2 китап дөнья күрә. Шушы рәвештәге нәшрият эшчәнлегенең сәбәпчесе белемгә, мәгърифәткә омтылучы халык үзе була. Татарлар әлеге елларда Россиянең иң укымышлы халкына әвереләләр. 1908 елны Идел буеның рус булмаган мәктәпләре инспекторы Я.Д.Коблов болай дип язган: *«Россиянең көнчыгыш өлешендә яшәгән халыклар арасында мөселман-татарлар беренче урында торалар. Аларның укымышлыларының проценты хәтта руслар белән чагыштырганда да бик зур. Татар, чыгышы белән кайсы класстан булуына да карамастан,*

диненең башлангычын белә, үз телендә укый-яза белә. Укымышлылыкның киң таралу сәбәбе аларның һәрбер, хәтта кечкенә авылларында да мәктәпләре булуында. Аларда белем бирү белән, юк кына бәягә, хәтта бөтенләй бушлай ук, муллалар шөгыльләнәләр»[1].

Халык китапка бик нык тартыла. Күп җирдә китапханәләр барлыкка килә. Аларда укучыларның саны артканнан-арта тора.

Менә боларны раслый торган берничә факт: 1911 елны Чиләбе шәһәренең мөселман китапханәсенең 13767 укучысы булган. Аларның кулына 4435 китап бирелгән. Шуларның 2386сы татар, ә 2982се рус телләрендә булган. Китапханә 905 данә газет-журнал алдырган[2].

Троицк шәһәрендәге «Нәҗәт» китапханәсенең шул ук 1911 елны 19432 укучысы булган. Казан, Уфа, Мәскәү, Петербург кебек зур шәһәрләрдәге китапханәләрдә дә укучыларның саны артканнан-арта барган.

Хатын-кызлар, балалар өчен махсус мөмкинлекләр булдырылган. 1911 елның 9 (22) декабрендә Казанның Шәрык клубында мөселман хатын-кызлары өчен махсус бүлек ачылып, анда алар өчен газет-журналлар, китаплар уку мөмкинлеге булдырыла. Казанда «Балалар күңеле» исемле журнал чыгару планлаштырыла.

Шушы елларны, халыкның күп санлы сорауларын истә тотып, Казан нәшриятлары рус язучыларының һәм шагыйрьләренең әсәрләрен дә тәрҗемә итеп чыгаралар. Пушкин, Лермонтов, Тургенев, Куприн, Андреев кебек классикларның әсәрләрен кабат-кабат бастыралар.

Белемгә, мәдәнияткә омтылу татар яшәешенең һәр төрендә чагылыш таба. Лекцияләр оештыру, дәреслекләр әзерләү, театр, музыка сәнгате белән кызыксыну – болар барысы да шул алгарыш елгасының агымнары. Шушы хактагы кайбер фактларга да күз салыйк.

1916 елда Уфада Закир әл-Кадыйриның халык университетының мөселман бүлегендә хатын-кыз хокукларына багышланган лекцияләре дөнья күрә. «Мәгариф» типографиясе Тукай әсәрләре җыентыгын, «Сабах» типографиясе исә Ф.Сәйфинең татар теле буенча 2-3 дәреслеген чыгара. «Гасыр» нәшриятында хикәяләр һәм шигырьләр җыентыгы, «Йорт хуҗалыгы», «Сәнаигы нәфисә», Г.Исхакыйның «Остабикә»се, Гыйффәт туташның шигырьләр җыентыгы, Мустаевның «Сугышның максаты һәм сәбәпләре» исемле китабы басылып чыга. 1909 елның февралендә Камил Мотыгый Төхвәтуллин, үзенең баритон тавышы белән Петербургтагы гастрольләрдә татар җырларын башкарып, тамашачыларны таң калдыра, чыгышын көчле алкышларга күмәләр. Аны 4 мартта Саратовтагы «Шәрык музыкасы кичәсе»ндә шулай ук кайнар алкышлар белән кабул итәләр.

Шушы елларда Гаяз Исхакыйның «Өч хатын белән тормыш» пьесасы рус теленә тәрҗемә ителә. Аны «Знание» нәшрияты бастыра. Бу пьеса Казан һәм Уфа сәхнәләрендә уйнала. Татар тормышына битараф булмаган Максим Горький нәшриятка язган хатында, Исхакыйның башка әсәрләре дә рус телендә дөнья күрсен иде, дигән фикер белдерә.

Әстерхандагы яшьләр труппасы У.Шекспирның «Отелло»сын сәхнәләштерә. Уфадагы хатын-кызлар комитеты балалар кичәсе оештыра, бер пьесаны сәхнәгә куя. Кичәдә балалар шигырьләр укыйлар.

Россиянең татарлар яшәгән башка шәһәрләрендә дә шундый ук активлык хөкем сөрә. Илнең 11 губернасында «Мәгариф лигасы» («Лига образования») барлыкка килә. Аның 100 кешедән торган төп комитеты Петербургта урнашкан була.

Татар мәгарифенең үсешендә 1906 елны Түбән Новгород шәһәрендә булып үткән Мөселман корылтаеның әһәмияте зур була. Анда мәгариф үсешенә караган 33 пункттан

---

[1] Страна Советов за 50 лет. Сборник материалов. – М., 1957, с.291.

[2] В мире мусульманства. №1, 20 апреля 1912 г.

торган карар кабул ителә. Беренче ике пунктта барлык татар авылларында башлангыч, ә кайберләрендә ике класслы мәктәпләр ачу теләге белдерелгән. 3 нче пунктта аларның барысында да укыту гарәп графикасында татар телендә алып барылырга тиешлеге язылган. Мәктәпләр белән идарә итү мөселманнарның үзләре сайлаган дирекция карамагында булырга тиеш, диелгән. Карарның 19 нчы һәм 21 нче пунктларында шәһәр мәктәпләрендәге гимназияләрдә мөселман балалары өчен пансионнар оештырып, укучыларга дин белемен һәм татар әдәби телен иркен кулланырдай итеп бирү мөмкинлеген булдыру каралган. Анда укытуларын рус телендә алып баручы «Учительски ышкул»да аларны тәмамлаучыларның дин һәм туган телләрен үзләре укытырдый дәрәҗәдә үзләштерергә тиешлегенә басым ясалган.

Шунысы игътибарга лаек: әлеге карарны тормышка ашыруны дәүләт һәм земстволар финансларга тиеш була. Земстволар, күпвакыт хөкүмәт сәясәтенә каршы килеп, татар мәгарифенең үсешенә зур өлеш кертә.

Шундыйларның берсе Уфа губерна земствосы була. Ул 1911 елның 23 маенда Думаның мөселман фракциясенең кайбер күренекле әгъзалары, җәмәгать эшлеклеләре, педагоглар һәм Халык мәгарифе министрлыгы вәкилләре катнашында рус булмаган халыкларга белем бирү мәсьәләсен тикшерүгә багышланган киңәшмә үткәрә. Аның карарларында башлангыч мөселман мәктәбен тәмамлаучылар русча укый-яза белергә тиеш, диелгән. Мөселманнар өчен учительская семинарияләр булдыру ихтыяҗы барлыгы да күрсәтелгән. Аларда туган һәм рус телләрен укыту бер дәрәҗәдә булырга тиешлеге ассызыкланган.

1912 елның 10-11 гыйнвар көннәрендә Казанда өяздәге татар мәгарифе мәсьәләсе карала. Өязнең халык училищелары инспекторы Коблов үзенең докладында, моңа кадәр татарлар һәрбер авылның мәчете каршындагы мәктәп-мәдрәсәләргә канәгать булып яшәгән булсалар, хәзер исә аларга дөньяви белем бирә торган рус-татар училищелары кирәк, ди. Киңәшмәдә катнашучылар бу училищеларда татарча укытуны, шулай ук татар телендә журнал чыгарырга кирәклеген шарт итеп куялар.

Татарлар өчен әлеге елларда театр әһәмиятле урын тоткан, чөнки татар театры, гомумән, мәдәниятебез болгар чорыннан ук башланган тирән тамырларга ия. Галимнәрнең раславынча, театр инде Идел Болгарстанында ук булган. Ул бертуктаусыз фольклор, төрле уеннар һәм спорт ярышлары белән баетыла торган һәм бигрәк тә Сабан туйлары вакытында ачык чагылыш тапкан.

Документаль рәвештә расланган фактларга караганда, Г.Ильясиның «Бәхетсез кыз» пьесасы 1887-1888 елларда аның үз өендә уйналган. Гаяз Исхакый үзенең автобиографиясендә Казанда «Блуждающие огни» пьесасы йогынтысында «Өч хатын белән тормыш» исемле пьесасын тудыруы турында яза. 1897-1898 елның кышында Казан укытучылар мәктәбе шәкертләренең көче һәм данлыклы Шамилнең оныгы М.З.Шамил тырышлыгы белән Н.В.Гогольнең «Женитьба»сы куела. Шамил бу эшләрне башкару өчен хакимият ризалыгын алуга ирешә, халык арасында театрны пропагандалауны да киң җәелдерә. Ниһаятъ, 1901 елның 27 гыйнварында шәһәр театры бинасында 400 тамашачы катнашында татар телендә А.Н.Островскийның «Волки и овцы» спектакле куела.

В «Мире мусульманства» газетасының 1911 елның 18 ноябрендәге санында Ильяс Кудашев-Ашказарский труппасының, Каспий арты җирләре, Бохара, Төркестан турнесыннан соң Оренбургка килеп, анда 15 октябрь көнне «Наследство помогло» һәм «Самоубийство» пьесаларын куюы турында хәбәр бар.

1911 елның 22 ноябрендә Мәскәүдә поляк китапханәсе залында Вәлиевнең «Оят яки күз яше», Г.Камалның «Беренче театр»ы сәхнәләштерелә. 1912 елның 28-29

декабрендә Укытучылар мәктәбе шәкертләре Островскийның «Доходное место»сын, А.П.Чеховның «Юбилей»ын сәхнәгә чыгаралар. Антрактларда оркестр тамашачыларга кайбер яңа музыкаль әсәрләр тәкъдим итә[3].

Шул ук елны Уфада Гаяз Исхакыйның «Өч хатын белән тормыш» пьесасы сәхнәләштерелә. Рус тамашачылары өчен рус телендә либретто тәкъдим ителә. Иркутск шәһәрендә музыка сөючеләр, Томскида сәхнә сөючеләр түгәрәкләре, Саратовта театраль коллектив эшли башлый. 1907 елны Казанда «Музыкаль җәмгыять» барлыкка килә. Концерт сәхнәләрендә татар һәм башкорт моңнары яңгырый башлый. Татар милли музыкасының шедеврлары булган «Тәфтиләү», «Озын су», «Мөхәммәдия», «Ашказар» җырларын скрипкачы И.Козлов, җырчы Г.А.Трейтер башкара торган була. Әдәби-музыкаль кичәләрдә еш кына скрипкачы Гали Зайпинның, Заһид Хәбибуллинның кыллы оркестры, Камил Мотыйгуллин, Исмәгыйль Галиәкбәров һәм башка җырчыларның тавышлары яңгырый торган була. 1911 елның декабрендә Стәрлетамак өязенең Мәләвез шәһәрендә земство тарафыннан укучыларның гомуми саны 160 кешегә җиткән татар хатын-кызлары өчен рус-татар училищесы ачыла. Земство Богырыслан шәһәренең 5 мөселман мәктәбендә рус теле дәресләрен кертергә карар кыла. Укытучылар өчен елына 300 сум хезмәт хакы билгеләнә[4]. Орск шәһәрендә Хәкимҗан Рәхмәтуллин тарафыннан 100 кешелек татар кызлары мәктәбе оештырыла. (В мире мусульманства, 4 (17) ноябрь.) Петербургта шулай ук шәхси инициатива рәвешендә ир һәм кыз балалар өчен мәктәп ачу планлаштырыла. Иркутскида җирле хәйрия җәмгыяте мәктәп бетергән 13-20 яшьлек балалар өчен профессиональ мәктәп ачып җибәрә. Аның столяр бүлегенә, 30 сум айлык хезмәт хакы белән, һөнәр укытучысы билгеләнә. Балаларга рус телен укыту да карала. Инструментлар һәм башка җиһазлар сатып алу өчен 1000 сум акча бирелә[5].

Бәләбәй өязенең Каргалы авылында 1911 елның 1 сентябреннән шәһәр татар мәктәбе эшли башлый. Әстерхан шәһәренең «Шураи-исламия» җәмгыяте шулай ук мәктәп ачып җибәрә һәм аның каршында хатын-кызлар өчен китап һәм газет-журнал уку бинасы булдыра.

Рәсми документларда күрсәтелгәнчә, бу елларда Иж-Буби мәдрәсәсе халык арасында киң танылган уку йортына әверелә. Биредә уку өчен бик күп губерналардан килә торган булалар. Мондагы укыту эшләренә Урта Азиядән һәм Төркиядән дә килүчеләр өзелми. Мәдрәсәнең иганәчесе Мөхәммәтҗан Әхмәтҗанов аңа ел саен 10 мең сум акча бирә торган булган. Өстәвенә, җирле земство да үзеннән 700 сумлык субсидия билгеләгән.

Күренекле эшмәкәр М.Ш.Рәмиев Уфа губернасының Стәрлетамак шәһәрендә зур мәдрәсә төзетеп, аның эшчәнлеге өчен 1000 сумлык капитал билгели. Процентлары исә ремонт эшләрен алып бару өчен тотыла[6].

28 октябрьдә Мохтар Мутин Чиләбедә ике бүлектән торган чыгышын тәкъдим итә. Шуннан соң «Әдәбият ахшамы» дип исемләнгән әдәби кичә булып үтә. Икенче көнне Мутин инде Семипалатинскида. Анда ул, Г.Латыйпов белән бергә, шәһәр җәмәгатьчелегенә үзләренең концертларын тәкъдим итә.

Шуннан соң алар Троицкида. Мондагы концертларын газета болай дип бәяли:

---

[3] В мире мусульманства. 13(26) января 1912 г.
[4] Шунда ук, 23(5) декабрь.
[4] В мире мусульманства. 11(24) сентября 1911 г.
[5] Шунда ук, 10(23) февраль.
[6] Шунда ук, 10(23) февраль.

«Троицк мөселманнары өчен бу бик зур вакыйга, чөнки әлеге шәһәрдә беренче мәртәбә профессиональ мөселман артистларының чыгышы иде. Шунлыктан, публика аларны зур күтәренкелек белән каршы алды һәм шулай ук озатты да».

Татар театрының башлангычында Галиәскәр Камал тора. Ул, профессор Й.Нигъмәтуллина язганча, яңа татар драматургиясен нигезләгәндә болгар традицияләренә таяна. Шунлыктан, аның иҗаты динамикада, ә персонажларының теле үткен һәм төгәл була. Кәрим Тинчурин исә Галиәскәр Камал пьесаларына хас булган фарс һәм гротеск алымнарына трагизм элементлары өсти һәм Салих Сәйдәшев белән бергә музыкаль драмага нигез сала. Ә Фатих Әмирхан татар драматургиясенә яшәү шатлыгын өсти. Шул елларда киң җәмәгатьчелек Гафур Коләхмәтовның татар интеллигенциясенең революциягә килү юлын тасвирлаган «Ике фикер» һәм «Яшь гомер» пьесаларын җылы кабул итә.

«Галия» мәдрәсәсендә Варшава консерваториясе профессоры В.Клеменц җитәкчелегендә оркестр барлыкка килә. Галимҗан Ибраһимов инициативасы белән «Милли моңнар, сәхнә һәм әдәбият түгәрәге» эшли башлый. Шәкертләр, каникулга таралгач, халык җырларын, легендалар һәм әкиятләр җыеп алып кайта торган була.

Жандарм органнары татарның рухи тормышын игътибарсыз калдырмый. 1913 елның 4 маенда Казан жандарм идарәсе Сембер, Самара, Саратов, Царицын, Әстерхан, Баку, Красноводск, Чарджоу, Мерв, Бохара, Сәмәрканд, Әндиҗан, Нәманган, Ташкент, Оренбург, Түбән Новгород калаларындагы хакимиятләргә шушы шәһәрләрдә Габдулла Кариев җитәкчелегендәге «Нур» труппасының концертлары булачагы һәм труппаның 45233 номерлы пароход белән Казаннан чыгып киткәнлеге хәбәр ителә. Шушы турыдагы телеграммада *«прогрессив юнәлештәге Кариев андагы җәмәгатьчелекне Казан прогрессистлары белән якынлаштырырга тырышачак»*, дигән борчылу белдерелә. Саратовтан алынган хәбәргә караганда, анда труппа «Новоцентральный» номерларында урнашып, Сөләйманов, Юскаев, Абделмановлар белән очраша.

Татарларның шушы дәрәҗәдәге тизлек белән мәгариф системасы үсүе рус хакимиятенә һич кенә дә ошамый. Татар тормышындагы позитив үзгәрешләр Россия хөкүмәте башлыгы П.А.Столыпинның да игътибар үзәгендә булган. Бу әлеге түрәнең Синодның обер-прокурорына язган хатында ачык чагыла. *«Христиан халкы өчен,* – диелгән анда, – *мөселман дөньясы белән бәрелешү – дини көрәш кенә түгел, ә дәүләти, мәдәни бәрелеш»*. Хатта, илдә панисламистик пропаганданың көчәюе, аның уңышы аерым әһәмияткә ия, диелгән. Столыпинны хәтта кечкенә авылларга кадәр мәчетләр ачылуы, яңа мәктәпләр барлыкка килүе, әдәби әсәрләр басылуы да борчый, авыллар буйлап газет-журналлар таратып йөрүче ир-ат һәм хатын-кызларның арта барулары, һәммә җирдә мәдәнияткә, аңлы тормышка, үзбилгеләнүгә омтылышлары пошындыра. Алай гына да түгел, аңа татарларның православие һәм ислам арасында тибрәнүче рус булмаган халыкларга йогынтысының арта баруы да тынгылык бирми. Шунлыктан, ул шушы татар йогынтысына каршы аяусыз көрәш ачарга чакыра. Мондый көрәштән баш тарту – гасырлар дәвамында барлыкка килгән тарихи бурычлардан баш тарту һәм моның тискәре нәтиҗәләре санап бетергесез булыр иде, дип яза Столыпин. Һәм шушы көрәштә хөкүмәтнең барлык мөмкинлекләрен кулланырга чакыра.

Нәтиҗәдә, озак көттермәстән, ул мөмкинлекләр гамәлгә аша башлый. 28 панисламчының исемлеге барлыкка килә. 1910 елның 12-19 сентябрендә, шушы көрәш чараларын билгеләү өчен, «Идел буендагы татар-мөселман йогынтысына багышланган махсус киңәшмә» – «Особое совещание по выработке мер для противодействия татарско-мусульманскому влиянию в Поволжском крае» булып үтә. Анда дини-мәдәни төстәге татар-мөселман хәрәкәтенең дәүләткә каршы икәнлеге ассызыкланган. Теоре-

тик яктан караганда, әлбәттә, Ислам динендәге халыклар арасына христиан диненең нурларын тарату мөселманнарның рус культурасына кушылулары булыр иде дә бит. Ләкин бу бүгенге шартларда һич кенә дә мөмкин түгел, шунлыктан, әлеге теләк берничек тә тормышка аша алмаячак, диелгән документта. Тиешле чаралар күрелмәве аркасында пантюркист пропагандистларның зур уңышларга ирешүләренә басым ясалган. Алар безнең законнар нигезендә конфессиональ рәвештә барлыкка килгән яңа методик мәктәпләр һәм мәдрәсәләр челтәрен гомуми белем бирү мәктәпләренә әверелдерделәр. Шуның белән алар дәүләт байлыгы булган мәктәпләрне үзләштереп, дини-мәдәни автономиягә адым ясадылар. Аларның бу адымнары куркыныч рәвештә үз нәтиҗәләрен бирә башлады. Анда дингә бернинди катышы булмаган арифметика, география, Төркия тарихы укытыла башлады, диелгән.

Киңәшмә, шушы рәвештәге керештән соң, мондый карарлар кабул итә. Беренчедән, шушы гамәлләргә каршы көрәшү өчен, рус булмаган халыкларның телләрен белердәй, алар арасына үтеп керердәй миссионерлар әзерләүгә керешергә кирәк. Икенчедән, шул миссионерларны әзерли торган семинарияләрдә җирле телләрне өйрәнү мәҗбүри булырга тиеш. Өченчедән, бүгенге ике класслы дини мәктәпләргә өстәп, андыйларны инородецлар яшәгән үзәкләрдә ачып, аларда укучы рус кешеләре өчен җирле халыкларның телләрен белүне мәҗбүри итәргә. Һәм, ниһаятъ, ул җирләрдә яшәгән рус булмаган халыкларның уңайсыз шартларда булуын искә алып, аларның кулларына ышанычлы корал бирергә яки божий законны, аның исламнан өстен икәнлеген ныклап аңлатырга, аңа каршы бәхәсләр алып барырга өйрәтергә кирәк.

Киңәшмә, әлеге максатка ирешү өчен, Ислам тарихы турында кыска язма һәм аны фаш итә торган катехезис һәм аның иң яхшы вариантлары өчен премияләр булдырырга, дигән карар кабул итә.

Татарга каршы адымнар моның белән генә чикләнми. Аны эзәрлекләүләр киң җәелдерелә. Беренчеләрдән булып, Казандагы Галимҗан Баруди мәдрәсәсе тар-мар ителә. Баруди үзе кайбер шәкертләре белән Вологда губернасына сөрелә. Вятка губернасының Сарапул өязендәге бертуган Габдулла һәм Гобәйдулла Бубиларның татар дөньясында дан тоткан мәктәпләре ябыла. Үзләре исә кулга алыналар. Аларга каршы «Бубилар эше» барлыкка килә.

Уфа, Оренбург, Казан губерналарындагы татар хәрәкәтен хөкүмәт сепаратизм дип бәяли. 1911 елның сентябрендә аларны тикшерү өчен махсус комиссия җибәрә. Нәтиҗәдә, кайбер укытучылар, мәсәлән, Казанның «Мөхәммәдия» мәдрәсәсе мөгаллимнәре А.Мостафин, Ш.Шәрәфи һәм Ф.Зәбиров, Вятка губернасы Малмыж өязенең Урбар авылы ахуны Әхмәтгәрәй Садыйков кулга алына.

Шул елның 11 июлендә иң бай китапханәләрнең берсе булып саналган Чиләбе мөселман китапханәсендә жандармнар тентү үткәрәләр һәм 1905 елда ук рөхсәт ителгән 75 татар китабын конфискациялиләр.

Мондый фактларның артканнан-арта баруына да карамастан, тирән тамырларга нигезләнгән татар алгарышы үзенең үсешен туктатмый. Киресенчә, ул киңәйгәннән-киңәя генә бара. ■

ШЫГЫРДАН ТАҢЫ

Памир Салихов

Чуаштан Республикасындагы иң зур татар авылы Шыгырданның исеме һәм җисеме, андагы халыкның кайдан һәм кайчан килеп төпләнүе, борынгы фамилияләр тарихы шактый кызыклы. Менә шул тарих турында үзем белгән кадәр мәгълуматны сезгә дә җиткерәм, кадерле «Безнең мирас» журналын укучылар!

Шыгырдан авылына **кангар** яки **каңглы (каңлы)** кабилә кешеләре нигез салган, имеш. Каңгар (каңлы) сүзенең «шалтырау», «шыгырдау» мәгънәсендә кулланылганы билгеле. Иң беренче арбаны уйлап чыгарган кешеләрне каңглы дип атаганнар, чөнки арба канг-канг итеп шыгырдап йөргән икән. Тора-бара каңлы кабилә кешеләрен бәҗәнәк (печенег яки урман кешесе) исеме белән атап йөртә башлыйлар. Халкыбызда:

«Шыгыр-шыгыр арба,
Шыгырданга барма.
Шыгырданга барсаң,
Ятлар белән чуалма», –

дигән дүртьюллык та бар.

Галим Кәшаф Земдихановның әйтүенчә, Шыгырданга нигез салучылар шәһәрдән

---

[1] **Салихов Памир Мөдир улы** – ветеран укытучы, төбәкне өйрәнүче. Шыгырдан авылында яши.

күчеп килүчеләр булган. Ул **«шәһәрдән»** сүзе Шыгырдан дип үзгәртелүе турында фараз кыла.

Татарлар авылны аңа беренче килеп утыручы кешенең исеме белән дә атый. Ул вакытта авылга нигез салучының исеме **Шаһигардан (Шәйгәрдән, Шаһигәрдән)** булырга тиеш. Г.Ф.Саттаров һәм М.З.Зәкиевнең «Татар исемнәре сүзлеге»ндә Шәйгәрдән (Шаһигәрдән) дигән исем бар. Шунда ук Шәйгәрдәннең (Шаһигәрдән) аерым шивәләрдә әйтелешенә мисал буларак, **Шагардан, Шыгырдан, Шырдан, Шайдан, Тардан, Гәрдән** дигән исемнәр дә китерелә.

1390-1395 елларда Аксак Тимер Биләр һәм Болгар шәһәрләренә һөҗүм итә. Шуннан соң бу шәһәрләрдә һәм аның тирәсендәге төбәкләрдә яшәүчеләрнең Зөя, Гөбенә, Бола елгалары буйларына (Тау ягына) китеп урнашканлыгы мәгълүм. Бездән ун чакрым чамасы ераклыкта Кыр Бикшиге авылы урнашкан. Аның янындагы «Наратлар асты» дигән урында нәкъ менә шул елларда шәһри Болгардан килеп вафат булган кешеләр җирләнгән каберләр саклана. Аксак Тимер явыннан качып килгән халыкның Шыгырдан авылына да нигез салулары мөмкин. Әлеге фикерне Чаллы шәһәрендә яшәүче авылдашыбыз, укытучы-пенсионер Минзифа Андин кызы Чинкина әйтә.

Шыгырдан һәм Кызыл Камыш авылларында **Сменов** фамилияле кешеләр бар. Кайберәүләр Сменов фамилиясен, урысча булганга, башкага алыштырган. Ләкин бу сүз Симән дигән татар исемен урыслаштырып әйтүдән килеп чыккан. Мөхтәрәм галим Марсель Әхмәтҗанов: *«Симән исемле кешеләр Биләрдән яки Шәһри Болгардан килгән»*, – дип яза.

Шыгырдан авылында **Катай** нәселеннән булган гаиләләр берничә. Ахмәр Минегали улы Алеев үз нәсел исеменең борынгы заманнан ук килгәнен әйтә. Тел галиме Фирдәвес Гарипова: *«Катай исемле төрки кабиләләр булган. Иң башта аларны тарихта киданнар дип йөрткәннәр. 553 елда ук киданнарның кытайлар белән сугышуы билгеле. Төрки каһанлык төзегән киданнар, кардәш татар кабиләләре белән берлектә, Кытайга каршы авыр көрәш алып барганнар. XII гасырда киданнар яңадан кара кидан яки кара кытай исеме белән телгә алына. Чүпрәле районында Югары Каракитә, Түбән Каракитә авыллары атамасы кара кытай сүзеннән чыккан. Бу авылларны Алатыр ягындагы Каракитә авылыннан күчеп килүчеләр 1440 елда нигезләгәннәр. Югары Каракитәне – Акмай, Түбән Каракитәне Тукмай исемле кешеләр башлап җибәргәннәр»*, – дип яза.

Шыгырдан авылында **Крымов** фамилияле нәсел дә бар. Бу нәсел кешеләре Канашка, Шумерляга да күчеп киткән. Шыгырданда яшәүчеләре исә үзләренең фамилияләрен Юнусовка алыштырган. Алар үз фамилияләренең кайдан килеп чыкканлыгын белми, борынгыдан ук килгәнлеген генә истә тоталар. Крымов фамилиясе Түбән Новгород өлкәсендәге татар-мишәрләрдә дә очрый. Билгеле, бу да очраклы рәвештә генә барлыкка килмәгәндер. Элек Кырым җирләре Нугай Урдасы составына кергән. Алтын Урда ханы Туктамыш Нугай Урдасыннан Кырым җирләрендә яшәүче күп кенә татарларны Идел-Урал төбәгенә күчергән.

Шыгырдан авылында **Җәмәков (Йәмәков)** фамилияле нәсел вәкилләренең төп нигез урыны иске каберлеккә якын. Риваятьләргә таянсак, бу нәсел кешеләре Шыгырданга нигез салучылар арасында булырга мөмкин, дип фикер йөртә алабыз. Мәгълүм ки, *җәмәк/йәмәк* атамасы да бик борынгылардан санала. Йәмәк кабиләләре кимак этнонимы белән дә йөргән. Алар Көнбатыш Төрки каһанлыгы составында булган һәм Алтай, Иртеш тирәләрендә күчмә тормыш алып барган. 656 елда Көнбатыш Төрки каһанлыгы таркалгач, йәмәк кабиләләре Иртеш елгасыннан алып Урал тауларына кадәр сузылган каһанлык төзи. Татарстанның Минзәлә районында һәм башка төбәкләрдә дә Җәмәк исемле авыллар, елга, инеш, чокыр, күлләр бар. Димәк, йәмәк кабиләләре Казан арты,

Кама аръягы, Тау ягы районнарына һәм башка бик күп җирләргә килеп урнашкан.

Авылда **Кушаев** фамилияле гаиләнең борынгы бабасы хәзерге Комсомол районы Урмай авылыннан күчеп килгән. Бу фамилиянең дә килеп чыгышы игътибарга лаек. Саранскида чыккан «Документы и материалы по истории Мордовской АССР» исемле китапта: *«Татарские княжья Кугушевы, Алышевы, Кушаевы и Тенищевы получили поместья за Керенским и Щацким валами на диком поле»*, – дип язылган. Минем фикеремчә, Кушаев сүзенең нигезе – «кош»тан. Тарихи чыганакларда Кушай исемле бабайның, Түбән Новгород якларыннан күчеп килеп, Буа төбәгендә яшәгәнлеге билгеле.

Шыгырданда татарларда сирәк очрый торган **Якушев** фамилияле зур нәсел бар. Мәгълүм ки, бу фамилия урысларда да еш очрый. Ләкин моңа нигезләнеп кенә аны урыс сүзеннән килеп чыккан, дип әйтеп булмый. Түбән Новгород өлкәсендәге татар-мишәр бабаларыбыз арасында да Якуш исемле кешеләр булган. «Якуш» сүзенең «Якуп»ны бозып әйтү сәбәпле барлыкка килүе бик тә мөмкин. Түбән Новгород татар-мишәрләрендә урыслашучылар да шактый. Шуннан Якушев фамилиясенең урысларга кереп китүе бер дә гаҗәп түгел. Загирҗан Сафиулла улы Якушевның әйтүенчә, йомышлы татар Якуш Санкт-Петербургтан Шыгырдан авылына патша армиясендә гренадер булып 25 ел хезмәт иткәннән соң кайта. Шыгырданга чагыштырмача якын урнашкан Алатырда да гренадер полкы булган. Минемчә, Якуш бабайның безнең авылга 1700 елларда, ягъни Петр I заманында шуннан килүе дә мөмкин. Ул озын буйлы, таза гәүдәле булган. Якуш бабай, балалары булмаганлыктан, тәрбиягә ир угыл ала. Аңа Ибрай (Ибраһим) исеме һәм Якушев фамилиясе бирелә. Ибрайның 9 ир баласыннан безгә мәгълүм Якушевлар нәселе тарала.

Шыгырдандагы Калинин урамын элек **«Таз каумы урамы»** дип йөрткәннәр. Дөрестән дә ул урамда «таз» дип йөртелгән нәсел кешеләре яшәгән. Якушев фамилиясе белән йөрүче берничә гаиләне «таз» дип әле хәзер дә атап йөртәләр. Шыгырданда Тазов фамилиясен йөртүче кешеләр әле дә бар. Таз сүзе татар, гомумән, төрки халыклар яшәгән һәр җирдә киң таралган һәм безгә шактый борынгы чорлардан калган истәлек ул.

Шыгырдан авылында **Чумар** кушаматлы һәм Чумаров фамилияле нәсел кешеләре дә бар. Галимнәр әйтүенә ышансак, «чумар» сүзе сувар этнонимындагы «с» авазының «ч»га тарихи күчеше нәтиҗәсендә килеп чыккан.

Авылыбыздагы Зөлкарниев фамилиясенең дә тарихы шактый кызыклы һәм борынгы заманнарга кайтып кала. Болгарларда, кыпчакларда үзләренең Зөлкарнай (Искәндәр Македонский) нәселеннән килеп чыкканлыгы турында риваять бар. Борынгы бабаларыбызның Кара диңгез буйларында греклар белән тыгыз мөнәсәбәттә булганлыгы тарихта билгеле. Шул төбәкләрдән Идел-Урал буйларына күчеп килүче кайбер татар кабиләләре үзләренең борынгы бабаларын Зөлкарнай дип күрсәтә. Бу очракта алар үзләрен Искәндәр Македонскийның данын дәвам итүчеләр итеп күз алдына китерергә теләгәннәр булса китәк.

1870 елдан муллалар алып барган метрика кенәгәсенә игътибар итсәк, анда Үзбәков, Хамбиков, Сүлтиев, Әхсәнов, Якупов, Хәбибуллин һ.б. фамилияләрнең еш очравын күрәбез. Үзбәков фамилиясенең бик борынгыдан ук килгәне мәгълүм. 1282-1341 елларда Алтын Урда тәхетендә Үзбәк исемле хан утырган.

Авылыбыз берничә өлешкә бүленгән. **Урталык** – Чишмәле, Майлы һәм Юхма елгалары арасында. **Колай очы** – Майлы һәм Юхма елгалары буенда. **Уби ягы** (Интернациональ урамы) – Юхма елгасының сул ягында. **Кәҗә урамы** Юхма елгасы түбән агымының уң ярында урнашкан. Тагын **Шакмак очы** (бүрәнәләрдән кисеп ясалган 60-70 см озынлыктагы шакмакларны җиргә батырып, юл салганнар), **Югары оч, Яшьләр урамы** һ.б. атамалар да бар.

Һәр атама борынгы тарихка барып тоташа. Кайберләренең килеп чыгышын ачыклыйк. Кәҗә урамына беренче килеп утыручылар «кәҗә» кушаматлы нәселдән булган. Алар әле хәзерге көндә дә үзләренең нәсел исемен югалтмаган. Колай очына беренче килеп утыручы кеше – колай нәселеннән. Метрика кенәгәсендә хәзерге «Минһаҗ мәчете» мәхәлләсендә Колай исемле кешенең яшәгәнлеге теркәлгән. Риваятьләргә караганда, аның йорты Майлы елгасы буенда, хәзерге Атаказовлар торган урында булган. Бу урамга беренче килеп утыручы кеше дә ул. Хәзер Колай нәселен дәвам итүчеләрне белүче юк. Ркаил Зәйдуллинның фараз итүе буенча, «Колай» атамасы «Кәләй» сүзеннән килеп чыккан. Ә «Кәләй» – Кәлимулла исеменнән кыскартып ясалган кушамат.

* * *

Шыгырданда яшәүче йомышлы татар Сүендек Булаев һәм аның иптәшләре белән Юхма елгасының югары өлешендә урнашкан Уби һәм янәшәдәге Шигали чуашларының җир өчен бәхәсләре 1666 елда судта тикшерелүе турында документ бар. Чыганакта Уби чуашларының дәүләткә салым түләп торуы, Шигали авыл кешеләренең аларның җирләреннән файдалануы, ә шыгырданлыларның бу җирләр аша терлек йөртүләренә ризасызлык белгертеп, Сембер воеводасына мөрәҗәгать итүләре турында әйтелә. Суд Шигали һәм Шыгырдан кешеләре файдасына тәмамланган. Моннан күренгәнчә, Уби чуашлары Юхма елгасы буена килгән вакытта ук Шыгырдан зур авыл булган, халкы 1666 елда тирә-яктагы җирләрне үзләштереп бетергән. Әгәр Уби чуашлары элегрәк килгән булсалар, алар Юхма елгасының югары өлешенә барып урнашмаган булырлар иде. Аңлашыла ки, алар килгәнче үк Юхма елгасының урта һәм түбән өлешләренең ике ягы – иң матур һәм тормыш итәргә җайлы урыннар татарлар тарафыннан үзләштерелгән булган.

* * *

Шыгырдан авылына кайсы төбәктән һәм кемнәр килеп нигез салганлыгы, бу вакыйганың кайчан булганлыгы турында да бездә әлегә кадәр саллы дәлил юк. Алда әйтелгән фикерләрнең берсен генә яклап чыгасым килә. Тарихи чыганакларда авылыбызның исеме «Шахардан» (Шихардан) яки «Шагардан» (XIX һәм XX гасырларда «Шихирдан») дип язылган. Муллалар тарафыннан да авылыбыз «Шагардан» дип теркәлгән. «Шагардан» һәм «Шыгырдан» исемнәре охшаш яңгырашлы. Димәк, авылыбызга нигез салучылар да Шаһигардан (Шәйгәрдән, Шаһигәрдән) җитәкчелегендәге кешеләр булган. Шаһигарданны морза, кенәз яки башка статустагы кеше булгандыр, дип уйлыйк.

Риваятьләргә караганда, Шыгырданга Түбән Новгород өлкәсенең Сергач районындагы Маклаково авылыннан күчеп килүчеләр нигез салган. Маклаково авылының болгар чорыннан ук билгеле булуы турында фәлсәфә фәннәре кандидаты А.М.Орлов яза. Шыгырдан авылындагы Хәкимовлар нәсел чылбырында Муклаука (Маклаково авылыннан килгәнгә күрә) кушаматлы кеше булган. Абдрахманов Минсәит әнисенең нәсел-нәсәп турында гарәби язулы дәфтәрендәге текстта үзләренең нәселендә Муклаука кушаматлы кешенең теркәлгәнлеге турында әйтә. Маклаково авылы халкы сөйләмендә булган кайбер сүзләр Шыгырданнан башка бер генә авылда да очрамый. Шыгырдан һәм Маклаково мишәрләренең гореф-гадәтендә, төс-кыяфәтендә дә охшашлыклар шактый.

1949 елда Батыр педучилищесының беренче курсында укыган вакытта тарих фәне укытучысы безгә үз авылларыбызның тарихын язып килергә кушкан иде. Мин авылның нигез салыну вакыты турында Сагадетдин мулладан сорадым. Аның Шыгырданга 500-600 яшь чамасы дип әйткәне хәтердә. Нәрсәгә нигезләнеп шулай диде икән? Кызганыч, ул вакытта аңа андый сорауны бирергә башыма килмәгән. Сагадетдин мулла бик укымышлы, зыялы кеше иде. Ул Шыгырданга XIX гасырның ахырында килгән. Бу вакытларда иске каберлектә язулы бик күп кабер ташлары яхшы хәлдә сакланганын беләбез. Ә кабер ташларындагы язмаларны мулла кеше, әлбәттә, бик яхшы укыган. Бикчурин Минсәит тә бабасы Садретдинның (Цатан Садрый) Шыгырдан авылы төзелүгә 600 ел дип сөйләгәнен яхшы хәтерли.

Шулай да, Шаһигардан бабай һәм аның җитәкчелегендәге кешеләр авылыбызга кайчан нигез салды икән? Урмай, Чүте (1476), Кара-Китә (1440), Кырык Садак, Татар Тимәше һәм башка авыллар XV йөзнең икенче яртысы-XVI йөзнен башында, ягъни Казан ханлыгы чорында төзелгән. Шәҗәрәләр буенча да (хәзерге көнгә кадәр 11 буын билгеле) Шыгырдан авылына Казан ханлыгы вакытында нигез салынганлыгы раслана. Шыгырданның Казан ханлыгы вакытындагы авыллар исемлегендә булуын да исәпкә алып, аңа нигез салынган елны төп-төгәл яза алмасак та, XV гасырның ахырында яки XVI гасырның башында Түбән Новгород якларыннан ирекле рәвештә күчеп килгән татар-мишәрләр тарафыннан төзелгәнлеген әйтә алабыз. Шыгырдан авылының барлыкка килү вакытын символик рәвештә 1500 ел дип билгеләсәк, дөрес булыр, минемчә. ■

«Хатын-кызның күрке – яулык»

Тәнзилә Шәйхнурова

Күзкәй авылы китапханәсендә узган очрашу-кичә шулай дип аталды. Ул хатын-кызларыбызның милли баш киеме – яулык һәм шәлләр турында иде. Зал күзнең явын алырдай аллы-гөлле бизәкле яулык, шәльяулык, шәлләр белән бизәлгән. Нинди төсләр, нинди фактуралар гына юк анда! Авылдашлар төрле вакыйгалар белән бәйле, сандык төпләрендә 50-60 ел буе изге бер тарихи истәлек булып сакланган яулыклар алып килгәннәр. Китапханә мөдире буларак, кичәне яулык тарихы белән таныштырудан башладым.

...Урысларда яулыклар XVI-XVII гасырда ук барлыкка килгән. Ул чагында ул «канаватка» дип аталган. Алар, зур итеп, юка ефәктән тегелгән. Яулык, бүләк булып, әнисеннән – кызына буыннан-буынга күчкән. XVIII гасырда Россиядә яулыкларны

Мәскәү мануфактураларында эшләнгән ефәктән теккәннәр. Чигү, бизәкләр төшерү гадәткә кереп киткән. Авыл хатын-кызлары исә яулыкны үзләре ал һәм ак төстәге ситсыдан теккәннәр, бизәкләп чиккәннәр.

Яулыкларда татар халкының тарихы да чагыла. Элегрәк әби һәм әниләребез башларына өрпәк (өчпочмаклы яулык) белән тастар (ак киндердән киселгән озынча яулык) бәйләп йөргәннәр. Тора-бара фабрикада җитештерелә торган дүртпочмаклы яулыклар барлыкка килгән. Татар хатын-кызлары аны үзебезнең милли гореф-гадәтләргә туры китереп бөркәнгәннәр. Ике янәшә почмагын ияк астына бәйләп, яулыкны аркага таратып төшергәннәр. Бу иңбашларын каплап торсын өчен шулай эшләнә. Кызлар исә, хатыннардан үзгә итеп, яулыкның ике очын колак артыннан уздырып, артка чөеп бәйли, бит, муен, иңбашларын капламый. Яулык кына дисәк тә, аларда тарих чагыла: төсе, бизәкләре, тукыманың сыйфаты – һәрберсе үз чорының үзенчәлеге турында сөйли, халыкның сәнгать үрнәкләрен чагылдыра, һәрберсендә – милли бизәкләр. Ефәк җепләр белән чигелгән ак яулык хатын-кызның сафлык билгесе булган. Аны башыннан мәҗбүри тартып алу оят саналган. Заманында яулыкны бүләккә сатып алганнар. Шәһәрдән килгән кунак та, базарга барган крестьян да, ерак якларда хезмәтен тутырып кайткан ир-егетләр дә бүләк итеп яулык бирә торган булганнар. Кичәгә дистәләп яулык алып килгән Тәгъзимә Гыйззәтуллина бу турыдагы кызыклы бер истәлеге белән уртаклашты. Гашыйк булып йөргән классташы Германиядә армия хезмәтеннән аңа бүләккә яулык алып кайткан. Рәсимә Хәсәнова гаиләләрендә 50-60 ел буе сакланган яулыкларының һәрберсенең тарихын сөйләде. Бүләк ияләре – туган-тумачалар, әнкәйләр, дуслар үзләре юк инде, ә менә яулыклар кадерле бер истәлек булып саклана. Төптәнрәк уйлап карасаң, алар буыннар чылбырын бәйләп тора икән бит.

– Менә бу яулыкны 1974 елда каенанам Хәернурга бүләк итеп биргән идем, – диде Нәсимә Биктимерова, япон яулыгын күрсәтеп. – Ә менә бу тула шәлне 1950 елда торфчылар алып кайткан. Кышкы айларда элек, юлга чыксалар, бишмәт өстеннән менә шундый тула шәл ябынганнар.

Ул үзе белән алып килгән һәр яулыкның «биография»сен сөйләде. Мин исә җитмешенче елларда беренче хезмәт хакына әнием Миннегаянга алган яулыкны күрсәттем. Гомере буе колхозда эшләгән, алты бала үстергән әниемне сагынып искә алдым.

79 яшьлек Хәнифә әби ВӘҖИЕВА сөйләгәннәрдән:

«Бу яулыкка бер гасыр, ягъни 100 ел инде. Авылыбызда иң борынгы яулыктыр ул. Аны бабам Талип беренче герман сугышыннан (1918) исән кайту сөенеченнән әбием Бибисарага бүләк итеп алган. Юлда каян алгандыр, анысы билгесез. Ул заманда авылда мондый шәлъяулык булмаган. Чынлап та, бер гасырлык яулык, тишек җирләре – бәйләгән җепләре өзелгән урыннары булса да, әле дә матурлыгын җуймаган, чуклы ефәк – зур шәлъяулык, җилкәгә

Безнең мирас №6 июнь 2018

салсаң, шуып төшәргә генә тора. Билгеле, әби аны бик яратып бәйләгән, мәҗлесләрдә җилкәсенә салган. Бөек Ватан сугышында Талип бабай, аның улы – минем әти Вәгыйз дә башларын салганнар, ә яулык күңелләрне җылытып, истәлек булып һаман яши әле. Сугыш чорында ничек кенә авыр булмасын, ачка тилмермәсен (яулыкны ризыкка, икмәккә алыштыру мөмкинлеге булып та), Бибисара әби аны чит-ят кулларга бирмәгән. Күңелендә, бәлки, бабай кайтыр да, шушы яулыкны ябып аны каршы алырмын, дип өметләнгәндер, гомер буе ирен дә, улын да көтеп яшәде ул. Яулык әбидән әнием Бәгъдәнурга калган. Ул да, бу яулыкны бәйләп, бик күп ашларда булды, яңаданяңа яулыклары була башлагач кына, сандыкка салып куйды. Сандыкны еш кына ачып, андагы истәлекле әйберләрне барлыйм, хәзер инде бу яулык тарихын оныкларыма сөйлим. Ефәк нык бит ул, әле тагын бер гасырлык ядкәр булып яшәрлеге бар».

Тәгъзимә ГЫЙЗЗӘТУЛЛИНА сөйләгәннәрдән:

«Күп балалы гаиләдә үскәнлектән, төпчек кыз булгач, миңа игътибар эләккән, әткәй-әнкәйнең дә, әбибабайның да яраткан кызы булганмын. Ерак әби Шәмсенур, бабай Шәйхеләгъзам авылда хәлле гаилә саналган. Бабай, 3 аты белән алмашлап, аръякка товарга йөргән. Авылдан ризык төяп алып китеп, Әгерҗе-Ижау якларында саткан яки товарга алмашкан. Авыл халкына кирәкле көндәлек товарны – төрле тукыма, шәл һәм яулыклар, ефәк, чәй, буяуларны шәһәр байларыннан, фабрикалардан алып кайткан. Ә әби тәмле ашарга, матур киенергә яратты. Мин – әбинең яраткан оныгы, эшләренә булышып, гел аларда кунып кала идем. Аларның ишегалды иркен: яшел чирәм үсә, уртасыннан су ага. Әби, чираттагы матур яулыгын ябып, күршеләренә яки аркасына кечкенә ак чүпрәк капчыгын асып, озын таягына таянып, магазинга китәр иде. Күлмәк итәге бик үк чиста булмаса да (чөнки тимер мич өстендә боламык пешерә яки күмер самавыры кайната), яулыгы һәрвакыт күз явын алырлык булды. Көнгә ничә тапкыр урамга чыкса, һәрберсендә яулыгын алыштырып чыга. Аның өчен яулык хатын-кыз күрке иде. Ә бабай алып кайткан товар арасындагы иң матур яулык аныкы гына, андый яулыкны авылда бүтән хатын-кыз бәйләргә тиеш түгел. Инде әбиемнең якты дөньядан киткәненә дә ярты гасыр, әни үлгәнгә дә 15 ел булды. Сандыкны ачкан саен, әбием һәм әнием бәйләгән яулыкларны кулга алып сыйпыйм, исним – үзәк өзелеп, бала чаклар искә төшә. Җитәр-җитмәс тормышта яшәсәк тә рәхәт иде. Табигать чиста, ризык тәмле, кешеләр ихтирамлы, чиста күңелле булган. Ләкин барысы да еракта калган, инде хәзер элек укылган әкият кебек кенә тоела».

Зәрия ХАФИЗОВА сөйләгәннәрдән:

«Әтием Хафизов Акмалны, 1945 елны сугышта яраланып 4-5 ай госпитальдә яткач, яңадан сугышка керерлеге булмагач, авылга кайтарып җибәргәннәр. Яралы солдатның биштәрендә зур шакмаклы шикәр, консервлар булган. Шулвакыт поездга бер баласын күтәреп, икенчесен җитәкләп чегән хатыны керә, хәер сораша башлый. Биштәрнең зурлыгын чамалаган хатын, аз гына йөри дә, яңадан әти янына әйләнеп килә икән, шулай берничә тапкыр кабатланган. Әтинең дә кайтасы җире ерак, авылда да ач балалары көтә, биштәрен бушатасы килми. Шулай да түзми, бер шакмак шикәрен алып бирә. Хәерчегә якты чырай күрсәтсәң... Чегән хатыны әтигә күрәзәлек итә башлаган һәм, җитмәсә, җилкәсендәге кара җирлеккә зур кызыл чәчәкләр төшкән яулыгын салып биргән, шуннан соң инде ярты биштәр бушап калган. Әтинең исән кайтуына бер сөенсә, матур яулыкка икеләтә сөенә әнием Кәнҗелбанат. Бик яратып, кунакка барганда гына кадерләп бәйләде аны әни. Әти дә, исе китеп, чегән хатынын кабат-кабат искә төшерә иде. Барлык юраулары да төп-төгәл юш килде бит, балалар санын да, эшне дә, тормышны да ничек шулай төгәл әйтергә була, дип еш кабатлый иде. Әти дә, әни дә мәрхүмнәр. Ә яулык исән, кадерле истәлек булып гаиләдә саклана. Чегән хатыны да ризалык белән биргәндер яулыгын, бәлки шушы яулык аның балаларын ач үлемнән саклап калгандыр. Чөнки без бик бәхетле гаиләдә үстек, хәзер дә булганына шөкер итеп, оныклар тәрбиялибез. Яулык тарихын барлык балалар да, оныклар да белә».

***

Истәлекләр, истәлекләр... Яулыклар аша чорлар белән чорларны бәйләдек, узганнарга кайтып килдек. Хәтта сугыштан соңгы авыр елларны, торфчы кызларны да сагынып искә алдык. Хак әйтәләрдер: тарих яшәгәндә, йолалар сакланганда – милләт яши. Әнә, яулыклар белән бәйләп, күпме истәлекләрне яңарттык, бакыйлыкка күчкән газиз кешеләребезне искә алдык, яулыкка багышланган җырларыбызны яңарттык. Баянчыбыз Марсель Биктимеровка ияреп, «яулык» сүзе кергән күпме җырыбызны искә төшердек. Китапханә эче гөр килеп торды.

Гөлсинә Зыятдинова белән Тәнзилә Гарәфетдинова төрле рәвештә яулык бәйләү ысулларын күрсәтте. Ни әйтсәң дә, яулык хатын-кызны бизи, үзенә генә хас образ тудыра. Истәлекләр, яулыклар тарихы әле чәй өстәле янында да бик озак дәвам итте. ■

Мансур авылы

Курган өлкәсенә узган елгы сәфәребез вакытында Сафакүл районындагы Мансур авылына килеп керүгә, игътибарыбызны агачтан затлы итеп салынган мәчет җәлеп итте. Аның имам-хатыйбы ***Миндель Хәйбулла улы Рәҗәпов*** *безгә дини вазгыять һәм авылның тарихы турында менә нилэр сөйләде:*

– Мәчетебез 2009 елда «Ямалдорстрой» АҖ Президенты **Марс Әхмәт улы Гайнетдинов**ның матди ярдәме белән салынды. Шуңа да ул мөхтәрәм иганәченең әтисе – Бөек Ватан сугышы ветераны, Ватан сугышы ордены кавалеры, әле кайчан гына «Красная Заря» колхозының рәисе булып, аның данын югары күтәргән зат – **Әхмәт Мөхәррәм улы** исемен йөртә.

Җәй көннәрендә мәдрәсәдә балалар укытабыз. Шәкертләребез Сафакүлдә

узган олимпиадада өченче урын алды. Мәчетебездә, дини бәйрәмнәрдән тыш, никах, балага исем кушу мәҗлесләре дә уза.

Урта мәктәптә, Мансур авылы балалары белән бергә, Атҗитәр һәм Некрасовкадан килеп, барлыгы 86 укучы белем ала. Балалар бакчасында 25ләп бала бар. Мәктәптә татар теле дәресләре дә укытыла.

Авылыбызга XVIII гасырда Мәүлет яки Мансур исемле кешеләр нигез салган, диләр. Шунлыктан, төрле чорда ул төрлечә – «Мәүлет», «Урта авыл», ә соңрак «Мансур» дип йөртелгән. Аңа нигез салынуның төгәл датасын тарихчылар төрлечә яза. Зиратта Мансур Тукаев исеме язылган кабер ташы бар. ■

Яңа Зимничә авылында борынгы мәчет. Хәзерге көнгә сакланмаган

КУЛАТКЫ СУФИЛАРЫ

Иршат Сафин*

Соңгы эзләнүләрем нәтиҗәсендә бик кызыклы факт ачыкланды: безгә билгеле булган Хәбибулла Хансәвәровтан кала, 1780 еллардан башлап яшәгән Әхмәр ишан Мастяки һәм 1915 елда бакый дөньяга күчкән соңгы ишан Абделманнан Курмакаевка хәтле 120-130 еллык чорда егерме авылдан торган хәзерге Иске Кулаткы районында тагын җиде ишан яшәгән. Бу, миңа калса, феноменаль хәл. Мәкаләмдә шулар турында сөйләргә телим, ә иң мәшһүрләрдән булган Хәбибулла ишанның тормыш юлы һәм эшчәнлеген бәян кылуны киләсе саннарның берсенә калдырыйк.

ӘХМӘР МАСТЯКИ

Иске Мастяк авылында туып үскән һәм шул авылда имам булып торган Әхмәр ибне Хәсән әл-Мастяки турында мәгълүмат бик аз. Бабасы Колмәт (Колмөхәммәд) икәнлеге билгеле. Укыган җире – Оренбург тарафында, бәлки бу төбәктәге танылган Каргалы авылындадыр, чөнки ишанлыкка аны шундагы күренекле имам Вәлид хәзрәт кертә.

---

* **Иршат Сафин** – Самара җәмигъ мәчете имам-хатыйбы, төбәкне өйрәнүче.

Шәкерте Әхмәр турында белмәсәк тә, остазы Вәлид ишанның кем икәнлеген белгәнгә, укучысы турында да бераз хәбәр алган булырбыз.

Вәлид Мөхәммәдәмин улы Дагыстанда һәм Бохарада укыган, ә ишанлыкка иҗазәтне бүгенге Әфганстанның башкаласы Кабул шәһәрендә яшәгән бик танылган шәех – Фәезхан Хозурхан улы биргән. Вәлид хәзрәтнең шәкертләре һәм аңардан суфичылык-ишанлыкны алучылар арасында башка күренекле татар имамнары да бар. Гобәйдулла Кизләви, Габделҗәббар Тайсугани – шундыйлардан. Әхмәр ишан да бу галимнәр белән аралашкан һәм дус булган, дип уйлый алабыз.

Нәселен дәвам итүчеләрнең эзенә төшә алмадым әле. Тик углы Мөхәммәдшәрифнең үзе урынына имам булганлыгы төгәл билгеле. Әхмәр Мастякиның Зимничәдәге атаклы ишан Хәбибулла Хансәвәров белән дә аз гына бәйләнеше бар. 1850 елларда ул Иске Мастякка барып, Әхмәр хәзрәт варисларыннан аның «Тәүзых» исемле фикыһ китабын сатып алган. Иске Кулаткы җирендә безгә билгеле булган беренче суфичылык үзәге – Иске Мастяк авылында Әхмәр ишан ачкан мөрит-дәрвишләр түгәрәге, ягъни үзе имамлык иткән мәчеттер. Атаклы ишан 1812 елда вафат булган.

АББӘС МУСАВИ

Кулаткы төбәгендә икенче суфичылык үзәге – Муса авылы һәм аның имамы Аббәс ибне Абдеррафиг ибне Кучкар әл-Мусави тоткан мәдрәсә. Аббәс хәзрәт турында да мәгълүмат аз. Р.Фәхреддиннең «Асар»ендә язылганнарга караганда, ул Муса авылында туган, башта үз авылындагы Сөләйман исемле кешедә дәрес укыган, соңыннан Казан төбәгендәге Өлге авылында, аннан Оренбург ягындагы күренекле Сәгыйд бистәсендә танылган дин галиме Габдерахман әл-Кирмани мәдрәсәсендә белем эстәгән. Шунда укыганда Оренбург төбәгенең Рәдуд авылыннан чыккан танылган Шаһиәхмәд ишан белән танышып, дәресләренә йөргән, аның мөрите булып киткән һәм үзе дә аңардан ишанлыкка рөхсәт алган. Аббәс хәзрәт, туган авылына кайтып, бердәнбер мәчеткә имам булып сайланган һәм мәдрәсә ачып укыту эшен дә оештырып җибәргән. Әмма 1837 елда 49 яшендә вафат булган. Муса авылындагы бер мәчетнең төрле елларда эшләгән барлык имамнары да – бу кешенең балалары, онык һәм онықчыкларыдыр. Муса хәзрәтнең мәдрәсәсе тирә-якта танылган уку йортларыннан саналган. Бик бай китапханәсе дә булганлыгы сөйләнә, тик барысы да янгын нәтиҗәсендә юкка чыккан.

ҖӘФӘР КУЛАТКЫЙ

Җәфәр (Җәгъфәр) Сәләй углы әл-Кулаткый әл-Болгари, башлангыч белемне туган авылында алганнан соң, Казандагы «Апанай» мәхәлләсе имамы Мөхәммәдкәрим хәзрәт Габдерәхимов мәдрәсәсендә укыган. Мәдрәсә җитәкчесе Салих Сәгыйть улы Җәфәрне Бохарага юллаган. Бохарада ул Кабул ишаны Фәезханның гыйлемле бер шәкертендә белем алып, Урта Көнчыгыш илләренә юнәлә, Дамаск (Дәмәшек), Багдад, Каһирә, Мәккә һәм Мәдинә калаларында 12 ел йөреп, бу шәһәрләрдәге мәдрәсәләрдә дә укый. Чит җирләрдә 18 ел яшәп, 1834 елны Иске Кулаткыга кайтып төшә. Монда шәкертләр укытып, ишанлык итә, күп санлы мөритләр тәрбияли. Аның мөритләре арасында танылган татар мулла-ишаннары, мәсәлән, Тинчәле хәзрәте Габделлатиф Яхудә улы, Бидәнги авылы мулласы Габделлатиф Халид улы, Иске Задур авылы имамы Фәтхулла хәзрәт бар. Р.М.Кадыров «Старину хранящая сторона (из дневника экспедиции)» исемле мәкаләсендә Түбән Новгород төбәгендәге татар авылларында да Җәфәр ишанның бик абруйлы икәнлеге турында яза: *«Джафар аль-Булгари — шейх ордена Накышбандия, был самым почитаемым муршидом (духовным наставником) сергачских*

мусульман. На краях рукописи, найденной во время археографической экспедиции в конце 1980 годов в селе Чембилей, написано, что уважаемый шейх «благословенными ногами ступил на землю села Медяны, после некоторого пребывания направился в Чембилей. Даже одна эта запись ясно свидетельствует о неподдельном уважении, которым пользовался Джафар аль-Булгари у сергачских мусульман». Ризаэддин Фәхреддин Җәфәр ишанның мөритләре арасында башкорт һәм казакълардан да күп кеше булганын әйтә.

Оренбург ишаны Шаһиәхмәд Радуди Кулаткыга килгәндә Җәфәр хәзрәт белән күрешә, озак сөйләшеп-аралашып утыра, аның белеменә таң кала. Баһаведдин Вәисев язуынча, Җәфәр хәзрәт бик тәъква һәм гадел кеше булган, матди байлык белән мавыкмаган, тирә-яктагы муллаларны дөнья белән артык мәшгуль булуда гаепләгән. Ул үзгә сүз һәм фикерләр дә әйткәләгән. Мәсәлән, күпләр патшаны яратмаса, Җәфәр хәзрәт аны мактаган һәм яклаган. Тирә-як, бигрәк тә Иске Кулаткы муллалары исә ишаннан көлгәннәр, аны бик кабул итеп тә бетермәгәннәр, әмма гыйлемле булуын хөрмәт иткәннәр. Әйтик, Иске Кулаткы бае Әюп сөекле кызы Голфарины аңа кияүгә биргән. Акчурин нәселенең затлы, зыялы байларыннан саналган Курамша да аның дусты булган. Ул үз акчасына Кулаткыда мәчет салдыртып, Җәфәр ишанны шунда имам итеп куйдырткан. Хәзрәт шул мәчеттә имам булып, мөритләр тәрбияләгән. Хатыны үлгәч, 1850 нче елларда тагын хаҗга дип чыгып киткән, әмма, сугыш булу сәбәпле, Кавказга кире әйләнеп кайткан, Дагыстанда, Грузиядә булган. Кавказда вакытта Шамилне тәнкыйтьләп, рус императоры Александрны яклаган. Мөселманнар күп булган Тифлиста (бүгенге Тбилиси) бик тә нәтиҗәле һәм тәэсирле чыгыш ясаган.

Чит илләрдә йөргәндә «Вәисовчылар хәрәкәте»нең җитәкчесе булачак Баһаведдин Вәисев белән танышкан. Ул исә Җәфәр ишанның мөритенә әйләнеп, Кулаткыга килгән һәм биредә озак еллар остазы мәдрәсәсендә яшәгән. 1862 елның 16 декабрендә 74 яшьлек Җәфәр хәзрәтнең вафатыннан соң, аны бик тә яраткан һәм хөрмәт иткән Баһаведдин патшага хат язган. Хатында ул остазын мактап, аның патша хөкүмәтен яклап сөйләгәнен искә ала һәм кабере өстенә мәкбәрә-мавзолей кебек нәрсә төзер өчен акча сорый, ә үзен анда сакчы итеп куюны үтенә. 1864 елны Баһаведдин патшага икенче «Всеподданнейшее прошение» язган, тик аларның берсенә дә җавап булмаган. Җәфәр хәзрәт кабере өстендә бик зур таш хәзер дә бар, аны Баһаведдин Вәисев язып куйдырган булырга тиеш. Язуы сөртелә-бозыла башлаганга, соңыннан да майлы буяу белән буялганга, таштан берни дә укылмый.

Җәфәр ишанның берничә баласы булган. Кызы Бәдигелҗамал Иске Кулаткы имамы Таҗеддингә кияүгә чыккан. Аларның уллары Зариф та (Мөхәммәдзариф бине Таҗеддин) имамлык хезмәтен дәвам иткән.

АБДЕННАСЫЙР ЗИМНИЧӘВИ

Абденнасыйр Абдессәлам улы Абдессәламев (Әбсәләмов) Зимничәви башта Муса авылындагы Аббәс хәзрәт Рафиков мәдрәсәсендә укыган. Соңыннан, Татарстан җиренә китеп, Мамадыш төбәгендәге Сөн авылында күренекле имам Фәхреддин ишан Мөхәммәдсадыйк улы мәдрәсәсендә белем эстәгән. Зимничәгә килгән оренбурглы Шаһиәхмәд ишан аңа суфилыкка иҗазәт биргән. Абденнасыйр хәзрәт кокандлы Йосыф хәзрәттән дә ишанлыкка рөхсәт алган.

Элеккеге укучысы Ибраһим Шибай улы остазы Абденнасыйр Абдессәлам улы турында менә ниләр сөйләгән: *«Гомерен укыту белән уздырды. Бик диндар, Аллаһтан курка торган зат иде, шәкертләренә төрле дәресләр укытты. Бик оста итеп гарәп теле сарыфы (морфология) һәм нәхүе (синтаксис) укыта иде»*. Абденнасыйр хәзрәт 78 яшендә, 1881 елда вафат булган. Урынына Җәләледдин исемле улы имам булып

калган. Ул токкан мәдрәсә зурлыгы буенча төбәктә өченче урында торган. 1891 елгы «О магометанских школах, находящихся в ведении Саратовской дирекции народных училищ» исемле чыганакта аның мәдрәсәсендә йөз шәкерт укуы турында хәбәр бар.

ИБРАҺИМ БИГИ

Россиянең танылган мөдәррисләреннән саналган Ибраһим бине Шибай әл-Биги 1828 елны Биги (Яңа Терешка) авылында туган. Башлангыч белемен Зимничәдәге Абденнасыйр хәзрәт Абдессәламовның мәдрәсәсендә алган. Сәет бистәсендәге Габделкәрим Габдеррәфиг хәзрәт һәм Юлкы авылындагы Мөхәммәдшәриф Габделлатыйф хәзрәт мәдрәсәләрендә укып кайткач, 1859 елны Биги (Яңа Терешка, бүгенге Урта Терешка) авылының мәчетенә имам итеп куелган. Үз мәхәлләсендә мәдрәсә ачып укыта башлаган һәм күп шәкертләр җыйган. Ике мәртәбә хаҗга барган. Башта суфичылыкка каршы чыгып, авылдагы Абделмәннан ишаннан читләшеп йөрсә дә, икенче мәртәбә хаҗга баргач, кайтышлый Истамбулга кереп, анда бик олы һәм күренекле суфи, шәех Әхмәд Зыяэддин Көмешханәвигә мөрит булган һәм аңардан иҗазәт алган.

Ибраһим хәзрәтнең мәдрәсәсе зур булып, шәкертләр саны буенча Кулаткы төбәгендә икенче урында* торган. 1891 елгы документтан күренгәнчә, мәдрәсәдә бервакытта 150 шәкерт укыган. Дәрәҗәле имам-хатыйп һәм мөдәррис булганга, зур татар муллалары һәм абруйлы байлары белән дустанә мөнәсәбәттә яшәгән. Әйтик, Ризаэддин хәзрәт белән берничә мәртәбә күрешкән, Зөябаштагы Акчуриннар, Пензадагы Дебердиев байлар белән дә аралашкан. 1900 елны 74 яшендә дөнья куйган Ибраһим хәзрәтнең урынына улы Имадеддин (Гыймадеддин) имам булып калган.

РАМАЗАН САРАТАВЫЙ

Суфичылык турындагы белешмәлекләрдә «Рамазан әс-Саратавый» (Саратовлы) дип йөртелгән һәм районыбызның Югары Терешка авылында туган Рамазан Алиәкбәр улының хаҗга баруы билгеле. Ибраһим ишан Шибаев белән аның суфичылыкны кабул итмәгән елларында тартышканы Р.Фәхреддиннең «Асар»еннан билгеле. Димәк, Рамазан ишан әс-Саратавый Ибраһим хәзрәт Шибай-әл-Биги белән бер елларда, ягъни XIX гасырда яшәгән. Аның кабере районыбызның Югары Терешка авылында.

АБДЕЛМАННАН БИГИ

Соңгы чор ишаннарыннан Абделманнан Корбанали улы Курмакаев та Яңа Терешка (Биги) авылының икенче мәчетендә имам булып хезмәт иткән. Кулаткы төбәге ишаннары арасында иң яше булуга карамастан, әлегә бу кеше турында мәгълүмат юк диярлек. Ике улы – Абдерәүф белән Шаһиазамның имам булып хезмәт итүләре билгеле. ■

---

* Беренче урында – Хәбибулла ишан Хансәвәров мәдрәсәсе. Бу турыда, әйткәнебезчә, киләсе саннарның берсендә язылачак.

№17-18 534

гор. Чистополь Кантземотдел плодов. питомнику.

почт. отд. Рыбная слобода Лаиш. к. село Масловка плодпитомнику.

гор. Елабуга КЗО плодпитомнику.

ТАССР 100 ЛЕТ
Празднование 100-летия Татарской АССР
Татарстан АССР төзелүнең 100 еллыгын бәйрәм итү

ТАТАРСТАНДА
ВАКЫТЛЫ МАТБУГАТ

Гали Рәхим[1]

1917 ел революциясеннән соң татар телендә вакытлы матбугат электәгегә караганда зур адымнар белән алга китте. Русиянең татарча гәзит чыкмаган кечкенә генә бер почмагы да калмагандыр, аз гына татар булган шәһәрләрдә, бөтен сугыш фронтларында гәзитләр чыкты. 1905 елдан 1917 елга

[1] Гали Рәхимнең бу мәкаләсе «За 5 лет к V годовщине провозглашения ТССР» исемле китапта рус һәм татар телләрендә басылган. – *Ред. иск.*
[2] Җирле телләрдәге, Кырым, Кафказ, Төркестан матбугаты бу хисапка керми. – *Авт. иск.*

чаклы 12 ел эчендә татар телендә[2] (бер үк гәзитнең төрле исемдә чыкканнарын да аерым гәзитләр итеп санаганда) барысы 31 исемдә гәзит, 26 журнал чыккан булса, 1917 ел революциясеннән соң сигез ел эчендә чыккан гәзитләрнең саны берничә йөздән, журналларның саны 50дән артык. 1917 елга кадәр Казанда «Кояш» белән «Йолдыз» гәзитәсе генә дәвам итеп бара иде. Революциядән соң хәзергә кадәр түбәндәге гәзитләр чыкты:

Чыккан елы	**Газетаның исеме**	**Мөхәррире яки нашире**
1917	Аваз	Шәһид Әхмәдиев (эшчеләр гәзите)
\-\-\-\	Кызыл Байрак	Мөселман социалистлар комитеты (Мулланур Вахидов гәзите)
\-\-\-\	Корылтай	Корылтай ширкәте – Милли Шура
\-\-\-\	Безнең тавыш	Хәрби Шура
\-\-\-\	Игенче	Губерна земствосы
1918	Эш	Мөселман комиссариаты
\-\-\-\	Идел-Урал өлкәсе	\-\-\-\-\-\-\
\-\-\-\	Алтай	Корылтай ширкәте, Милли Шура
\-\-\-\	Чыңгыз баласы	Хәрби комитет
1919	Кызыл көрәшче	\-\-\-\-\-\-\
\-\-\-\	Кызыл Армия	Хәрби һәйәт (Мус. воен. комитет.)
1920	Татарстан хәбәрләре	Башта ревком, соңыннан ТатЦИК
\-\-\-\	Эшче	Русия коммунистлар партиясенең Шәрык халыклары мәркәзи бюросы
\-\-\-\	Кызыл яшьләр	Комсомол органы
1921	Хәбәрләр	«ПУР»ның шәрык шөгъбәсе
	Авыл хуҗалыгы сәхифәсе	Татарстан җир эшләре халык комиссариаты
1922	Татарстан	Татарстан башкарма комитеты
\-\-\-\	Безнең Байрак	Татарстан партия өлкә комитеты
\-\-\-\	Кызыл Татарстан	Татарстан башкармасы һәм партия өлкә комитеты
1923	Байтарлык сәхифәсе	Татарстан үзәк байтарлык идарәсе
1924	Кызыл Татарстан	Татарстан башкарма һәм партия өлкә комитеты
\-\-\-\	Крәстиән гәзите	«Кызыл Татарстан» гәзите янында
\-\-\-\	Яшь ленинчы	Пионерлар органы
\-\-\-\	Кызыл Армия	«ПУР»
\-\-\-\	Казан мал биржасы бюллетены	Казан мал биржасы комитеты

Менә бу 25 гәзитнең бары бишесе генә Үктәбер революциясенә каршы лагерьда булган гәзитләр. Совет, Үктәбер юлында татар дөньясында беренче гәзит Петроградта Вахидов, Ибраһимовларның катнашы белән чыккан «Чулпан» иде. Казанда «Эш» булды. Казанның үзендә чыкканнардан башка хәзерге көндә Татарстан эчендә булган кантон калаларында революциядән соң шушы гәзитләр чыккан:

Елы	Кайда	Исеме	Нашире
1917	Тәтеш	«Тәтеш оешмасы»	Тәтешнең татар оешмасы мөселман мәгариф шөгъбәсе. Басылуы Казанда
1918	Спас	«Халык теләге»	Мөселман мәгариф шөгъбәсе
1919	Чистай	«Үктәбер инкыйлабы»	
1921		«Берлек»	Чистай кантпечате
	Буа	«Яңа тормыш»	
1923	Мамадыш	«Киңәшче»	
	Минзәлә	«Игенче»	

Татарстан Җөмһүрияте төзелгәнче Казанда чыккан гәзитләрнең нык куелганы «Эш», «Эшче», «Кызыл Армия» гәзитләре иде. «Эш» көндәлек гәзит булып, 1918 елның 12 мартында чыга башлап, 1920 елның ахырына кадәр дәвам итте. «Эшче» 1920 елның февраль башында чыга башлап, ел ахырына кадәр чыккач, Мәскәүгә күчте. Атнага өч тапкыр чыга иде. Казанда вакытта тиражы 10 меңнән ким булмады. 15 меңгә кадәр басылган нөсхәләре булды. Мәскәүгә күчкәч, башта тиражы кечерәйгән иде (1923 елда 3 мең), соңгы елда тагын 12 меңгә менде. Хәзердә бу гәзитнең 2500ләбе Татарстанга килә. «Кызыл Армия» Казандагы мөселман Хәрби һәйәтенең органы булып, 10 меңнән 17 меңгә чаклы басыла торган көндәлек гәзит иде.

Татарстан җөмһүрияте төзелгәннән соң, 1920 елда хөкүмәтнең көндәлек органы булып «Татарстан хәбәрләре» гәзите чыга башлады. Исемен алмаштыра-алмаштыра («Татарстан», «Кызыл Татарстан») ул хәзергә кадәр чыгып килә. Яңа икътисадый сәясәткә кадәрле аның тиражы 7-10 меңнәр тирәсендә булып килде. 1922 елда 2-3 мең тирәсенә төште. Аннан соң арта-арта хәзерге вакытта 5-6 меңнәргә күтәрелде.

1922 елның үктәбереннән башлап 1924 елның мартына кадәр өлкә партия комитетының органы булып, атналык «Безнең байрак» чыкты. Бу мөндәриҗә *(эчтәлек)* ягыннан журнал характерындарак булган бер гәзит булып, тиражы 2 меңнән артты.

1920 елда комсомол органы «Кызыл яшьләр» чыга башлап тукталган иде. 1923 елда комсомолның өлкә комитеты тарафыннан яңадан чыга башлады. Тиражы 1000 белән 4000 арасында үзгәреп торды. 1924 елдан башлап пионерлар оешмасы тарафыннан «Яшь ленинчы» гәзите чыгарыла башлады. 1921 елдан башлап 1923 елның ахырына кадәр Наркомзем тарафыннан, «Игенче» журналына бер кушымта булып, «Авыл хуҗалыгы сәхифәсе» дигән гәзит чыгарылды. Бу сәхифә барлыгы 42 номер чыкты.

Хәзерге көндә бөтен Советлар Союзында чыга торган 18 татар гәзитеннән 7се Татарстанда чыга. Татарстанда чыга торган 16 исемдәге гәзитнең 8е – татарча, 6сы – урысча, 2се – вак милләтләр телендә (чуашча, мукшыча).

Хәзерге көндә Татарстанда татар телендә чыга торган гәзитләр шушылар:

1) **«Кызыл Татарстан»** – җөмһүриятнең рәсми органы, көндәлек гәзит.
2) **«Крәстиән гәзите»** – кечкенә кулда сигез битле, атналык гәзит.
3) **«Кызыл Армия»** – гаскәр өчен чыгарыла торган атналык гәзит.
4) **«Кызыл яшьләр»** – ВЛКСМның Татарстан өлкә комитеты органы, атналык.
5) **«Яшь ленинчы»** – пионерлар гәзите.
6) **«Казан мал биржасы»** – икътисадый гәзит, атнага ике чыга.
7) **«Игенче»** – Минзәлә гәзите.
8) **«Киңәш»** – керәшен гәзите, керәшен хәрефе белән басыла.

Безнең мирас №6 июнь 2018

Татарстанда чыгарылган төрле телләрдәге бөтен гәзитләрнең тиражы 1924 елның апрелендә 29 мең булган. Шуннан соң һаман арта килеп, 1925 елның апрелендә инде 77 меңгә җиткән. Хәзер Татарстанда урта хисап белән 35 кешегә бер гәзит туры килә. Гәзитнең иң күбе авылга тарала, гомумән, авылга китә торган гәзитләрнең санын тигезләп бүлгәндә 10 йортка бер гәзит, хәтта урыны-урыны белән 3 йортка бер гәзит тия (сирәк-сирәк кенә дүртәр-бишәр йөз гәзит ала торган волостьлар бар).

Гомумрусия күләмендә алганда да революциядән соң татар халкының гәзит укучысы әллә никадәр арткан. Электә һәрбер 500 татарга бер данә гәзит туры килгәндә, хәзердә һәрбер 82 кешегә бер гәзит төшә. Моның сәбәбе дә волость белән бергә гәзитнең дә халык (эшче-крәстиән) массасына якын килүедер. Электә гәзитне укучылар сәүдәгәрләр, руханилар, мөгаллимнәр булса, хәзер гәзитнең күбе эшче, крәстиән арасында тарала. Бер яктан гәзит теленең халык теленә якынлашуы, икенче яктан хезмәт ияләре массасының үз арасыннан чыккан (Татарстанда саннары ике меңгә җитә торган) хәбәрчеләрне гәзитләр тирәсенә җыю – тышкы һәм эчке яктан гәзитне халыкка якынлаштырды, массага кертте. Былтыр гына чыга башлаган, крәстиәннәрнең үз телләренә якын телдә языла торган «Крәстиән гәзите»нең таралуы аның авыл халкы арасында кирәклеген күрсәтә: соңгы вакытта бу атналык гәзитнең тиражы 18 меңгә җитте. Бу 18 мең нөсхә барысы да бушлай түгел, акчага тарала. Элекке заманда Казанда иң тарала торган гәзитләрнең дә тиражы 4 меңнән артмый торган иде. Әмма хәзердә бер Татарстандагы татар авылларында гына аз куйганда 25 мең чамасы гәзит тарала. Бу турыда без һич шөбһәсез бик зур тәрәккый – алга бару күрәбез. Басыла торган гәзитләр өстенә тагы язма, эстинә гәзитләрен дә өстәргә кирәк. Татарстанда төрле оешмалар тарафыннан чыгарыла торган эстинә гәзитләренең саны (урысча, татарчасы) 300гә җитә. Эстинә гәзитләре дә, әлбәттә, гади гәзитләр үтәгән үк хезмәтне үтиләр.

Журналларга килсәк, Казанда 1917 ел революциясеннән соң түбәндәге журналлар чыкты:

Чыккан елы	Исеме	Нашире
1918	Шәрык кызы	Русия мөслимәләре мәркәз бюросы
1918	Мәгариф	Гыйльми һәйәт, соңыннан Татарстан халык Мәгариф комиссариаты
1920	Кызыл шәрык	РКПБның шәрык халыклары коммунист оешмалары мәркәзи бюросы
1921	Кызыл дәфтәр	«ПУР» каршындагы Шәрык шөгъбәсе
	Игенче	Татарстан җир эшләре халык комиссариаты
1922	Безнең юл	Башта Татарстан Үзәк башкармасы һәм совнаркомы, соңыннан Татарстан мәгариф халык комиссариаты
\-\-\-\	Кызыл шәрык яшьләре	Комсомол
1923	Чаян	Көлке журналы
\-\-\-\	Үктәбер яшьләре	Комсомол («Кызыл шәрык яшьләре»нең дәвамы)

Боларның «Шәрык кызы»ннан башка һәммәсе – Үктәбер революциясе тудырган журналлар. Бу журналлардан хәзер тукталганнары «Кызыл дәфтәр» белән «Кызыл шәрык» кенә. «Кызыл дәфтәр» бер номер чыкканнан соң ук тукталды. «Кызыл шәрык» 1920 елның мартыннан 1921 елның апреленә кадәр ун номер чыгып тукталды. Бу «икътисадый-иҗтимагый, сәяси-назари, әдәби, фәнни айлык журнал» 1922 елда

идарәсе Мәскәүгә күчерелеп, яңадан бер номер чыкты, дәвам итә алмады. Бу номеры да Казанда басылган иде.

Хәзердә Татарстанда (Казанда) урысча һәм татарча барысы 9 төрле журнал чыга, шуларның 5есе – татар телендә.

1) **«Мәгариф»** – тәрбия, мәктәп, мәгариф эшләренә багышланган гыйльми, иҗтимагый һәм тәрбияви, урта кулда, айлык журнал. Ул иң элек 1918 елда гыйльми һәйәт тарафыннан чыгарыла башлаган иде. 1918-1919 елларда барысы 3 номер чыккач тукталып, 1921 елның апрелендә Татарстан Мәгариф халык комиссариатының нашири әфкяре буларак яңадан чыга башлады. Бик начар кәгазьгә басылып, тышсыз булып чыккан «Мәгариф» хәзердә матур, күркәм басылган, тотрыклы, калын, рәсемле бер журнал булып чыга. Һәр санына кушып китаплар да бирә. Басылуы 3 мең.



«Безнең юл» журналы. 1924 ел

2) **«Безнең юл»** – сәяси, иҗтимагый, гыйльми, әдәби айлык журнал булып, 1922 елның маенда чыга башлады. Башта кечкенә кулда чыга башлаган иде, 5 саннан башлап зур кулга күчте. 1923 елның мартыннан алып бу журнал Татарстан Мәгариф халык комиссариаты тарафыннан нәшер ителә башлады. 1925 елның башыннан алып РКПБ Татарстан өлкә комитетының агитация бүлеге тарафыннан чыгарыла. Бу журнал үзенең битләрендә нәфис әдәбиятка зур урын бирә. Соңгы вакытта рәсемнәр белән чыга башлады.

3) **«Үктәбер яшьләре»** – бу журнал Казандагы татар комсомол оешмасы тарафыннан 1922 елда «Кызыл шәрык яшьләре» исемендә чыгарыла башлаган иде. 1924 елда журналның исеме «Үктәбер яшьләре»нә әверелде, форматы урта кулдан зур кулга күчте. Ул Татарстан яшь коммунистлар союзының өлкә комитеты тарафыннан чыгарыла. Бу журнал нәфис әдәбиятка күп урын бирә, эчендә балалар почмагы да бар. Рәсемнәре дә була, техникасы яхшы. Тиражы – 1500. Хәзер бу журнал авылга йөз тотып, авылга якынлашып бара.

4) **«Игенче»** – Наркомзем тарафыннан чыгарыла торган авыл хуҗалыгы эшенә багышланган айлык журнал. Форматы – уртача. 1921 елның сентябрендә чыга башлап, хәзергә кадәр дәвам итеп килә. Тиражы хәзер – 4000.

5) **«Чаян»** – рәсемле айлык көлке журналы. Тиражы – 3200.

Татарстанда моңарчыга кадәр журнал эше бераз аксабрак килсә дә, соңгы елларда гомуми икътисадый күтәрелеш белән бергә безнең журналлар да тернәкләнеп киләләр. Материал төрләнүе, кызыклануы, журналларның элекке еллардагы шикелле гел сәяси мәкаләләр белән генә тулып чыкмыйча, нәфис әдәбиятка, тәнкыйтькә һәм төрле бабтан гыйльми-фәнни мәкаләләргә урынның күбрәк бирелүе шактый киң укучылар түгәрәген журналлар тирәсенә җыйды. Моннан алып Татарстанда журналларның тәртипле чыгып торуы тәэмин ителгән инде. Бөтен журналларның тиражы хәзер 15 меңгә басып килә. ■

Безнең мирас №6 июнь 2018

БЕЗНЕҢ ЗАМАН КАҺАРМАНЫ

Рабит Батулла

ЭШ КҮП – ҮЛӘРГӘ ДӘ ВАКЫТ ЮК

Ныклы тәртип булсын өчен
Һәр йортка хуҗа кирәк.

Вахит Галиев

Урысның күренекле язучысы Михаил Шолоховның «Күтәрелгән чирәм» романы каһарманы Давыдов белән булган аяныч хәлләр Казан өязендә дә кабатлана: Давыдовны авыл байлары үтерә, Мамадыш олысына кергән Уразбахты авылында 1932 елда читтән китереп куелган күмхуҗ рәисенең дә башына авылның усал бәндәләре җитә.

Шушы җинаятьне башкарганнарның нәселе әле дә булса Уразбахтыда яшәп килә икән. Алар колхоз рәисен кыйнап үтергән ата-бабалары белән әле дә булса мактанып, бу гамәлне токымның батырлыгы итеп сөйләп йөри, ди.

Чыннан да, Уразбахты – гайрәтле кешеләр яши торган авыл, анда колхоз җитәкчеләре озак эшли алмый, аларны йә куалар, йә алар үзләре китә. Уразбахтылардан хәтта Мамадыш милициясе дә шүрләп тора, диләр.

Ахыры. Башы журналның 3 нче (2018) санында.

Мамадыш райкомында алты бала атасы, запастагы офицер, кырык яшәр Вахит Галиевкә кемсәләр болай диде:

– Ай-һай, эшли алырсыңмы икән? Уразбахтылар башкисәрләр бит алар.

– Ничава! – диде Вахит Галиев. – Без дә Кара баганалы Комазанда туган!

Бу авылда яңа куелган җитәкчене беренче көннән үк «эшкәртә башлау» гадәткә кергәнен Вахит Галиев бик яхшы белә иде. Авыл белән берничә куәтле егет идарә итә. Уразбахтыга алар баш: яки син шуларның ише булып китәсең, алар ни кушса, шуны эшлисең яки син аларны җайлап-майлап, көйләп тормыш алып барасың, яки сине тукмап ташлаячаклар, кем кыйнаганын да белмәячәкләр, авыл үз серләрен башкаларга сатмый, яисә җыелыш җыеп, синнән баш тартачаклар, яки «булдыксыз, эшне тарта алмады», дип адәм көлкесенә калдырып, сине авылдан абзар себеркесе белән куачаклар.

Вахит Галиевкә теләктәшлек белдерүчеләр дә бар иде авылда, ләкин алар да тегеләрдән курка. Бу авылның астыртын җитәкчесе Рафил исемле, олы гәүдәле, батыр ир-егет иде. Үзенә күрә, «вожак». Авыл егетләре аның авызына гына карап тора...

Райком вәкиле яңа председатель белән таныштырганда клубка җыелган халык карсак буйлы Вахит Галиевне кабул итмәде.

– Буең ничә сантиметр синең, чебеш? – дип кычкырды кемдер.

Райком инструкторы Вахитның колагына:

– Бу аларның атаманы – Рафил!– дип пышылдады. – Сак бул!

Вахит, һич тә исе китмичә:

– Минем буй бер метр да алтмыш ике чамасы! – дип җавап бирде.

– Ә минеке метр сиксән сигез! – дип кычкырды атаман.

Шыгрым тулы клуб шартлардай булып көлә башлады.

– Бергә – ноль: Рафил файдасына! – дип кычкырды кемдер.

– Бусы – Рафилнең куштаны, ата ялкау Рәшит Усманов, – диде райком вәкиле.

– Авырлыгың күпме? – дип янә кычкырды Рафил.

– Алтмыш дүрт кило! – диде Вахит.

– Ә минеке туксан сигез!

– Рафил файдасына: икегә – ноль!

Халык, Сабан туендагы кебек, кул чаба башлады. Вахит Галиев, аягүрә торып басты да, кызыл җәймә капланган өстәлгә ике кулы белән таянып, Рафилнең күзенә туры карап әйтте:

– Колхоз малын ашый башлагач, мин дә, синең кебек, йөз килога җитәрмен әле! – диде.

Көтелмәгән бу кыюлык халыкка кызык тоелды, ахрысы, Вахитның үткен сүзлелеген хуплапмы, кешеләр янә кул чабарга тотынды.

– Икегә – ике! Ничия! – дип кычкырды куштан егет.

Шаярулар бетте. Җитди сөйләшү башланды.

Халык белән сәхнәдә утыручылар арасында киеренкелек упкыны хасил булды. Вахитны райком китереп куйды, халык нишләсен, ризасыз гына таралды.

Бу вакыйга 1976 елның гыйнвар аенда булды. Райком вәкиле яңа рәисне колхоз идарәсенә хәтле озата килде дә тыныч йокы һәм уңышлар теләп, китеп барды.

«Колхоз идарәсе» дип аталган бер җәбәхәер генә өй аның эш урыны да, ятак йорты да иде. Күрше бүлмәдә бухгалтерия утыра. Өй ягылмаган, өйалдында чи усак түмәрләре аунап ята. Яңа рәис йоклый алмады, суыктан түгел, җыелган халыкның җан өшеткеч салкын карашыннан өшегән иде ул. Бу сиңа Суслонгер салкыны гына түгел, бу сиңа кансыз командирларның солдатларны кыйнавы гына түгел, бу үз халкыңның кыйнавы

иде. Ләкин Вахит тәвәккәлләрдән иде. Салындырсаң, борын салына инде ул. Вахитның борыны бәләкәй түгел, ул зур бөркет борынлы, шушы бөркет борын астында сызылып киткән кара мыек, кап-кара кашлары астыннан үтәли тишеп чыга торган, бөркетнеке кебек үткер карашлы, йөрәкле адәм иде ул. Менә шушы тәвәккәл, йөрәкле кеше дә каушап калсын инде. Халыкның тискәре тәэсире аның кәефен кырган, шыксыз идарә өе (ул идарәгә түгел, котсыз каравыл өенә охшаган иде), таракан катып үләрек суык.

Кыска кайры тунын салмыйча гына, ул салкын агач урындыкка утырды. Тирән итеп көрсенеп алгач, кинәт кычкырып җибәрде:

– Яңа тормыш башлана, кадровый офицер, иптәш Галиев! Армиядә син танковый частьлар белән командовать иттең, инде хәзер тракторчылар белән командуй!

Күзенә йокы кермәгәч, ул урамга чыкты. Авыл инде йокыда. Салкын гыйнварда аяк астындагы кар шыгырдаганы әллә каян ишетелеп тора. Кемдер, зыңгылдап торган салкын карны шыгырдатып, бирегә таба килә иде. Кара-кучкыл шәүлә Вахит белән тигезләште дә туктады. Бу салмыш ир иде.

– Ныу! – диде салмыш ир. – Камытны кидең син, иптәш Галиев! Батыр кеше син!

– Ни булган? – диде Вахит.

– Кыю кеше, дим, сине! Синнән алдагы присидәтелләрнең караңгы төшкәч урамга чыкканнары булмады.

– Ни өчен?

– Өченки урамга чыгарга куркалар иде...

– Ә мин чыктым әле, һавасы әйбәт бит, туган... Кем әле син? – диде яңа хуҗа сабыр гына.

– Каравылга барам мин, пирмегә! – диде салмыш.

– Иптәш каравылчы! – диде Вахит. – Каравылга исерек килеш барырга ярамый бит. Икенчедән, син салып йөргәндә ферманнан бозавыңны алып чыгып китсәләр?

– Беренче көннән үк тешләргә уйлыйсыңмыни, Комазан күсесе! Монда теш куючылар да, теш коючылар да җитәрлек, иптәш присидәтел, – дип, бер дә исе китмичә генә юлын дәвам итеп, салмыш ир ферма ягына китеп барды.

Икенче көнне иртүк Вахит нәрәт җыйды. Салмыш каравылчы хакында, каравылны көчәйтү һәм фермада тәртип урнаштыру турында сабыр, әмма шактый кырыс тавыш белән идарә әгъзаларын кисәтте. Дәшмичә генә таралдылар.

Ул тагын идарә өендә ялгыз калды. Вахитны тагын авыр уй басты.

Ялгышамы ул бу эшкә алынып, ялгышмыймы – вакыт күрсәтер, ләкин артка чигенү юк. Уразбахтының басу капкасыннан борылып кайтып китү – җиңелү, үз язмышыңа үзең балта чабу булыр иде.

– Янсам, шушында дөрләп янам! – диде Вахит.

Сугарга теләгәнсең икән – кизән, кизәнгәнсең икән – сук, сукансың икән – үтер. Үтергәнсең икән, акланма, мин үтердем, диген! Аны атасы мәрхүм Миңлевәли абзый шулай өйрәтә торган иде. Атасының шушы тәвәккәл сүзе аның кәефен күтәрде.

– Алга, иптәш офицер! – дип кычкырды үз-үзенә яңа рәис.

Икенче көнне ул хуҗалык белән танышып йөрде. Юллар юк, бозауларга ашатырга курмы юк, техниканың яртысы ватык. Аның каравы, кичкә таба звено саен эчеш. Мужикларның төп максаты ничек аракы табу иде. Әбиләргә печән, салам, утын китертү – бер ярты, авылның валютасы – аракы...

Вахит Галиев таң әтәчләреннән дә алдарак уянды. Нәрәткә иң беренче кеше булып бер әби килеп керде.

– Балам, – диде әби, – ягарга утыным бетте. Берәр ат йөге утын китертергә, дип инде

әллә кайчан йөрим. Ялгыз карчык мин. Тракторчыларга – бер ярты, ат җигүчегә – бер ярты... Минем пенсиям бәләкәй, каян алыйм мин ул яртыларны. Кибетчедән аракы сораву да оят, намаздагы карчык бит мин...

Кояш чыкканда, Вахит әбинең бөтен узган гомерен белә иде инде.

Нәрәт җыелып беткәндә, әби китәргә дип калыкты:

– Әби, син китмә, утыр! – диде Вахит. Әби урынына утырды. Ярсыган иде ул, иң беренче нәрәт әбигә багышланган иде. Эчке ачуын тыя төшеп, Вахит сүз башлады:

– Катырып үтерәбезмени бу карчыкны! – диде ул.

Нәрәттәгеләр, яшенле яңгыр алдыннан тынып калган табигать кебек, сагаеп калды. Вахитның сүзе бик тәэсирле булды. Кемдер, кирәге булмаса да, тамак кырып куйды, кемдер утырган уңайга чалбар төбен ышкып алды.

– Гомере буе калхузга бил бөккән, ике баласын, ирен сугышка биргән шушы карчыкның ягарга утыны булмасын инде. Сез, өрлектәй егетләр, утын китергән өчен, шушы бичара карчыкның соңгы пенсиясенә аракы алдыртасызмы?! Оятыгыз кайда сезнең? – Яңа хуҗа кызганнан-кыза бара иде. – Ферма мөдире бармы?

Мөдир торып басты:

– Монда! – диде.

– Мәктәп мөдире кайда?

– Монда!

– Атың җигүлеме? – диде Вахит ферма мөдиренә.

– Капка төбендә! – диде ферма мөдире.

– Менә синә әби! Чанаңа утыртасың, әбине таракан катып үләрдәй суык өенә илтеп куясың. Мәктәп мөдире сиңа өлкән класслардан биш-алты егет бирә. Шул егетләр, өй борынча кереп, шушында утырганнарның каралтысыннан берәр кочак, парторг белән авыл советы рәисеннән икешәр кочак коры утынны чанага төяп, язга чаклы ягарлык утынны әбинең лапасына кайтарып, яхшылап өеп куя. Җәйдән үк ялгызларга утын әзерләмәсәгез, һәр кышны шулай булачак! Утын, печән китергән берәр тракторчы, ат җигүче калхуз аты, калхуз машинасы белән берәрсенә йөк китергәне өчен аракы алса, ул кешегә карата кискен чаралар күреләчәк! Бетте! Башкарган эшегез турында кичкә минем алда хисап тотасыз!

Вахит йоклый торган өенә дә коры утын кайтартып, идарәне шактый җылытты. Ул инде толып киеп утырмый, чишенеп, кәгазъ-каләм алып, киләчәккә планнар кора башлады: кемгә нинди эш кушарга, кушкан эшнең үтәлешен тикшерергә, звенолардагы өерелешеп эчүләрне туктатырга, язгы чәчүгә әзерлек, запчастьлар юнәтү, ягулык табу, язгы чәчүгә, урып-җыюга техниканы ремонтлау, малларга курмы әзерләү мәсьәләләре... Уку елы тәмалангач, мәктәпнең калхузга ярдәме... Культура-агарту эшен ничек тергезергә... Эш алдынгыларына акчалта һәм премия сыйфатында гәзит-журналлар яздырып, кешеләрнең күңелләрен күрергә...

– Эш күп, үләргә дә вакыт юк! – ди торган иде аның әнисе.

БЕРЕНЧЕ «ЭШКӘРТҮ»

Яз үзен инде сиздерә. Февраль уртасында ук яз хәбәрчесе «эшләки» кошы килеп җиткән, кар калын, суыгы да бар, ләкин кояш якты карый, эшләки тупылларда, талларда сайрый, эшләп ашарга, эшләп киенергә куша. Эшләки – песнәкнең бер төре, ул кош авылга кайттымы, кышның көннәре санаулыга кала. Төн уртасы булуга карамастан, Вахит һаман йокламый. Шулай хыялланып утырганда идарә өйалдында нидер

дөбердәде, тышта тәрәзә каршында кемдер бар сыман тоелды, күңелгә шом иңде. Кинәт чыпталы ишек каерылып ачылып китте, ишек караңгылыгында алагаем олы гәүдәле тракторчы-комбайнчы Рафил күренде, ул ишелеп килеп керде.

Төн уртасында нишләп йөри бу? Нияте яхшылыкта түгеллеге күренеп тора, дип уйлады Вахит.

Ишекне шар ачык калдырып, Рафил эчкә узды. Вахит сабыр гына:

– Рафил, син ятим баламыни? – диде.

– Атам-анам бар минем. Монда аларның ни катнашы бар?

– Атаң-анаң булса, ятим булмасаң, син бу суыкта артыңнан ишекне ябып йөрергә өйрәтелгән булыр идең!

Болай да котырырга гына торган Рафил, бик яман сүгенә-сүгенә, Вахит өстенә килә башлады.

Бу кешенең күзе тонган. Моңа маһы бирергә ярамый, курыкканыңны күрсәтү – ул инде җиңелү дигән сүз. Вахит, ипләп кенә урыннан кузгалып, өстәл арасыннан чыгып, ике кулын сузып, Рафилга таба атлады.

– Һи-и, Рафил, мин сине ышанычлы кешем булырсың, дип уйлаган идем, бергәбергә ярашып эшләрбез, дип өмет иткән идем, – диде председатель. – Синдәй ирегетләргә таянмыйча, мин берни дә эшли алмыйм...

Рафилдан алдан өлгермәсә, Вахитның хәлләре мөшкел булачак. Авырлык үлчәме артык аермалы иде. Төнге кунак зур йодрыгы белән Вахитка кизәнде. Десантчы, боксчы, самбист Вахит кинәт уң йодрыгының ике сөяге белән Рафилның күкрәк авызына бәрде. Рафил, эчен кысып, тезенә төште, ул айнып күтәрелә калса, нәтиҗәсе Вахит өчен һич югы нокдаун белән бетәчәге билгеле иде. Дошманының ике иңбашыннан умырып тотып, Вахит тезе белән Рафилның чыраен яньчеде. Рафил нокаутта иде. Председатель, механизаторның ярым аңсыз гәүдәсен өстерәп өйалдына алып чыкты да, баскычтан аска ташлады.

Бераз аңсыз яткач, Рафил кыймылдый башлады. Вахит аңа торырга булышты.

– Хәзергә җитеп торырмы, Рафил, әллә тагын өлеш чыгарыйммы? – диде председатель.

– Җитте, Вахит Вәлиевич! – дип, Рафил, канаган борынын тотып, алпан-тилпән атлап, капкадан чыгып китте.

– Бабаңа сәлам әйт, әбиең утырмага килсен! – дип кычкырды Вахит гөрес-мәрес китеп баручы «батыр» артыннан.

Бусы инде тез белән бәрүдән дә катырак сугу иде.

Элеге вакыйга турында һичкем белмәде, күрмәде, дип уйлады Вахит. Әмма иртә белән идарәнең бухгалтерия ягында сөйләшеп утырганда Вахит әйтә куйды:

– Ай-һай, Уразбахты кешеләре усал сезнең! – дигән иде, хисапчы хатын белән җыештыручы апа пырхылап көлеп куйды.

– Ник көләсез? – дип сорады рәис.

Җыештыручы җиңги әйтте:

– Кара баганалы Иске Комазаннар Уразбахтылардан да усалрак булып чыккан әле монда! – диде.

– Аңламадым! – диде Вахит.

Җыештыручы җиңги:

– Син Рафилны «эшкәрткәндә» мин бухалтер бүлмәсен җыештыра идем, – дип җавап бирде.

Бу гадәттән тыш хәл турындагы хәбәр бөтен авылга таралды. Метр алтмыш ике гәүдәле присидәтел метр сиксән сигезле Рафилны изгән, урам буйлап сүрәп йөргән.

Кара канга батырып кыйнаган икән, дип озак сөйләде халык.

Шуннан соң Рафил, чыннан да, аны яклаучы, аның терәге булып китте.

КЕМ УЛ – ВАХИТ ГАЛИЕВ?

– Кем ул Вахит Галиев?

– Вахит Галиев – ул Мамадыш каласының шәрәфле гражданины!

– Кем ул Вахит Галиев? – дигән сорауга танылган җырчы, педагог, Татарстанның халык артисты Миңгол Миңлевәгыйзь улы Галиев болай җавап бирде:

– Вахит Галиев – ул минем мәгънәви атам. Без – туганнан туган Галиевләр нәселе. Вахит абый Галиев булмаса, Миңгол Галиев дигән җырчы да булмас иде. Чөнки Вахит Галиев үзенең тугыз баласы өстенә мине дә унынчы баласы буларак тәрбия кылды. Киңәшләре белән ярдәм итеп, укыганда, авыр чакларымда ул минем өс-башымны карап торды. Наилә җиңгәм белән Вахит абый миңа мәгънәви анам, мәгънәви атам булды. Аларга чиксез рәхмәтләрем!

– Кем ул Вахит Галиев?

– Шагыйрь! Вахит Галиев – ундүрт шигъри китап авторы! Аның сүзләренә утыздан артык җыр чыгарылган. Көйләрнең авторлары арасында Ганс Сәйфуллин («Әтиләр, әниләр»), Миңгол Галиев («Үтә гомерләр», «Авылым мәктәбенә», «Комазан авылы», «Яшә, Мамадыш»), Фирзәр Мортазин («Әниемә теләгем»), Фәрит Хатипов («Сине юксынам») кебек танылган исемнәр дә бар.

– Кем ул Вахит Галиев?

– Вахит Галиев – «Суслонгер» җәһәннәменнән исән чыккан солдат.

– Кем ул Вахит Галиев?

– Танк хәрби көчләрендә сәяси хезмәткәр.

– Кем ул Вахит Галиев?

– Вахит Галиев – бокс ярышында (үз авырлыгында) җиңелү белмәгән бердәнбер спортчы!

– Кем ул Вахит Галиев?

– Комазан авыл клубының штаттан тыш мөдире, мотоцикл спорты тренеры, 100 кешелек хор җитәкчесе, Халык театрындагы спектакльләрдә баш рольләрне башкаручы һәвәскәр актёр, Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре.

– Кем ул Вахит Галиев?

– Бала чагыннан ук яратып йөргән авылдаш кызы, яшьтәше, сыйныфташы Наиләгә егерме яшендә өйләнеп, 70 ел никахта аерылгысыз яшәгән, әле һаман да исән шәхес. Аларның 9 баласы, 53 оныгы вә торыннары бар. Бөтен балалары да югары белем алган. Биш баласы – табиб, икесе – укытучы, икесе – икътисадчы. Күптән инде алмаз туйларын уздырган Вахит ага белән Наилә ханым Галиева Гиннессның рекордлар китабының иң түрендә торырга тиеш гаилә.

Нефтьче, урман хуҗалыгында – өлкән мастер, хуҗалыктан сөт җыючы, умартачы булганын да саный китсәң, Вахит Галиевнең рухи вә бәдәни куәтенә сокланмый мөмкин түгел!

– Кем ул Вахит Галиев?

– Хезмәттәге батырлык медале иясе!

Ачлык һәм сугыш, үз башыннан уздырган Суслонгер җәһәннәменнән исән чыгу, шәһәрдән шәһәргә балалары, хатыны белән күченеп йөреп, фатирсызлыкны, әллә ничә тапкыр авыр операцияләр кичереп, партия кушуы буенча бер вазыйфадан икенчесенә

көчеп күп һөнәрләр алмаштырса да, җор телле, миһербанлы, мохтаҗларга ярдәмчел булып кала алган бу каһарман ир-егет Вахит Миңлевәли углы Галиевтән:

– Чүтеки, иң әһәмияле, иң яраткан вазыйфаң кайсысы булды? – дип сорасагыз, ул әйтер:

– Бөтен эшемне дә вөҗданым кушканча башкарырга тырыштым. Әмма ике вазыйфама бик җитди карадым: үз белдеклегем аркасында, клуб мөдире эшен үз өстемә алдым. Бу минем ихтыярым иде, туган авылымда шундый сәләтләр була торып, клубның ташландык ятим сыман тырпаеп торуына түзә алмадым. Бу вазыйфага алынуыма әле дә булса куанып бетә алмыйым. Икенче вазыйфам – Уразбахты авылында калхуз рәисе булып эшләвем минем иң изге максатым, намус горурлыгым, йөз аклыгым булып тора!

Вахит Галиев – Мамадыш төбәгенең «Аксакаллар шурасы» рәисе, президиум әгъзасы (1994-2017).

Вахит Галиев – кайнар кеше, тормышны кайнаткан кеше, үзе дә шунда кайнаган, пешкән-өлгергән зат: халык йолаларын, гореф-гадәтләрен канына сеңдереп үскән татар шәхесе, ирексездән үзе теләмәгән сәяси тормышка яраклашырга мәҗбүр булса да, үз йөзен, үз гаиләсен, үз авылын, үз милләтен теше-тырнагы белән саклаган, яклаган каһарман.

Чалубәйләр, Идегәйләр, Җәлилләр, Карбышевлар, Әлмәндәрләр, Гавриловларның нәсел каны Вахит Галиев кебек каһарманнар холкында дәвам итә.

– Нинди соң ул серле татар холкы? – дигән сорауга болай дип җавап бирер идем:

– Серле татар холкы ул – Вахит Галиев кебекләрнең холкы!

Инде күпме еллар узды, әмма Уразбахты белән Чаллы юлы арасын тоташтырган, күтәртелгән юлны халык әле һаман да «Вахит юлы» дип йөртә. Ул – шушы юлны күтәртеп, халык күңелендә үзенә һәйкәл салган батыр кеше.

Шулай ук Иске Комазан авылы мәчетен дә «Вахит мәчете» дип атаудан туктамыйлар.

Вахит Миңлевәли углы Галиев 1976 елдан алып 1985 елгача Уразбахты халкы өчен башкарган эшләрнең исемлеге саклaнган:

1981 елда Уразбахтыда 30 сыер савучының 20се – яшь кызлар. Аларның хезмәт нәтиҗәләре аркасында сыер савучылар коллективы Муса Җәлил исемендәге бүләккә лаек булды.

Балалар бакчасы ачылган. 8 чакрым юл күтәртелгән. Өч күпер салынган. Ашлама амбары корылган. Ашлык саклау амбарлары төзелгән. Тегермән эшли башлаган. Мөгезле эре терлек өчен заманча җәйге лагерьлар барлыкка килгән. Машинага запчастьлар склады сафка бастырылган. Тракторларга, машиналарга махсус гараж корылган. Бәрәңге саклагыч базлар, ашханә, ике катлы идарә йорты, белгечләр өчен авыл эчендә 8 йорт төзелгән. Яшьләр, яңа никахлашканнар өчен исә ике катлы 15 йорт салынган. Яңа типтагы урта мәктәп. Силос чокырлары. Эретеп ябыштыру цехы. Телевизион манара. Урам юлын күтәртү һәм асфальтлау. Ындыр табагына асфальт җәю. Һәр өйгә телефон кертү. Тимер торбалар белән авылга су уздыру...

– Ләкин, – диде хикәябезнең каһарманы Вахит Галиев әңгәмәбез ахырында, – алда искә алган ике вазыйфамнан башка минем супервазыйфам да бар иде. Ул – хатыным Наиләне җил-яңгыр тидертмичә саклау; тугыз баламны миһербанлы итеп тәрбия кылу, аларны аякка бастыру!

Һәм Вахит Галиев үз максатына иреште дә! ■

Безнең мирас №6 июнь 2018

КАРАНТАУ ИТӘГЕНДӘ

Рәдиф Сәгъди

Әлмәт, Лениногорск, Бөгелмә һәм Азнакай якларының халкы Урал тавының итәкләренә борынгы заманнардан ук килеп сыенган. Матур-матур татар авылларына нигез салынган биредә. Шул калкулыкларга ышыкланып, бүгенге көндә дә ошбу җирләргә тугры калган халык гомер итә. Заманында Казан ханлыгы чорларында гөрләгән бу яклар казакъ, башкорт, кыргыз, үзбәк һәм башка кавемнәр белән сәүдә итү, тауар алмашу урыны да булган, борынгы Карабаш шәһәрчеге дә шушы җирлектә чәчәк аткан, шаулаган!

Татар токымлы атлар

Археологик казылмалар да шуны дәлилли. Ни кызганыч, бүгенге көндә халкымның шанлы төбәге пыскып кына ята. Татарның ярсу атлары, гаярь җайдаклар күренми хәзерге сәүдә юлларында. Аларны бары тик Каран тауның итәкләреннән генә эзләп табып була. Әлеге тау бик биек калкулыклардан тору сәбәпле, тирә-юньне күзәтү өчен гаять уңайлы булган һәм исеме дә җирле татарлар тарафыннан «тирә-ягыңа каран, йоклап ятма», дигәннән алынган. Биредән карап, офык ераклыгыннан ук кемнәр килгәнен аерып булган. Ак, алмачуар чапкыннар күренсә, бу аларның татар кавемнәреннән икәнлеген аңлаткан. Дошманнар килсә дә аеруы кыен булмаган, һәр кавемнең атлары үзенчәлекле төсләрдән торган! Бары тик йоклап ятма, уяулык кына күрсәт! Тирә-юнеңә каран!

Шушы төбәктә атчылык, умартачылык белән шөгыльләнеп ятучы татар алдынгысы Фәрит Нәбиуллин, үзенең тимер айгырына утыртып, мине әлеге тау битенә алып менеп китте. Тау башындарак ат көтүе күренде. Шайтан таягына (татарник) бай булган әлеге сыртта дистәләгән нәселле, татар токымлы атлар утлап йөри. Кинәт ачылган бу гүзәл күренештән хәйран каласың, үзеңне элекке заманнарга әләккәндәй тоясың. Әле искә алып киткән шайтан таягын, чәнечкеле булса да, бахбайлар бик яратып ашый, өстәвенә,

бал кортларының да яраткан чәчәге булган үлән, үзенә тартып, алсу-кызгылт төсләргә төренеп утыра. Безне атларның көтүчесе – «Таза йөрәк» кушаматлы Ринат әфәнде каршы алды. Аты татар токымыннан булса да, кушаматы «Мустанг» икән. Ул барлык чабышкыларны иртәнге дүртләрдә утларга алып чыгып китә. «Фермага җиделәрдә генә алып кайтам, көндезен урыслар Чихан дип атап йөрткән тау үзәнлегендәге чишмәгә алып төшеп, шифалы салкын су эчерткәч, кире утлауга күтәреләмен», – ди. Болгар дәүләте заманында, биредәге сихәтле суны эчеп, сәламәтлекләрен ныгытыр өчен, төрле яклардан килә торган булалар. Ошбу шифалы су белән коену, чайкану инешкә исем биргәндә дә үз ролен үтәгән, ягъни «Чайкан», әлеге атаманы руслар тора-бара үз телләренә яраклаштырып, Чихан дип атый башлаганнар. Шунысы да кызыклы: Фәрит Нәбиуллин Тува Республикасына тәҗрибә уртаклашырга баргач, анда да Чайкан инешен күреп шаккаткан. Хәер, монда әллә ни гаҗәпләнер нәрсә дә юк, чөнки без тугандаш, кан-кардәш халык, бер кавемнән. Аларда христиан, безгә ислам дине кабул ителгәч кенә, алынма сүзләр өстәлеп, тел байлыгы үзгәреш кичергән. Шуңа карамастан, борынгыдан килгән сүзләр барыбер уртак инде. Чайкан суына килгәндә, ул минералларга бик бай, өстәвенә, катылыгы да 5,8 мг-экв/л гына, ә норма буенча ул 7 мг-экв/л тиеш икән. Алдарак язуымча, суының шифасы зур булып, борынгы бабаларыбыз тернәкләнергә бирегә килгәннәр. Биредәге балчык Бәкер шифаханәсендә кулланыла торганга тәңгәл килә.

Халкын да беркайчан да буйсындырылмаган, милли рухлары сынмаган татар, мари, мордвалар тәшкил итә. Казан тирәсендәгеләре, коточкыч афәтләр күрү сәбәпле аннан качып китеп, Урал таулары ягына сыенганнар. Биредәгеләр гаярь, көчле рухлы булганга, чукындыручылар гаскәре дә бу тирәләргә барып башбаштаклык итәргә җөрьәт итмәгән. Яхшы мәгънәдә усал халык яши бу төбәктә – кешенекенә тими, үзенекен бирми торган кавем! Әлбәттә, басым ясарга теләүчеләр дә җитәрлек булган, ләкин көчле каршылык күрсәтү мондый алымнарга чик куйган. Октябрь революциясеннән соң көчләп икмәк җыючылар (продразверстка отряды) килгәч, «яңа тормыш төзүчеләр» сәнәкчеләр һөҗүменә дучар булалар. Совет дәүләте, моңа үч итеп, ул елларда бер меңгә якын ир-атны атып үтерә, калганнарының бер өлеше Ошка, икенче өлеше Әфганстанга

Фәрит Нәбиуллин шәкертләре белән

Фәрит Нәбиуллин һәм юртагы

гына качып котыла. Сәнәкчеләрнең әйдаманы Гобәйдулла бабай исә Ютазы ягыннан була. Ул София Гобәйдуллинаның газиз әтисе, Фәрит әфәнденең бабасы Майкынби белән бертуган, шул сәбәпле, композитор София ханым белән Фәрит тә туганнан туганнар.

Хәер, биредә, патша хакимияте баскаклыгыннан, милли кимсетелүләрдән котылу өчен, гел чуалышлар булып торган. Эш шуңа кадәр барып җитә ки: бәрелеш, низагларның сәбәпләрен ачыклап, кискен хәлне җайга салыр өчен, 1895 елда губернатор Карабашка үзе килә. Ул, халык вәкилләрен җыеп сөйләшкәч, Карабашта мәчет салырга рөхсәт бирә. Күңел күтәренкелеге кичергән татарлар ерактагы Чупай тавыннан арба белән таш ташып, үзләрен мәчетле итәләр. Бу мәчет бүгенге көндә дә Карабаш бистәсен бизәп, тирә-юньгә иман нуры таратып тора. Тагын шунысы да кызыклы: мондагы тау тезмәләре аша салынган юлдан, Биектаудан патшабикә дә үтеп киткән. Шул сәбәпле, халык аны Екатерина тракты дип атап йөртә.

Азнакай юлы өстендә Фәрит Нәбиуллинның ат фермалары һәм конторасы урнашкан. Яп-яшь кыз-кыркын бахбайларны тәрбияли, чапкыннарга гашыйк чәчбикәләр арасында төрле милләт вәкилләре бар. Әлмәт, Бөгелмә, Лениногорск һәм Азнакай шәһәрләреннән дә килеп, ат өстендә йөрергә өйрәнәләр. Карда эчендәге нәсел айгыры гына, биләмдә йөргән бичәләрен юксынып, «тизрәк кайтыгыз», дигәндәй, көчле, көр тавыш белән кешнәп җибәргәли. Аннары, ташып торган гайрәтен тыя алмыйча, карда буйлап чабып китә. Ул да булмый, арт аякларына басып, баһадирларга гына хас мәһабәт төз гәүдәсен күрсәтеп, кабат тирә-юньне яңгыратып аваз сала. «Үзебезнең бабаларыбыз үрчеткән токым бит бу!» – дигән соклану хисләре туа күңелдә. Яңадан үрчетелә башлаган татар токымлы атлар башкаларга көндәшлек тудыра алырмы соң, дигән уйлар да килеп киткәли. Хәер, июль аенда (2017) Туймазы якларында булып үткән Сабан туе аңа да ачыклык кертте. Лениногорск районыннан Фәрит алып килгән алты атның дүртесе дүрт беренче урынны алды, бишенчесе исә алтынчы урынга чыкты. Соңрак Казан каласында үткәрелгән ярышта да татар токымлы атлар дәрәҗәле икенче һәм өченче урыннарны яулады. Искитмәле нәтиҗә! Мин бу якларда Фәрит кебек яшәп ятучы тагын бер генә фидакарь кешене беләм. Ул да булса, Туймазы якларында туып үскән эшкуар, композитор, җырчы Фәнир әфәнде Галимов! Андый төпле фикерле, ачык

Татар атлары ыргымы

максатлары булган шәхесләр бүгенге көндә халкыма да, илбашларына да бик кирәк! Чөнки алар илгә дан китерүчеләр! Инде татар токымлы бияләр Карабаш, Биектау, Каран тауларында утлап йөриләр икән, бу инде әлеге дә баягы Фәрит кебек милләтпәрвәр егетләребезнең тырыш хезмәте нәтиҗәсе. Ат бит ул гомер бакый татарның горурлыгы булган. Бабабыз Атилла хан үзенең җайдаклары белән Европаны колбиләүчелектән азат иткән. Кубрат бабабыз исә Азак, Кара диңгез буйларында атлар ярдәмендә таш калалар төзеткән. Аның улы Кодрәк хан Идел буе Болгарына нигез салган! Кайда гына йөрсә дә, нинди генә кала-дәүләтләр корса да, татарның иң зур терәге бахбайлар булган. Инде урыс баскаклыгы астында калгач та, нинди генә яу килмәсен, татарлар уртак илебезне сакларга дәррәү күтәрелгәннәр. Чөнки бүгенге Рәсәй җирләре безнең ата-бабалардан мирас булып калган туган җиребез дә ул. Арысландай сугышканнар явыз дошман белән! Татарларның атлы гаскәре 1812 елда француз гаскәрләренә каршы да тиңдәшсез батырлыклар күрсәткән. Бу турыда партизаннар сугышы герое, полководец Денис Давыдов мемуарларыннан өземтә китерү дә җитә: «Лучше татар никто не воевал, им завидует даже и донские казаки». Биредә казакларның да кайчандыр төрки кавемнән чыкканлыгын искәртеп китү урынлы булыр. Денис Давыдов истәлекләренә кабат мөрәҗәгать итик әле: «В параде победы, которой проходил в Париже, впереди шли татарская кавалерия, потом дикая дивизия Кавказа», – дип искә ала ул. Бу сугышта урыс гаскәрләре белән җитәкчелек иткән Кутузовның татар өммәтеннән икәнлеген инде күпләр белә. Әмма Денис Давыдовның Батый ханның оныгының оныгы икәнлеген рус галимнәре әлегә хәтле яшереп килә. Бу фактны танысалар да дөреслекне ачарга җөрьәт итмиләр, эшсез каласылары килми, сәясәт! Ә менә Фәрит Нәбиуллинның нәсел-нәсәбе, аның борынгы бабасы Чыңгызханның якыннарыннан булган. Нәсел билгесе дә – тарак рәвешендәге тамга. Бүгенге көндә ул Украина халкының да дәүләт символы. Фәрит тә үзенең нәсел тамгасын ат фермасының өстенә зур итеп ясаткан. Шуны тиешле урынга җиткергәннәр. Нәтиҗәдә, прокуратурадан килеп бәйләнгәннәр.

«Украина белән низаг бара, ә Сез аның символын күзгә ташлана торган урынга элеп куйгансыз», – дип дәгъва белдерәләр аңа. «Украиннарны белмим, әмма үземнең нәсел тамгамнан ваз кичә алмыйм», – дигәч, кул селтәп китеп баралар. Тагын килеп тыгылып йөрүчеләргә ул, үзенең шәҗәрәсен дә күрсәтеп, авызларын томалый, нәселенең каян ки-

Чайкан күленең суы татар атларына да шифалы

леп чыкканлыгын дәлилли. Сокланырлык, көнләшерлек аның нәсел-нәсәбе. Хуҗалыгы, мал-туары белән танышкач, Фәрит әфәнде шифалы сулы чишмәле күлгә алып менеп, үзенең киләчәккә планнарын җиткерде. «Бу күлне чистартып, кешеләр ял итәрлек дәрәҗәгә җиткерәм. Кара син аның тирә-юнен, моның хәтле вәхшилек каян килә диген безнең халыкка?!. Әле Совет заманында бу изге күлнең өске ягына, әнә күрәсеңме, сыер фермалары салынган иде. Аларның тизәкләре суга юылып төшә торгач, күлнең ни хәлгә китерелгәнен аңлыйсыңдыр. Безнең Ислам динендәге бабаларыбыз кайчандыр кадерләп саклаган, суын эчкән, чайканган суга мондый мөнәсәбәтнең каян килгәнен барыбыз да аңлый, ләкин төзәтергә, чистартырга, элекке хәленә кайтарырга йөрүчеләре генә сирәк. Зур чыгымнар соралса да, әкренләп имгә китерәм бу изге күлебезне! Менә бу зур-зур ташлар-валуннар белән исә әйләнә-тирәсен ныгытам, суның үзенә затлы балыклар җибәрәм, тирә-юненә чыршы-нарат, артыш агачлары утыртам. Табигатьнең элеккеге гүзәллеген кире кайтарачакмын, Алла боерса! Әйдә, хәзер чишмә-чыганакның өске ягынарак менеп, суын эчеп карыйк әле, ни диярсең», – дип, ул мине үзе артыннан ияртте. Якынайган саен, челтерәп аккан чишмә тавышы көчәя төште. Ул төрле үлән-куаклар арасына яшеренеп кенә ага иде. Кешеләр йөреп таптап салган сукмагыннан гына каян су эчәргә мөмкинлеге беленә... Эчеп карадык без Каран тау башыннан агып төшкән шифалы суны, тәнгә сихәт иңгән кебек булды, әлхәмдүлилләһи шөкер! Күпме табигать байлыгы кадерсез булып агып ята. Адәмнәр, ошбу шифалы суны эчәсе урынга, акчага сатып алып агу чөмереп ята, алай гына түгел, кешелек сыйфатларын җуя, башка халыкның яшәү рәвешенә бирелеп иманын югалтып ята! Киләчәк өчен, оныкларыбыз өчен саклагыз, диеп, бөтен җиһанга аваз саласым килә! Саклагыз!

Нинди зур югалтулар кичергән безнең милләт! Нәсел-нәсәбе генә түгел, үзе яшәгән гүзәл табигатенә хәтле мәсхәрәләнгән. Килгәннәр, талаганнар, җимергәннәр... Ә менә алмашка нәрсә бирелгән – пычраклык һәм явызлык! Шуңа карамастан, милләтебез элеккеге хаталарын төзәтер өчен көрәш алып бара. Алар арасында алдынгылар рәтендә – алгы сызыкта Фәрит кебек милләтпәрвәр шәхесләребез маяк булып тора. ■

Галимҗан Ибраһимов туганы

Фәнис Фәтхи

Күптән сыналган күренеш – затлы-зыялы нәселнең дәвамчылары да, нигездә, аксөякләр даныны дәвам итә, төрле талантлары һәм булдыклы булулары белән аерылып тора. Татар халкының асыл улы, күренекле язучы, галим һәм җәмәгать эшлеклесе Галимҗан Ибраһимовның дәвамчыларына да бик туры килә бу сыйфатлама. Галимҗан агабызның шәҗәрәсен тикшерсәң, Башкортстанда бүгенге көндә дә аның оныкларының балалары, туганнары шактый икәнлеге күренә. Һәм алар атаклы бабаларының, кардәшләренең истәлеген кадерләп саклый, аның яңадан-яңа ядкәрләрен таба, җәмәгатьчелеккә җиткерә.

Хәйрияче Марат Сәетов

Стәрлетамак шәһәрендә яшәүче булдыклы эшкуар һәм меценат Марат Сәетов та шундый игелекле затларның берсе. Фамилиясе Сәетов булгач, Г.Ибраһимовка кайсы яклап туган булып чыга соң ул, дигән сорау туар. Марат Мәҗит улы Галимҗан Ибраһимовка әнисе Мәүсилә апа ягыннан нәсел дәвамчысы. Әнисе Әпсәләм авылына Солтанмораттан килен булып төшә. Кияүгә чыккач та, бабасы хөрмәтенә Ибраһимова фамилиясендә кала. Әлбәттә инде, тормыш иптәше Мәҗит ага ризалыгы белән. Мәүсилә апа өч улына да, шул исәптән Маратка да, кечкенә чакларыннан ук: «Сез – күренекле Галимҗан Ибраһимовның оныклары, шуңа күрә, йөзебезгә кызыллык китерерлек гамәлләр кылмагыз», – дип өйрәтә. Малайлар әниләре сүзеннән чыкмый, тәрбияле, укымышлы булып үсәләр, һәммәсе дә яхшы белем ала. Галимҗан агалары аларның уңышларын күреп куаныр иде. Марат әфәнде татар классигы булган абыйсы истәлеген мәңгеләштерү өчен күп эшләр башкара. Солтанморат авылында Г.Ибраһимовның йорт-музеен төзүгә һәм аны тәртиптә тотуга үз өлешен кертә. Туган авылы Әпсәләмдә туганнары белән берлектә мәчет төзетеп куйды. Аны да әниләре һәм атаклы әдип бабалары хөрмәтенә сафка бастырдылар. Быел Марат әфәнде мәчетнең уңайлыкларын арттыру, идәнен җылыту өчен дә шактый акча тапшырган. Танылган галим һәм язучы Суфиян Поварисов Г.Ибраһимовка багышланган трилогия язган иде. Аны Казанда нәшер итү чыгымнарын да Марат Сәетов үз өстенә алды.

Стәрлетамакта һәм Авыргазыда Ибраһимов укуларын оештыруга да аның керткән өлеше бәһасез. Татар милли оешмалары эшчәнлегендә актив катнашучы буларак, татар мәктәпләренә, китапханәләргә матди ярдәм күрсәтә Марат Сәетов. Булдыклы эшкуар һәм меценат ел саен үз хисабына дистәләрчә авылдашына һәм мәктәп, китапханәләргә татар газета һәм журналларын яздырта. Әлбәттә, Казанда нәшер ителүче басмалар да байтак арада.

Марат әфәнде әнисенең дә, әтисе ягыннан да нәсел агачларын төзегән. Шәҗәрәләрне төбәк тарихын өйрәнүче Мөдәррис Сафин белән әзерлиләр. Бергәләп, Әпсәләм авылына багышланган китапны да нәшер итәләр. Туган төбәкнең 190 еллык юбилеена өлгертәләр аны. Күренекле туганы турында яңа мәгълүматлар туплау өчен хәтта Ялта шәһәренә дә сәяхәт кыла М.Сәетов. Һәм нәтиҗәле була ул баруы. Гомумән, Галимҗан Ибраһимовны искә алган һәммә чараларның да үзәгендә Марат әфәнде. Атаклы әдипнең 130 еллыгын да зурлап билгеләп үтүгә җитди әзерлек эшләрен алып барды. Казаннан да байтак галимнәрне чакырдылар, фәнни-гамәли конференция оештырдылар, якташлары белән очрашуларда булдылар.

М.Сәетов күп еллар инде төбәктәге татар милли хәрәкәтенең үзәгендә кайнап яши. Татар конгрессының Стәрлетамак бүлеге идарәсе әгъзасы күп чараларны оештыруга матди ярдәме белән дә катнаша. Филология фәннәре докторы, Башкорт дәүләт педагогия университетының татар кафедрасы мөдире Илшат Насипов өлкән дустына киңәшләре өчен әле дә рәхмәтле. Илшат әфәнде элекке елларда Стәрлетамак педагогия университетының татар-чуаш кафедрасы мөдире һәм бер үк вакытта Татар конгрессы төбәк бүлеге рәисе дә иде. Шулчакта Марат Мәҗит улы оештыру эшләрендә төпле тәкъдимнәре белән дә, химаячелеге белән дә бихисап мәдәни чаралар оештыруга, мәктәпләрнең татар сыйныфларына һәм аеруча 5 нче татар гимназиясенә һәрдаим ярдәм итә. Башкортстанда татарларның милли-мәдәни мәнфәгатьләрен канәгатьләндерү җәһәтеннән мөмкинлекләр бик аз булуы да борчый Марат Сәетовны. «Башкортстан юлдаш телевидениесендә элекке елларда татар телендә «Рәйхан» исемле тапшыру чыгып килә иде. Шуны да ябып куйдылар, ә алмашка бернәрсә дә ачылмады. Дәүләт радиосында да тапшырулар юк. Ә бит татар халкы Башкортстанда халыкның өчтән берен тәшкил итә һәм шулкадәрле үк салым түли. Шулай булгач, нигә әле без ана телебездәге телевидение һәм радио тапшыруларыннан мәхрүм булырга тиеш? Бу һич кенә дә аек акылга сыймый», – ди әңгәмәдәшебез.

Сөйләшүебез Галимҗан Ибраһимов мирасын барлауга кагылышлы хәстәрлекләр турында дәвам итә.

– Туганыбызның истәлеген мәңгеләштерү өчен моңа кадәр байтак эшләр башкарылды. Район үзәк китапханәсе һәм Толбазыда бер урам Галимҗан Ибраһимов исемен йөртә. Авыргазы районында «Зәңгәр чишмә» дигән иҗат берләшмәсе оештырылды. Ул үз тирәсенә халык талантларын, аеруча сәләтле яшьләрне туплый. Әдәбият, сәнгать һәм халык иҗатын үстерүгә һәм пропагандалауга аеруча зур өлеш керткән кешеләргә бирү өчен район хакимияте Галимҗан Ибраһимов исемендәге премия булдырды. Мәктәпләрдә, китапханәләрдә, клубларда бөек якташыбызның әдәби һәм фәнни мирасы кабат-кабат ныклап өйрәнелә. Район күләмендә берничә тапкыр тел һәм әдәбият укытучыларының фәнни-гамәли конференциясе булды, – ди М.Сәетов.

Галимҗан Ибраһимов туган көләч март аенда Стәрлетамак шәһәренең 5 нче татар гимназиясендә ел саен «Ибраһимов укулары» республика конференциясе оештырылуы да бик әһәмиятле чара. Татар балалары күңелендә ана телебезгә мәхәббәт уятуны, милли рухны күтәрүне күз уңында тота ул. Җыенны ел да Мәгариф министрлыгы, Стәрлетамак шәһәре хакимиятенең мәгариф бүлеге, БДУның Стәрлетамак

филиалы һәм 5 нче гимназия коллективы оештыра. Ә гомум эшкә Марат Сәетов һәм аның башка туганнары химаячелек белән кушыла. Әйтергә кирәк, күмәк көч, уртак тырышлык үз нәтиҗәләрен бирми калмый, чарада катнашучыларның саны елдан-ел арта бара. Конференциягә тәкъдим ителгән фәнни-гамәли эшләр аерым җыентык булып басылып чыга. Татар, урыс, башкорт, чуаш, немец, инглиз телләрендә 7 секция оештырылып, алар Г.Ибраһимов иҗатын заманча шартларда өйрәнү, туган телнең, әдәбиятның аралашу чарасы буларак һәм дөньяны танып-белүдә әһәмияте, Башкортстанда яшәүче халыкларның тарихы һәм мәдәнияте, Стәрлетамак шәһәренең Башкортстан сәнәгатендә, мәдәниятендә, мәгарифендә тоткан урыны, укучыларда ватанпәрвәрлек хисен тәрбияләү кебек актуаль темаларга багышлана. Конкурста ел саен Авыргазы, Бакалы, Бәләбәй, Бишбүләк, Бүздәк, Илеш, Стәрлебаш, Мәләвез, Кырмыскалы һәм Стәрлетамак районнары, Бәләбәй, Ишембай, Салават, Стәрлетамак, Туймазы, Уфа шәһәрләре укучылары һәм БДУның Стәрлетамак филиалы студентлары югары нәтиҗәләр күрсәтә. Җиңеп чыгучылар чарада катнашучы абруйлы кунаклар кулыннан дипломнар, истәлекле бүләкләр ала.

«Галимҗан Ибраһимовны күпләр фәкать язучы буларак кына белә. Ә бит ул күренекле галим дә, тел белгече дә, дәүләт һәм җәмәгать эшлеклесе дә, – ди Марат әфәнде. – Аның хакында язылган трилогиядә болар чагылыш тапты. Әмма шулай да Ибраһимов шәхесе әле һаман тулысынча ачылып бетмәгән. Тикшеренүләр дәвам итәргә тиеш».

Әңгәмәдәшемнең әйтүенчә, әдипнең 12 томлык җыентыгын чыгару да дәвам итә. Анда Галимҗан Ибраһимовның моңа кадәр беркая да кертелмәгән, тыелган әсәрләре дә урын алачак. Шулай итеп, гаделлек барыбер җиңә һәм асыл затлар милләткә бар тулылыгында кайта башлый.

Галимҗан Ибраһимовка багышланган соңгы чара яңарак Уфадагы «Ихлас» мәчетендә үтте. «Галимҗан Ибраһимов мирасы» исемле фәнни-гамәли конференциягә Казаннан да галимнәр килгән иде. Дамир Исхаков, Илнар Гарифуллин һәм башкалар атаклы милләттәшебезнең тормышы турында кызыклы мәгълүматлары белән уртаклашты. Мәртәбәле җыен Галимҗан Ибраһимовның фаҗигале вафатына 80 ел тулуга багышланды. Тикшерелүче темалар арасында шулай ук Башкортстан Республикасының 100 еллыгы, Россия мөселманнары Үзәк диния нәзарәте оештырылуга 230 ел тулу вакыйгалары да үзәктә. Әйе, конференциядә катнашучы танылган галимнәр Галимҗан Ибраһимовның тормыш юлын һәрьяклап өйрәнгән. Аның Башкортстан Республикасын оештырган вакытлардагы гамәлләре дә игътибардан читтә калмый. Күренекле якташларының истәлеген мәңгеләштерү өчен, туган ягы Авыргазы районында да зур эшләр башкарыла. Бу хакта Авыргазы районы туган якны өйрәнү музее мөдире Саимә Әминева сөйләде. Аның әйтүенчә, быел Солтанмораттагы музейны төзекләндерү, матурлау өчен республика Мәдәният министрлыгы грантын алуга ирешкәннәр. Моны үзе дә күп ярдәмнәр күрсәтүче Марат Сәетов хуплап каршы алган.

Марат Мәҗит улы тормыш-көнкүрештә дә затлы һәм зыялы. Стәрлетамак каласы янында матур итеп шәхси йортын төзетә ул. Гүзәл табигать почмагындагы өйнең эчендә дә иркен, җылы һәм рәхәт. Бирердәге берничә бүлмә чын музейны хәтерләтә. Галимҗан Ибраһимовка багышланган почмактан тыш, монда борынгы ядкәрләр дә, бихисап күренекле шәхесләрнең фотосурәтләре дә урын алган. Сәетовларның да, Ибраһимовларның да затлы итеп эшләнгән шәҗәрәләре аерым бер урын алып тора. Марат әфәнденең тырыш җәмәгать эшчәнлеге дә лаеклы бәяләнә. Ул – Галимҗан Ибраһимов исемендәге премия һәм Әнгам Атнабаев бүләге иясе. ■

Безнең мирас №6 июнь 2018

Өч армия, максат – бер

Әнәс Сафуанов*

Беренче Бөтендөнья сугышы – зур фаҗига, кешеләр аны тирәнтен аңлап өлгергәнче, илдә янә җитди үзгәрешләр, тетрәнешләр бер-берсенә ялганып китә: патша төшерелә, Совет власте урнаша, Гражданнар сугышы, ачлык... Солдатларның кайберләре Бөек Ватан сугышында да катнашкан, күпчелеге анда улларын, туганнарын озаткан, хезмәт армиясенә алынучылар да байтак булган. Якташым Галимулла Хәлилов язмышында да ачык чагыла бу.

АТАРГА? ТҮГЕЛ, ЯРЛЫКАРГА!

Галимулла Хәлилов 1890 елда Туймазы районының Исмаил авылында туып үскән. Әтисе Газизулла укымышлы булган, авылның ике мәхәлләсе мөхтәсибе эшен алып барган. Аның – кызу канлы, ә улының, киресенчә, сабыр, төпле, әзлекле, дөреслек өчен көрәшүче кеше булуын сөйлиләр.

Авыл мулласы Сәләх Галимулланы урысчага өйрәткән. Галимулланың урысча белүе Петербургта патша армиясендә хезмәт иткәндә бик тә ярап куйган. Авылдашлары аның шундый бер очракны сөйләвен хәтерләде. Бервакыт офицер казарма стенасына эре хәрефләр белән язып эленгән «Ученье – свет, неученье – тьма» дигән лозунгны укырга куша. Солдатларның күбесе укый белми, укыганнары да тотлыга-тотлыга, вата-җимерә генә. Галимулла сүзләрне дөрес әйтеп, чатнатып укып бирә. Офицер бик канәгать кала, солдатны башкаларга үрнәк итеп куя. Аның яза белү-белмәве белән дә кызыксына. Уңай җавап алгач, кемнән өйрәнүен сорый. Мулла турында ишеткәч, бөтенләй аптырап кала. Менә шуннан инде Хәлиловны полк мәктәбенә укырга җибәрәләр. Ул аннан унтер-офицер чины алып чыга, командир дәрәҗәсенә лаек була.

Галимулла Хәлилов 1914 елда башланган сугышка армия хезмәтеннән алынган булса кирәк. Көнчыгыш Пруссия, Карпат операцияләрен, Осовец крепостендагы бәрелешләрне кат-кат сөйли торган булган ул. Бу крепостьта Германия химик һөҗүм оештырган. Урыс солдатларының бер өлешенә противогаз, җитми калганнарга исә битлекләр таратылган. Аны да алалмаганнарга катлап төрелгән чүпрәкне юешләп биргәннәр. Бер кулы белән – шуны, икенчесе белән винтовка тотып һөҗүмгә барганнар. Бу сугышта Галимуллага поручик чины бирелә, ул гвардия полкында хезмәт итә.

Бервакыт взвод командиры Хәлиловны атарга хөкем иткәннәр. Ул хәл болай була. Пасхада христиан динен тотучылар бәйрәмгә шәһәргә чыгарга рөхсәт сораган. Галимулла дини бәйрәмне үткәрүгә каршы килми, кичке унга кадәр кайтып җитәргә боерып, рөхсәт бирә. Тегеләр исә отбойга да кайтмый. Җитәкчелек, аларны – дезертир, коман-

*__Әнәс Сафуанов__ – төбәкне өйрәнүче, Башкортстан Республикасының Туймазы районындагы Кәкребаш авылында яши.

Галимулла Хәлилов хатыны һәм улы белән

дирны моңа юл куючы дип табып, Хәлилов кулга алына. Хәрби трибунал аны атарга хөкем итә. «Елавын еламадым, әмма көн яктысын да күрә алмас дәрәҗәдә һушымны җыя алмый атлыйм. Белгәннәремне укыйм. Эчемнән генә әткәм-әнкәм, туганнарым, авылдашларым белән бәхилләшәм», – дип сөйләгән ул атарга алып барган мизгелне. Шунда бер генерал очрап, хәлнең асылына төшенеп, взвод командирын азат итәргә боера. Нәтиҗәдә, Хәлилов исән калып, хезмәтен дәвам итә.

Сугышта ул бик күп батырлыклар күрсәтә. Алышларның берсендә взводы белән камалышта кала. Аларны үлем яисә әсирлек көтә. Якында гына куе урман була. Ата-ата шунда таба чигенергә боера командир. Ничек кирәк шулай урманга җитеп, агачлар ышыгыннан файдаланып, камаудан чыгалар, үз частьлары белән кушылалар. Шуның өчен Хәлилов «Георгий тәресе» ала. Бу орденга ул тагын бер тапкыр лаек була, шулай ук бер медаль, исемле револьвер белән дә бүләкләнә.

Галимулла сугыш барышында үзен яхшы командир, батыр солдат итеп күрсәтә. Таза гәүдәле, көч-куәтле, сабыр холыклы булуы белән аерылып тора. Рядовойларны

җәберләми, аларны үз итеп, хәлләрен аңлап җитәкчелек итә. Шулай да бер очрак турында: «Служба башланган чор. Ике рәт стройда торабыз. Сизәм, миннән арттагы бер хохол минем аркага акбур белән басып-басып тәре сызып маташа. Шуны сизеп алып, борылдым да шаңладым тегеңә. Һушсыз егылды. Мине арестовать иттеләр», – дип сөйләде ул. Гаделсез хөкем була бу. Беренчедән, Устав буенча, смирно басып торганда хәрәкәтләнү тыела. Икенчедән, патша солдатына сугу булырга тиеш түгел. «Мине гауптвахтага ябып та куйдылар. Хөкем көтеп ятам. Бер офицер хәлне тикшергән дә, мине яклап, аресттан азат итте. «Правильно сделал. Он ведь мусульманин, а это оскорбление», – дигән. Ул вакытта полкта мулла юк, вакыт-вакыт кына бер мулла килеп, үгет-нәсыйхәт биреп, вәгазь укып китә иде. Ә урысларның штатный полк побы бар. Солдатлар белән гел бергә диярлек инде. Урыс диненә игътибар күбрәк иде», – дип сөйли торган иде Галимулла Хәлилов.

ӨЙЛӘНЕРГӘ АКЛАР ЭТӘРӘ...

Фронттан кайту белән, Галимулла Кызыл Армиягә мобилизацияләнә. Аны командир итеп тәгаенлиләр. Гражданнар сугышы турында авылыбыз картлары: «Әле аклар басып ала, әле кызыллар җиңеп килеп керә. Күп тә үтми, аларны аклар чигендерә», – дип сөйли иде. Хәлилов белән дә шундый очраклар булып тора. Бервакыт алар аклар камавында кала. Шунда солдат тәҗрибәсенең файдасы тия. Авыл янынннан ук башланган куе урманга таралалар. Галимулла үзе дә, яшеренеп, Өсән елгасы буена килеп чыга. Куа килгән аклардан елгага чумып, качып кала. Бөтен гәүдәсе белән суга чумып, камыш көпшәсе белән сулыш алып утырырга туры килә аңа. Шулай итеп, Исмаил авылына кайтып керә. Бик күренеп йөрергә ярамый. Юлына очраган бер кыз аны базга яшерә, ашарга-эчәргә төшерә. «Исән калсам, шушы матур кызга өйләнәчәкмен», – дип нәзер әйтә егет.

Аклар чигенеп, авылга янә кызыллар килеп керә. Галимулла тагын сугышка катнашып китә. Алар Бәләбәйгә үк барып җитәләр. Анда кызылларның штабы була. Бүген шәһәр музеенда Хәлиловның фотосы саклана. Сугыш беткәч, ул авылга кайта. Егет әйткән сүзендә тора, сылу кыз Тәзкирәгә өйләнә, бер-бер артлы биш балалары туа.

ОРДЕН-МЕДАЛЬЛӘР АЧЛЫКТАН КОТКАРА

Заманалар шундый тиз үзгәрә ки, аз гына гаеп өчен дә хөкем ителә торган вакытлар башлана. Сугышта үлемгә каршы барып алынган «тәре» тагып йөрү дә хәвефле була башлый. Аның хәләле Тәзкирә Галимулланың ике «Георгий тәресе» орденын, бер медален, исемле револьверын тавык кетәклегенә күмеп куя. «Ачлык башланды. Аптырагач, орден-медальләрне бер капчык арыш онына алмаштырдык. Беразга тамагыбыз туеп торды. Соңрак «именной револьвер» да ризыкка алышынды. Жәл инде, тик нишлисең, биш баланы ачка үтереп булмый бит», – дип сөйли иде ул.

ЗАВОД – ШУЛ УК ФРОНТ УЛ

Бөек Ватан сугышы башлангач, Хәлиловны, өлкән яшьтә, дип, фронтка җибәрмиләр. 1942 елда 52 яшьлек ирне хезмәт армиясенә алалар. Ул Орск шәһәре заводында эшли. Ачлык-ялангачлык, казармаларда салкынлык үзәккә үтә. Станок артында сине алмаштыручы эшче авырып китсә, тәүлек буе эшләргә дә туры килә. Ә авырырга, имгәнергә ярамый. Махсус эшләнгән, дип, нык тикшерәләр, саботажда гаепләнүең дә ихтимал.

Бервакыт көнгә бер кушуч чамасы арыш бирә башлыйлар. Ачлыкка чыдый алмый,

аны берьюлы ашап, күбенеп чирләүчеләр, хәтта үлүчеләр дә булган. Галимулла бу ризыкны тәүлек буена җиткерә. «Бирелгән барлык арышны плитә өстендә куырып, шешә белән изеп ваклап, өчкә бүлдем дә, тәүлек буена шуны өч тапкыр ашадым. Ашадым, дисәң, хәтерең калыр, кабып куйдым, дию дөресрәк булыр. Шулай итеп күбенми дә, ачка үлми дә исән калдым. Сәламәтлек буенчамы, башка сәбәп беләнме, әмма эшкә яраксыз хәлгә килү дә куркыныч. Хәзер саботажник ясыйлар. Военный вакыт, карар бер генә – «Расстрел!» Эштә имгәнү дә куркыныч. Ә имгәнү очраклары булып тора. Нык тикшерәләр. Бармагың, бигрәк тә кулың киселмәсен. «Бу – преднамеренное членовредительство!» Күрше авылдан берәү имән бармагын пресска эләктергән. Ялгышмы, хәйләләпме, белмим. Әмма бик зур бәлаләр белән атылудан чак котылып калган. Сугыш беткәч тә йөдәткәннәр», – дип сөйли иде Галимулла Хәлилов.

Хәлилов, тагын берничә кеше, ачлыкка, хәлсезлеккә чыдый алмый, фронтка җибәрүләрен сорап гариза яза. Бер офицер, алар белән очрашып, кемне фронтка җибәрү, кемне калдыруны хәл итә. Галимулла белән алар арасында шундыйрак сөйләшү була: «Халилов, хотя ты старый, но очень даже здоровый, вполне можешь воевать. Но ты плешивый. Скажут, что Советский Союз воюет плешивыми стариками. Позор!» Галимуллага бу вакытта 53 яшь була. Ул тагын берничә тапкыр мөрәҗәгать итә, тик аны фронтка барыбер җибәрмиләр.

Галимулланы бригадир итеп куялар. Хәлилов кул астындагыларның хәлен җиңеләйтергә тырыша. Соңыннан үзе белән бергә булган авылдашы: «Ярый әле син бригадир идең, югыйсә, мин шунда ялсыз эшләп үлгән булыр идем», – дип, елый-елый сөйли торган булган.

Галимулланы ике елдан кайтарып җибәрәләр. Юлга көрпәдән генә торган бер буханка кылчыклы кара икмәк белән балык консервасы бирәләр. Аның белән бергә Кәкребаштан Дәүләтгәрәй Әхтәриев һәм Төмәнәк авылыннан ике якташы да кайтырга тәгаенләнә. Станциядә аларның мал вагоннарына утырырга тиешлеге ачыклана. Кайтып җиткәнче ачтан үләбез, кешеләрдән ризык сорый-сорый җәяүләп кайтуың яхшырак, дип, тегеләр икесе аннан баш тарта. «Егетләр, хөкүмәт ташламас, шушы вагонга утырып кайтыйк, юләрләнмәгез!» – дип, Галимулла ничек кенә үгетләсә дә, риза булмыйлар. «Без кайтып җиткәнче ачка үләбез, лутчы җәяүләп, хәер эсти-эсти, тукланып кайтабыз», – дип, үз сүзләрен сүз итәләр. Галимулла: «Әй малайлар, илдә – ачлык. Кем сезне туйдырсын. Барысының да балалары ач-ялангач. Сезнең ак фуфайкагызны салдырып, чишендереп, үтереп ташларлар. Күрүче дә булмас», – дисә дә, ул поездга үзе генә утыра.

Тегеләр үзсүзлеләнеп калгач, Галимулла чеметеп-чеметеп кенә икмәк капкалап, станцияләрдә төшеп су эчеп, кайтып җитә. Кайтып җиткәндә коры сөяккә калган була. Өстендәге киеме, таякка элгән кебек, җилфердәп тора. Ә теге ике якташы хәбәрсез югала. Соңрак аларның берсенең хатыны берничә тапкыр Галимулла янына килеп: «Нигә аларны яхшылап үгетләмәдең? Ник үзеңнән калдырдың?» – дип елаган. «Шулхәтле әйттем, хөкүмәт ташламас, җан биргәнгә юнь бирер, дидем. Юк бит, тыңламадылар», – дип ачынып җавап бирә торган булган ул.

***

Гыйбрәтле тормыш сынаулары үткән, үрнәк булырлык гомер кичергән, гадел дә, акыллы да, сабыр да Галимулла Хәлилов 94 яшендә вафат булды. ■

ҮЗБӘК ХАЛКЫНЫҢ СӨЕКЛЕ ШАГЫЙРЕ

Сәхифәне Ләбиб Лерон алып бара.

Үзбәкстанның халык шагыйре (2002), Үзбәкстанның атказанган мәдәният хезмәткәре (1984) Нормурад Нарзуллаев 1934 елның 7 июлендә Кашкадар өлкәсендәге Касби районының Хуҗахәйран авылында зыялы гаиләдә дөньяга килә. Җидееллык белемне авыл мәктәбендә ала.

1948 елда Карши педагогика институтына укырга керә.

Нормурад Нарзуллаев иҗади эшчәнлеген 1954 елда башлый. Шигъри әсәрләре арасында балаларга багышланганнары да бар. Әсәрләре бик күп телләргә тәрҗемә ителгән.

1969-1974 елларда Сәмаркандта һәм Ташкентта бик җаваплы вазыйфалар башкара.

2006 елда вафат була.

Нормурад Нарзуллаев шигырьләре

ТУГАН ИЛГӘ

Әгәр син – тыңгысыз диңгез икән,
Мин – синең ярсулы дулкының.
Син биргәнсең миңа яшәү көче, –
Яшим, димәк, тормыйм гел тынып.

Әгәр син – куе, киң ябалдашлы,
Төз агачлы карурман икән,
Мин – синең тын гына шаулаган
Бер гади тупылың, бел, илкәй!

Әгәр син – яп-якты кояш икән,
Нур сибәсең икән дөньяга,
Мин – синең бер җанлы очкының,
Мин сүнмим, пыскымыйм, мин – янам!

СӨЕНЧЕ

Мин шатлыклы хәбәр алып киләм –
Әзерләгез сөенче.
Минем кулда
Шатлык ташып торган
Дөнья кадәр төенчек.

Елмаегыз әйдә, сөенегез,
Нигә моңсуланырга?
Яхшы хәбәр алып киләм сезгә –
Куанычлы җырлар!

Сөенечле хәбәрләрем белән
Керәм өйдән-өйгә...
Яңа сорт уйлап тапкан бакчачы,
Табиб авыруны җиңгән.

Галәмне айкый космик кораблар,
Синең оныгың туган.
Кара син, кара син аңа: батыр! –
Өй шатлык белән тулган.

Тавыш бирә малай, ул тавышны
Бар җиһан ишетерлек.
Ваемсыз чырай, сытык йөзләрнең
Җаннарын өшетерлек.

Ишетсен әйдә җиһан, ишетсен
Һәм алга атласын ул!
Чакырсын гел алга – киләчәккә,
Чакырсын яп-якты юл!

Алга барам.
Ә кулымда минем –
Дөнья кадәр төенчек...
...Яхшы хәбәр алып киләм сезгә –
Әзерләгез сөенче!

АЛМАЗ

Түгел ул
Бик затлы,
Кыйммәтле таш кына.
Каты ул, бары тик
Остага буйсына.

Алмаз!
Катырган аны гасырлар.
Алмаз!
Данлыйм аны, мактыйм –
Күңелемдә туа ак җырлар.

Алмаз!
Шундый саф ул, үтә күренмәле,
Балкуыннан йөзләр яктыра.
Тишеп үтә тыгыз катламнарны,
Пыяланы кисә сак кына.

Бөек матурлыкка хезмәт итә,
Шуның өчен дә ул... алмаз!
Мин ышанам: алмаз коралны
Кеше уйлап табалмас!

***Л.Лерон** тәрҗемәсе* ■

«Codex cumanikus» – төрки мирас

Иршад Гафаров

1880 елда Будапешт шәһәрендә венгр галиме Геза Кун тарафыннан «Codex cumanikus» исемле хезмәт нәшер ителә. Ул 1294-1303 елларда католик миссионерлары (итальян һәм немец монахлары) тарафыннан язылган латин-фарсы-куман (кыпчак) сүзлеген тәшкил итә. Бездә ул «Куман мәҗмугасы» исеме белән мәгълүм. Элек Европада кыпчакларны «куман», руслар исә «половец» дип атап йөрткәннәр. Олжас Сөләйманов язуынча, бу халыкның ыру тамгасы ике пычак рәвешендә булган. Соңрак «ике пычак» сүзе «кыпчак»ка әйләнгән икән.



Мәҗмуганың төп язылу урыны итеп Кафа шәһәрен санарга кирәк, чөнки бер францисканец монахның хатында шундагы монастырь мәктәбендә татар теле укытылу турында әйтелә. Ихтимал, латин-фарсы-куман сүзлеге һәм христиан тәгълиматы өземтәләреннән тәрҗемәләр шушы мәктәп өчен эшләнгәндер дә.

Биредә кыпчак теле турындагы мәгълүматка да тукталып үтәргә кирәк. Көнбатыш Аурупа сәяхәтчеләре ерак Азия илләренә барганда кыпчак телен халыкара тел буларак файдаланырга мөмкин, дип санаган. Украин милләтеннән булган тюрколог, филология фәннәре докторы, гомеренең 30 елдан артык өлешен «Кодекс...»ны өйрәнүгә һәм тәрҗемә итүгә багышлаган А.Н.Гаркавец менә ниләр яза: *«Алтайдан алып Дунайга кадәр булган аралыкта яшәүчеләр 700 ел элек хәзерге төрки халыкларның ерак бабалары булган кыпчак телендә сөйләшкән. Бу телне белми торып, зур мәйдан биләгән Евроазия киңлегендә аралашу мөмкин булмаган. Икенче төрле әйткәндә, кыпчак теле ул заманда, хәзерге чорда инглиз, кытай, рус һәм бүтән халыкара телләр үти торган вазыйфаны башкарган»*. Танылган рус галиме, тюрколог, этнограф Н.А.Баскаков болай дип искәртә: *«Урданың төп халкы, шул исәптән көнчыгыш*



Аурупа халыклары буйсындырылганнан соң, монголларның югары катлавы белән кушылып, Алтын Урдада сарай тирәсенә елышкан аксөякләрнең дә күп өлеше кыпчаклардан була. Шуңа да ул чорда Алтын Урдада өстенлек итүче тел – кыпчак теле».

«Куман мәҗмугасы»ның төп максаты – миссионерларга кыпчак телен өйрәтү һәм шуның нигезендә Алтын Урда халкын христиан тәгълиматы белән таныштыру. «Ходайның ун васыяте» һәм башка дини китаплардан тәрҗемә ителгән өзекләр шуңа дәлил. Китапта кыпчак сүзләре латин графикасында бирелгән. Шунысы игътибарга лаек: кыпчак теле латинча – *comanicum* (куман), кыпчакча – *tatar tili* (татар теле) дип язылган.

Бу кулъязма 1362 елда Франческо Петрарко тарафыннан Венеция Республикасына бүләк итеп бирелә һәм Изге Марк китапханәсендә саклана. XIX гасыр башында ул, Наполеон фәрманы белән, Париж китапханәсенә күчерелә. Бу турыда китапның беренче һәм соңгы битендәге Париж Милли китапханәсе тамгасы раслый. Соңрак кулъязма яңадан Венециягә кайтарылган.

В.В.Радлов әлеге китапка кертелгән 2223 сүзнең 1781е, ягъни 80 проценты татар телендә кулланыла, дип раслый. Галим, куман теленең төрки телләр арасындагы уры-

нын күрсәтергә теләп: *«Куман сөйләше, аерым алганда, Идел буе сөйләшләренә, бигрәк тә мишәр сөйләшенә якын тора»,* – дип яза. В.В.Радлов шул ук вакытта куман теленең хәзерге мишәр шивәсенә караганда күпкә борынгырак булуын да ассызыклый. Бу турыда: *«Кодекс мәгълүматлары Идел буе татарлары сөйләшенең фонетика өлеше 500 ел чамасы вакыт эчендә бик азга үзгәрүен раслый»,* – ди.

Мәҗмугадагы күп сүзләрнең төркиләрдән славяннарга да үтеп кергәнен әйтик. Мәсәлән, «кирпеч» сүзе «пичтә кипкән балчыкны» аңлата. Борынгы руста кирпеч сүзен бөтенләй белмәгәннәр һәм аны «плита» дип атаганнар. «Плита»ны исә руслар греклардан алган, грек телендә кирпеч – «плинтос». Мурад Аджи язганча, «ызба» сүзе «исбина» дигән борынгы төрки сүздән алынган һәм «җылы бина» дигән мәгънәне аңлата. Күп вакытлар үткәннән соң да «ызба» сүзе мишәрдә генә түгел, бүтән сөйләшләрдә дә яшәвен дәвам итә. «Мәҗмуга»да телгә алынган һәм барыгызга да мәгълүм «товарищ» сүзе дә төрки мирас. Кыпчак теленнән руска металл атамалары, кыйммәтле таш, кием-салым, көнкүреш, ат асрау, хәрби, икътисад һәм башка тармакка караган терминнар күчкән. Бу сүзләрне итальяннарның руслардан белүе шикле. Әлеге чорда Ука елгасыннан көньяктарак славяннар да, аларның бердәм дәүләтчелеге тә булмый, кенәзлекләр һәркайсы аерым, үзара ызгыш-тартышта көн күрә. Итальяннар русларның нинди бинада яшәвен түгел, хәтта аларның якты дөньяда барлыгын да белмәгән, дип уйларга кирәк. Мәгълүм ки, С.Герберштейнның 1517-1526 еллардагы сәяхәте турындагы «Записки о Московских делах» исемле язмасы халыкка таралганнан соң гына европалылар өчен Рус дәүләте ачыла. Бу вакытта инде «Куман мәҗмугасы» язылып, 200 ел вакыт үткән була.

«Куман мәҗмугасы» «Слово о полку Игореве»ның асылына төшенү өчен дә затлы чыганак. Чөнки рус әдәбиятының йөзек кашы дип саналган бу әсәрдә «Куман мәҗмугасы»нда булган күпсанлы кыпчак сүзләрен күрәбез. Атаклы тюрколог Н.А.Баскаков, «Слово...»ның авторы төрки дөньяны бик яхшы белгән, дип яза. Аңлашыла ки, телне белү өчен кыпчаклар белән тыгыз, ә бәлки туганнарча аралашып яшәү дә кирәктер.

***

Бу урында «Куман мәҗмугасы»нда хәзер дә татар телендә булган сүзләрнең кайберләрен генә укучыларыбыз игътибарына тәкъдим итмәсәк, язмабыз тулы булмас иде. Аларны АКШ тарихчысы, тюрколог, исламны өйрәнүче Голден Питер Бенджаминның ошбу мирасыбызга багышланган хезмәтеннән алырга булдык. Без бу сүзләрне шул чор авторы язганча, ягъни мишәрчә яңгыраштa бирдек.

Көн, географик, әйләнә-тирә мохиттә кулланылган атамалар: *tusambe* – дүшәмбе, *sesambe* – сишәмбе, *caarsambe* – чәршәмбе, *pansanbe* – пәнҗешәмбе, *aybasi* – ай башы, *kun towusu* – көнчыгыш (көн туу), *kun batisi* – көнбатыш, *jahan* – җиһан, *tengiz* – диңгез, *tag* – тау, *yol* – юл, *terek* – тирәк, *yemis* – йөмеш, *saar* – шәһәр, *saray* – сарай, *ev/ew* – өй (мишәрдә – ү), *kopru* – күпер, *cipciq* – цыпцык, *qaraqus* – каракош, *qarciga* – карцыга, *turna* – торна, *yabalaq* – ябалак, *sigirciq* – сыерцык, *tizi goy* – (мишәрдә – теше) сарык, *qocqar* – кучкар, *it* – эт, *maci* – мацы, *qoyan* – куян, *br* – бүре, *sicqan* – тыцкан, *cibin* – цебен, *bit* – бет, *qandala* – кандала, *bu kn* – бүген, *kece* яки *tn* – кич, төн, *kn* – көн, *hawa* – һава, *su* – су, *yer* – җир, *ot* – ут.

Сәүдә, тауар атамалары: *aqca* – акца, *borclular* – бурыцлылар, *seker* – шикәр, *bal* – бал, *burc* – борыц, *ot* – үлән, *altun* – алтын, *oymaq* – уймак, *ip* – җеп, *teyn* – тиен, *cekmen* – цикмән, *teri ton* – (тире) тун, *basmaq* – башмак, *balta* – балта, *kzg* – көзге, *tuqmaq* –

тукмак, *satuqci* – сатуцы, *kendir* – киндер, *baliq* – балык, *ipeq* – йөфәк, *tlemek* – түләү, kebit – кибет, *boday* – бодай, *arpa* – арпа, *bircaq* – борцак, *un*– он, *yogurt* – йогурт.

Кеше, гәүдә өлешләре: *kisi* – кеше, *bas* – баш, *manglay* – маңгай, *qas* – каш, *kirpik* – керфек, *qulaq* – колак, *kz* – күз, *burun* – борын, *yangaq* – яңак, *tis* – теш, *tiz* – тез, *til* – тел, *gursaq* – корсак, *icex* – эцәк, *am* – гаурәт (мишәрдә – амауыз), *tamar* – тамыр (кан), *qan* – кан, *qol* – кул, *barmaq* – бармак, *ayaq* – аяк, *saqal* – сакал, *kngl* – күңел, *kormek* – күрмәк, *esitmik* – ишетмәк, *iylamaq* – еламак.

Өй, төзелеш, кием-салым: *izba* – ызба, *acquc* – ацкыц, *qadav* – кадак, *olturgic* – утыргыц, *tb* – фундамент, төп, *tas* – таш, *kum* – ком, *su* – су, *taqta* – такта, *kerpic* – кирпец, *yanciq* – янцек, *kepes* – кәпәц, *brk* – бүрек, *calma* – цалма, *etik* – итек, *basmaq* – башмак, *qamci* – камцы, *araba* – арба.

«Куман мәҗмугасы»нда иллеләп табышмак та бирелә. Шуларның берничәсен генә булса да укучыларга тәкъдим итәргә кирәк, дип саныйбыз: *Olturganim oba yer basqanim baqir canaq* – утырганым – калкулык *(ат сырты),* басканым – бакыр кубок. Җавап – өзәңге. *Yazda yavl toqmaq yatur. Ol – kirpi*. Кырда (безнең карашка, «язда») калын тукмак ята. Ул – керпе. *Aq qoyni avuzi yoq. Ol – yumurtqa*. Ак сарыкның авызы юк. Ул – йомырка. *Buruncïz buz teser. Ol qoy bogu*. Борынсыз боз тишәр. Ул – куй *(сарык)* тизәге.

Без «Кодекс...»ның дин әһелләренә кулланма өчен язылганын әйткән идек. Шуңа күрә дингә кагылышлы берничә генә сүзне дә бирик: *peygamber* – пәйгамбәр, *friste* – фәрештә, *Tengri* – Тәңре, *Maryam gaton* – Мәрьям катын / хатын (ана), *yarligamaq* – ярлыкау, *xac* – тәре. *Tengrini svgil barca stnde* – Тәңрене сөю барсыннан да өстен. *Atangi anangi xormatlagil* – атаңны, анаңны хөрмәтлә. *Ogur bolmagil* – карак (угры) булма. *Yalgan tanixlig bermegil* – ялган шаһит булма.

***

Әлеге сүзләрне укыганда күңелдә татар теле өчен горурлык хисе туа. Моннан 700 ел элек гамәлдә булган хәзинә бүген дә минем өчен аңлаешлы һәм таныш. Чагыштыру өчен рус теленә мөрәҗәгать итик. Җиде гасыр түгел, ә 300 ел элек язылган текстларны да тел белгечләре генә, әле аларның да бу юнәлештә махсуслашканнары гына укый һәм аңлый ала.

«Куман мәҗмугасы» Казакъстанда һәм Румыниядә нәшер ителгән. Аны өйрәнүгә венгр, америка, украин, румын, рус, казакъ галимнәре күп көч сарыф кылган. Кызганыч ки, бу китап әлегә кадәр милләттәшләребез тарафыннан татарча кереш сүз һәм аңлатмалар белән басылмады. Ватиканнан «Казанская божья матерь» иконасын кайтару буенча республиканың шактый гына дәрәҗәле кешеләре эш алып барды. Шуның нәтиҗәсе буларак, күпсанлы христиан әлеге иконаны күрү, аңа табыну бәхетенә иреште. Әмма Ватиканда саклана торган иконадан берничә йөз ел элек дөнья күргән, төрки халыкларның бәһасез мирасы булган әлеге китапның күчермәсен генә булса да республикабызга алдыру турындагы фикерне безнең әлегә кадәр ишеткәнебез юк. Бу уңайдан янә А.Н.Гаркавецның сүзләрен искә аласы килә. *«Мине немецларның истәлекләрне нәшер итүгә булган мөгамәләсе таң калдырды. Әгәр нинди дә булса китапта Германия турында бер яки ике сүз генә табылса да, алар әлеге истәлекне тулаем бастырганнар»,* – дип яза галим. Ә бит «Кодекс...»та татар исеме берничә сүз белән генә искә алынмый. Киләчәктә төрки халыкларның ядкәре булган «Куман мәҗмугасы» да Казанга кайтыр, аны өйрәнүче, Татарстан китап нәшриятында бастырып, халкыбызга җиткерүче яшь галимнәребез дә булыр, дигән өметтә калам. ■

Безнең мирас №6 июнь 2018

ИСЛАМ ДӨНЬЯСЫ

Габдерәшит Ибраһимов

Иркутск (Өркет). XIX гасыр

ИРКУТСК МУЗЕЕ

Беркөнне музейны карарга бардым. Иркутск музее тулысынча Көнчыгыш яшәеше белән бәйле әсәрләрдән оешкан иде. Бигрәк тә этнография бүлеге бик бай. Буддизм һәм шаманизмга караган күп санлы сәер әсәр бар. «Бурхан» ди атала торган җисемләштерелгән тәңренең нинди генә юк, чын бәясен билгеләп бетереп булмаслык кыйммәтле ташлар белән бизәлгәннәре дә бар. Музейга барлыгы 158 бурхан куелган.

Моннан тыш, монгол язуы белән язылган төрле-төрле догалар да бар. Мәсәлән, бала еламасын өчен, авырудан саклану өчен, күз тимәсен өчен аерым-аерым догалар. Сәнгать осталары язып калдырган мактаулы бәяләмәләрдән дә аңлашылганча, болар сәнгати югарылыкта язылганнар. Барысы да монгол язмалары.

Дәвамы. Башы журналның 1 нче (2017) санында.

Игътибарымны җәлеп иткән нәрсәләрдән берничәсе турында биредә дә язып үтәчәкмен. Бер агач тамырының тармакларына 11 кеше рәсеме урнаштырылган. Һәммәсе дә бер үк агачның тамырлары. Хамба Ламаның аңлатуы буенча, бу рәсемнәр Будда һәм аның укучыларының рәсемнәре икән. Тагын берсе – бер бурят даруханәсе, тәлинкәле кечкенә үлчәүләре дә куелган. 212 ел элек ясалган хәреф басу калыбы ул вакытларда ук Монголиядә басмаханә булганлыкка дәлил булып тора. Каен тузыннан ясалган көймә, ишкәкләре нәкъ безнең Истанбул каекларының ишкәкләрен хәтерләтә. Бу бик гаҗәеп сәнгать. Көймә биш кешене алып су өстендә йөзә ала, ә үзенең авырлыгы, ишкәкләрен санамаганда, якынча 28,5 кг гына. Бу көймә Минусия татарларыннан алынган, алар андый көймәләрне Енисей, Ирбә елгаларында кулланалар икән.

Әлеге музейда Көнчыгыштагы тормыш белән бәйле башка әһәмиятле әсәрләр дә бар, ләкин алар, музейның ачылуына инде 25 ел үткән булса да, әлегә тәртипкә салынмаганнар.

ГОСМАНЛЫ МИЛЛӘТ МӘҖЛЕСЕ ҺӘМ ИРКУТСК МӨСЕЛМАННАРЫ

Иркутск шәһәрендә 5 нче декабрь җомга көнне кичке телеграф белән Истанбулдан Милли Мәҗлеснең ачылуы турында хәбәр килде. Шул кичне үк бөтен Иркутск мөселманнары бергә җыелдылар, чыгышлар ясап, шатлыкларын белдерделәр, дога кылдылар. Тик ул җитди һәм самими изге теләкләрен һәм шатлыкларын Милләт Мәҗлесенә телеграф җибәреп, тәбрикләрен ирештерә алмадылар, моңа хөкүмәт басымы астында булган һәм ул кушканча эш итүче телеграф хезмәткәрләре каршы төште. Ни генә булса да, Истанбулдагы мөселман кардәшләренең гомерлек хөррият бәйрәмнәренә, тирәннәрдә әрнегән сызлаулы йөрәк хисләре белән бәйләнып булса да катнаштылар.

Шунысына шөкер итәргә кирәк, бөтен Госманлы мөселман кардәшләребезнең иртән йөрәкләрендә туган хөррият сөенече кичен Иркутск мөселманнарының йөрәкләрендә дә балкыды. Гүя чыбыксыз телеграфлар йөрәкләрне бергә бәйләде, ул көнне Иркутск мөселманнарында күргән сөенечне бәйнә-бәйнә язарга уйласам, бу кәгазь битләре генә җитмәс иде. Себер сәяхәтем белән Госманлы Милли Мәҗлесе арасындагы бәйләнешне уйлап кына, бу кадәре белән чикләнәм.

Иркутск шәһәрендә 15 көн торганнан соң, Верхнеудинск шәһәренә юл тоттым. Биредә сәфәрем Байкал күле яныннан үтсә дә, төн караңгылыгына туры килгәнгә, берни дә күрә алмадым. Бары тик вагон эчендә утырып, ул куркыныч туннельләрдән үтүебезне тойдым. Байкалны әйләндереп алган матур табигатьне күрү безгә насыйп булмады.

ДАСАН – ГЫЙБАДӘТХАНӘ БУДДА, ЛАМА, ШАМАН МӘЗҺӘПЛӘРЕ ТУРЫНДА

Верхнеудинск шәһәренә килүгә, берничә кеше белән күрешеп сөйләшкәннән соң, бу шәһәрдән 70-80 км ераклыкта, Кытай чигендә урнашкан атаклы Кяхта шәһәренә таба юл тоттым. Казлар күле дип аталган җирдә, дасанда, ягъни монастырьда яшәүче, Будда диненең икенче зур кешесе, мәшһүр Хамба Лама җәнаплары белән күрешү фикере белән, җигүле ат чанасына утырып, шул монастырьга киттем.

Будда диненең бөекләре – ике кеше, шуларның берсе – атаклы Далай Лама һәрвакыт Тибетта яши, икенчесе исә – Хамба Лама, ул Монголиядәге бурят кавеменнән чыккан кеше, дасанда, ягъни монастырьда тора. Бу ике кешедән кала, буддистлар илаһи дип саный һәм «хотото» дип атый торган тагын бер кеше бар – анысы исә, Кытай чикләре эчендә булган Урга шәһәренең көнбатышында бер мәгарәдә гомер итә. Аны «тере илаһ» дип атыйлар.

Минем бу юлы күрешеп сөйләшергә теләгән кешем – менә шул, чыгышы буенча бурят булган Хамба Лама иде. Бу шәхес Монголиядә бик зур хөрмәткә ия һәм, әйткәнемчә, дасан-монастырьда яши. Мин, әле янына барып җиткәнче үк, аның турында бераз мәгълүмат алган һәм нинди кеше икәнен дә беркадәр аңлаган идем.

Декабрь аеның унысында иртән иртүк монастырьга килеп җиттем. Бу җирне хөрмәтле укучыларыма ничек аңлатып бирим икән? «Саумаа» , дисәм, барыбер аңлашылып бетмәс. «Монастырь», дисәм, бәлки беркадәр дөреслеккә туры килер. Бу җирне тасвирлап бирү өчен, башта буддизмдагы Лама мәзһәбе турында бераз булса да мәгълүмат бирергә кирәк.

ЛАМА МӘЗҺӘБЕНЕҢ ТӘГЪЛИМАТЛАРЫ

Адәм баласы, гомумән, гөнаһ эчендә яши, гөнаһка баткан. Эш-хәрәкәтенең дә һәммәсе гөнаһ, чөнки адәм баласының яратылышы да гөнаһтан, ир белән хатынның табигый мөнәсәбәтеннән барлыкка килгән. Шулай булгач, адәм баласын бу гөнаһтан коткару өчен нишләргә кирәк? Ирне хатыннан аерып, аларның бергә булуларын катгый рәвештә тыярга. Аерым яшәсеннәр, һич булмаса бер өлеше ул гөнаһтан котылып, башкалары өчен яклаучы булсыннар.

Дасан – менә бу ышануга таянып, ирләрне хатыннардан аеру өчен төзелгән авыл кебек бер җир. Бу авылда ирләрдән башка кеше юк. Хәтта әтәч бар, ә тавык юк. Биредә яшәүче ирләрне лама дип, ә җитәкчеләре булган кешене Хамба Лама дип атыйлар. Без менә шул Хамба Лама белән күрешергә килдек.

ДАСАН, ЭТИКЕТ, ХАМБА ЛАМА

Дасан дип атала торган бу җир бик төзек, ягъни план белән төзелгән. Кечкенә-кечкенә, бер катлы, бер генә бүлмәдән гыйбарәт өйләр, туры урамнар, рәт-рәт, ялтыравыклы каплама белән бизәлгән дүртпочмаклы бик зур гөмбәзләр. Биредә якынча 250, бәлки дә 300 йорт бар, күз алдына китереп карагыз – ник бер хатын-кыз булсын?!

Мин бирегә килгәч, башта туры кунак өенә урнаштым. Бераз ял итеп алганнан соң – Хамба Лама җәнапларына хәбәр бирелгән булып чыкты – ул миңа «хуш килдегез» диюен тапшырырга махсус бу төр эшләрне башкаручы лама җибәргән иде.

Ламалар һәрвакыт сары озын күлмәк киеп йөриләр. Тантаналар вакытында билләрендә кызыл билбау була икән, ул билбауның бер очын иңбашлары аша үткәрәләр һәм ул тасма кебек салынып тора. Һәрвакыт яланбаш йөриләр.

Ярты сәгатьтән соң, этикет буенча махсус билгеләнгән лама белән, мин Хамба Лама хозурына килдем. Хамба Ламаның йорты зур, кечкенә-кечкенә бүлмәләрдән гыйбарәт һәм гаять ару иде. Без тышкы ишектән кергәндә, Хамба Лама безне эчке ишектә көтә иде, безгә таба бер-ике адым атлап, русча: «Хуш килдегез! Рәхим итегез!» – диде. Мин килеп җиткәч, кул биреп исәнләште, шулай кулымнан тоткан килеш, эчке ишектән бергә кердек.

Хамба Лама урта буйлы, түгәрәк йөзле, йөзеннән исә акыллы һәм сабырлы булуы аңлашылып тора иде. Өйнең эченә кергәннән соң, утырырга урын күрсәтте, кабат: «Хуш килдегез!» – диде, сөенгән булуын белдерде. Саф рус телендә сөйләшә иде. Хамба Ламаның бу бүлмәсе кечкенә генә һәм монда яшәүче ирнең өйләнмәгән кеше булуы беренче карашка ук аңлашыла иде. Бүлмәдә бер кешелек урын-җир, ике юл биштәре һәм бер телефон бар. Алардан кала, берничә изге сын – бурхан бар, башка берни юк иде.

---

[1] Саумаа – госманлы-төрек телендә гыйбадәтханә мәгънәсендә кулланылган (тәрҗ. иск.).

Иркутск (шәһре Өркет) җәмигъ мәчете

ХАМБА ЛАМА БЕЛӘН ӘҢГӘМӘБЕЗ

– Сезне күрергә килүемнең максаты – Сезнең белән танышу һәм Сезнең белән сөйләшеп белем-мәгълүмат алу.

– Мин бик шат. Петербургка баргач, Сезнең исемегезне ишеткән идем, ләкин күрешеп сөйләшү насыйп булмады. Күрсәткән илтифатыгызга чиксез сөендем.

– Мин башта Сездән ишетеп белергә теләгән кайбер нәрсәләр турында сорау бирмәкче булам, аннан соң бик игътибар белән тыңлаячакмын.

– Рәхим итегез, мин әзер.

– Сезгә гозерем шул: иң башта миңа Лама мәзһәбенең тәгълиматлары хакында сөйләсәгез иде. Ламаларның ышанулары нидән гыйбарәт? Лама динендә илаһилык нәрсә? Пәйгамбәрлек нәрсә? Гыйбадәт нәрсә? Ламалык үзе нәрсә аңлата? Шаманлык нәрсә?

Болардан соң, бурятларның иҗтимагый һәм сәяси тормышы, киләчәге турында бераз мәгълүмат бирүегезне үтенәчәкмен. Иркенләп әңгәмә кору өчен, башта үзем белән таныштырып үтим. Мин – Тобольск губернасында туып үскән татар кешесе. Яшь чагымда Истанбулда һәм Гарәбстанда белем алдым. Берара Оренбург Шәригать мәхкәмәсендә эшләдем, соңгы елларда Петербургта яшәдем. Газета чыгара идем, хөкүмәт басымы белән газетам ябылды. Аннан соң менә сәяхәткә чыктым.

– Борчылмагыз, мин Сезнең белән бик иркен һәм ачык сөйләшәчәкмен, чөнки Русиядә рус булмаган милләтләр бер-берләре белән уртак фикердәләр, чирләре уртак. Моннан тыш, әле Сезне беләм дә, ышанычым бөтен.

Безнең Будда дине бик күп тармакка аерылган, күбесе хәтта буддизмнан читкә дә чыккан. Бездә Аллаһ юк, җаһил бәндәләр Аллаһ дип саный торган бурханнар – йә Буддаларның, йә буддизмга хезмәт иткән бөек шәхесләрнең сыннары гына.

Буддада монгол язуы белән язылган 101 китап бар. Тагын шуны да аерып әйтәсем килә: Сезгә сөйләячәк сүзләремне, иң әүвәл Будда галиме буларак сөйләячәкмен, соңыннан үзем булып, шәхси фикер һәм инануларымны да белдерәчәкмен.

Дәвамы бар

Төрекчәдән ***Асия Рәхимова*** *тәрҗемәсе* ■

Аяз Гыйләҗев һәм мин

Фатих Кутлу

«Өч аршын җир» повесте төрек халкы арасында искиткеч кызыксыну уятканнан соң, остазымның «Җомга көн кич белән» әсәрен тәрҗемә итәргә алындым. Бу эшкә кемнеңдер киңәше, тәкъдиме яки кушуы буенча түгел, ә повестьны үзем бик яратканга һәм халкымның да яратачагына чын күңелдән ышанганга күрә керештем. Аны төрекчәгә аудару чәчләремне агартты, дисәм, һич арттыру булмас. Гомеремнең дүрт елын шуңа багышладым. Повесть Төркиядә басылып чыкканнан соң, төрек укучылары Аяз Гыйләҗевнең бөеклегенә тагын бер кат инанды. «Өч аршын җир»нең очраклы уңыш булмавына, язучының, чыннан

Аяз Гыйләҗевнең тоткынлыкта төшкән фотосы. 1954 ел

Ахыры. Башы журналның 5 нче (2018) санында.

Аяз Гыйләҗевнең Фатих Кутлуда саклана торган күзлеге



Аяз Гыйләҗевнең Төркиядә дөнья күргән «Яра» китабының тышлыгы. 2018 ел

да, олуг, мәгърур әдип икәнлегенә тамчы да шикләре калмады. Ул вакытта хөрмәтле галим Тәлгат ага Галиуллинның бу әсәргә биргән бәясен белми идем әле мин: *«Башка әсәр язмаса да, – ди ул, – «Җомга көн кич белән» повесте белән Аяз Гыйләҗев татар әдәбияты тарихында калыр иде»*[1]. Миңа әнә нинди әсәр тәрҗемә итү бәхете тигән икән!

Төркиянең мәдәни дөньясы миннән Аяз аганың яңадан-яңа тәрҗемәләрен көтә башлады. Абделкадыйр Чәкич исемле галим төрекчә чыккан шул ике әсәрдән илһамланып, Аяз Гыйләҗев иҗаты буенча фәнни эш язарга кереште. Һәм, ялгышмасам, узган ел Истанбул университетында «Аяз Гыйләҗев әсәрләрендә мәдәният көрәше» темасына кандидатлык диссертациясен яклады да.

Төрек галимнәренең киңәшенә күнми булмый иде: «Нинди дә булса чит ил әдибе төрек әдәбиятында үз урынын алсын өчен, аның бер-ике әсәрен аударып кына чикләнергә ярамый. Тәрҗемә әсәре күбрәк булган саен, әдип турында күзаллау һәм фикерләү дә тулырак булачак. Бу исә әдәбият-фән дөньясына нәтиҗәлерәк эшләргә этәргеч бирәчәк», – диде алар миңа.

Җөмләдән, шуны да әйтим: фәкыйрегез тәрҗемәсендә Төркиядә дөнья күргән татар әдәбияты үрнәкләре җәмгысе ун китапка җыелып, аның икесе генә Аяз Гыйләҗевнеке иде. «Иде», – дип әйтүемнең сәбәбе шул: быелгы февраль аенда, Аллаһка шөкер, остазымның «Яра» повестен да тәрҗемә итеп чыгара алдым.

Әлеге әсәр турында Аяз Гыйләҗев: *«Яра» – минем йөз аклыгым... <...> җаныма иң якыны – «Яра»*, – дип язып калдырган. Аның бу сүзләренә мин шушы көннәрдә генә юлыктым...

Төрекчә укыганнан соң, «Яра» әсәре хакында төрек язучысы, галим Рәҗәп Шүкрү

[1] Аяз Гыйләҗев. Истәлекләр китабы. – Казан: Татарстан китап нәшрияты, 2006. – 58 б.

Гүнгөр саллы гына фәнни мәкалә язды. Ул киләсе айларда Казанның бер гыйльми журналында дөнья күрергә тиеш. «Язгы кәрваннар», «Яра», «Мәхәббәт һәм нәфрәт турында хикәят» кебек әсәрләрен тәрҗемә иткәндә, ихтыярсыздан: «Аяз Гыйләҗев, һичшиксез, повесть остасы! Мин аның әсәрләренә алынып бер дә ялгышмаганмын икән!» – дип сөенә-сөенә кабатлый тордым үземә.

Аяз аганың дөнья халыкларына тәкъдим итәрлек бик саллы, бай мирасы бар. Бу хәзинәне, көчемнән килгәнчә эшләп, үз халкыма күрсәтергә гомерем җитәрме – әйтүе кыен. Шулай да, киләчәктә, сүз ара сүз китепме, минем хакта: «Ул Аяз Гыйләҗевне төрек әдәбиятына керткән кеше», – дип искәртеп узсалар, җирдә миннән дә бәхетлерәк кеше булмас иде.

***

Бу урында тагын бер сөенечемне уртаклашасым килә. Күптән түгел Нәкыя ападан (Аяз аганың җәмәгате), тартынып булса да: «Остазымның берәр күзлеге юкмы? Аның төсе итеп гомер буе кадерләп саклар идем», – дип сорадым. Нәкыя апа иренең бер күзлеген дә ташламаган икән. Шулай да, үтенечем аның өчен көтелмәгән хәл булды. Тиз генә ризалашырга ашыкмады. Ул аларны киләчәктә музейларга тапшырырга ниятләгән икән. Ахыр чиктә, барыбер күндерә алдым. Озак еллар татар әдәбияты классигы, олуг әдип Аяз Гыйләҗевнең күз алдында йөргән, дөньяны үзенең пыяласы аша күрсәткән, күпме әсәрләрен, хатларын яздырган, күз нурларын үткәргән күзлеге – әдипнең бер өлеше! – бүген минем бәһасез хәзинәмә әверелде.

***

Журнал укучылар да (элекке язмаларымнан күреп), таныш-белеш тә минем саннарга, вакыйгалар бәйләнешенә игътибар итәргә яратуымны белә. Аяз Гыйләҗевкә бәйле кайбер кызыклы фактларга дикъкатегезне юнәлтимче...

«Өч аршын җир»не төрекчәгә тәрҗемә итү теләге без Аяз ага белән танышып 8 ел узгач, 2008 елда тормышка ашты. Әсәр Төркиядән әдипнең тууына 80 ел тулу уңаеннан бүләк булып кайтты. 8 саны!

Әсәр 1962 елда язылган. Төрек телендә, искәргәнчә, 2008 елда басылды. Арада 46 ел гомер. Бу – туган шәһәрем Каһраманмарашның дәүләт номеры: 46.

Югарыда телгә алынган фактны очраклылыкка сылтап була, әлбәттә. Әмма басманы кулга алып, ачып карасам, ни күзләрем белән күрим: ул – нәшриятның 46 нчы китабы булып дөнья күргән икән! Өстәвенә, февраль аенда нәшер ителгән (бездә һәр китапның кайчан чыгуы тәүге биттә күрсәтелә). Ә 12 февраль – Каһраманмарашта Котылу, ягъни Җиңү бәйрәме буларак билгеләнеп үтелә.

«Яра» әсәре 2018 елның февраль аенда, әдипнең 90 еллыгына багышланып чыкты. Аяз Гыйләҗевнең ошбу юбилее Камал театрында 12 февраль көнне, ягъни Каһраманмарашның Котылу бәйрәме көнендә үткәрелде!

Һиҗри (ай) календаре буенча исәпләсәң, Аяз Гыйләҗев 1346 елның 23 рәҗәбендә туган икән (үз нәүбәтендә, 23 саны да 46ның яртысы).

Аяз Гыйләҗевләр яшәгән йорт тукталышыннан Займищедагы бакчаларына фәкать 46 нчы автобус кына йөри.

Остазым 1928 елда туган. Мин – 1974тә. Арада – 46 ел.

Төрле урамнарда торсак та, яшәгән йортыбызның номеры бер үк – 35. Безнең тукталыштан аларга һәм, киресенчә, алардан безгә фәкать 35 нче автобус кына йөри.

Остазымның 3 баласы бар, минекеләр дә 3. Ул беренче мәртәбә 30 яшьтә әти булган, мин дә шулай. Соңгы тапкыр 40 яшьтә әти булган, мин дә шулай.

Сулдан уңга: Аяз Гыйләҗев әсәрләрен урыс теленә тәрҗемә иткән Наил Ишмөхәммәтов, маҗар (венгр) теленә тәрҗемә иткән Арпад Галгоци һәм төрек теленә тәрҗемә иткән Фатих Кутлу. 2017 ел. Солтан Исхаков фотосы

Олы кызым Рауза исемле. Нәкыя апа бер сөйләшеп утырганда болай дип сөйләгән иде: «Беренче балама көмәнле чакта Аяз: «Малай булса – Искәндәр, кыз булса, Рауза кушабыз», – диде. Безнең малай туды. Берничә елдан кабат авырга узгач: «Малай булса – Мансур, кыз булса, Рауза кушабыз», – диде. Мин тагын малай алып кайттым. Өченче юлы: «Малай булса – Рәшат, кыз булса, Рауза кушабыз», – диде. Өч ир-егетле булдык. Әмма Рауза насыйп булмады». Моны ишеткәч, ис-акылым китте. Нәкыя апаның бу сүзләрен видеокамерага да яздырып алдым. Үзем исә өйләнгәнче үк: «Киләчәктә кызым туса, Рауза исемен кушам», – дип хыялланып йөргән идем.

Аяз Гыйләҗевнең бабасы Сәхабетдин хәзерге Сарман районының Мортыш Тамак авылы мулласы була. Аның 1930 елда кулга алынып, Алабуга зинданында кыйнап үтерелүе турында остазым «Төркиянең түренә үк уздык» хатирәсендә дә телгә ала. Сәхабетдин мулланың атасы Гыйләҗетдин мулла Төркиягә һиҗрәт итә. 1938 елга кадәр Измир шәһәре белән ике арада хатлар да йөри. Ул чорларда, нигездә, фамилия итеп ата яисә баба кешенең исеме алынган. Димәк, остазым да Сәхабетдинов яисә Сәхабиев булырга тиеш иде. Әмма ул, ничек шулай килеп чыккандыр, Төркиягә күчеп киткән, шунда гомер кичергән һәм шунда мәңгелеккә кичкән Гыйләҗетдин исемле карт бабасының (бабасының әтисе) исемен фамилия итеп ала.

Изге догасы кабул булгандыр, мөгаен: Гыйләҗетдин мулланың исеме оныгы аша мәңгеләшеп кенә калмый, аның китаплары аша, Аллаһ кушып, яңадан Төркиягә әйләнеп кайта. Шул рәвешле, исем-аты Төркиядә дә, дөньяда да бакыйлаша. Бу эшне башкаруда минем – гади төрек баласының да – хәл кадәри өлешем булу бәндәгездә чиксез куаныч һәм горурлык уята. ■

АЛТЫНГА ТИҢ КИҢӘШЛӘР

Рухия Ахунҗанова

Чүтри кәмин — дүрт таш,
Ниләр күрми безнең баш…

Автобиографик планда язылган «Агымсуларга карап» повестен чын ихластан яратып укып чыкканнан соң да, миңа тынгылык бирмичә, шушы ике юл башымда айкалды. Әлеге ике юллык такмак мине Шәйхи Маннур дигән язучыга «бәйләп куйды».

Миндә кечкенәдән үк җырлау, рәсем ясау, хат язу маһирлыгы бар иде. Мәктәп һәм авыл сәхнәләрендә «Ак пароход», «Үз илемдә» җырларын башкардым. Авылдашларыма рәхмәт, чыгышымны алкышларга күмәләр иде. Казанга Флюра Сөләйманова исеменә: «Җырчыларны кайда әзерлиләр?» – дип сорап хат язуым да хәтеремдә. Нигәдер, филармониядән җавап хаты килмәде. Мөгаен, Флюра апаның үзенең дә читтә чагы булгандыр.

9-10 яшьлек кызчыкның график ысул белән генә ясалган рәсемнәре дә республика газета-журналлары битләрен бизи алмады. Шартын китереп, ягъни тиешле буяулар кулланып иҗат ителмәгәнлектән, редакцияләрдән гафу үтенеп язылган хатлар гына килә иде.

Хатлар язуым исә бернинди киртәләргә дә очрамады. Хатлар яза-яза, мин язучылык дигән сихри дөньяга үз сукмагымны салганмын булып чыкты.

Хат дигәннән, язучының үз тормышы сурәтләнгән теге шәп повесть тәэсиреннән туган уйларымны, яшь тәнкыйтьче кебегрәк, Татарстан Язучылар берлегенә юлладым. Хатым Шәйхи ага Маннурга төгәл вакытында тапшырылган. Конверт белән салган

Шәйхи Маннур хатыны Тәгъзимә, кызы Миләүшә (матрос киеменнән) һәм апасы Хәдичәнең кызы Зәйнәп белән

тәнкыйть мәкаләм автор тарафыннан шулкадәр җылы кабул ителгән ки, ул үзе дә миңа җавап хаты җибәрде.

Шигырьләр язуым, хәтта Казанда да басыла башлавым белән мактанганлыктан, хат аша аны «иҗатым» белән дә таныштырырга туры килде. Күбрәк уңай якларына басым ясап, ул аларны «әлегә өйрәнчек шигырьләр» дип бәяләгән. Язучылык эшенең гаять тә авыр хезмәт икәнлеген исбатлап, озын итеп язылган хат иде ул. Миңа тормышны өйрәнергә, югары белем алырга, башкаларны укырга, һәм татарча, һәм русча шәп белергә кушып, акыллы киңәшләр бирелгән иде анда.

Ул минем башта – әтисез, аннары әнисез дә калып, әнкәйнең апасында үскәнемне хатларым аркылы белә. Үзе, миңа караганда да иртәрәк ана назыннан мәхрүм булганлыктан, хәлемне аңлый, шуңа күрә аталарча җылы мөнәсәбәт күрсәтә иде. Танышбелешләрем, шаяртып, мине «Шәйхи Маннур кызы» дип йөртә башладылар. Аның үз кызын – Миләүшәне әтисе фатирында бер тапкыр да очратмадым. Бик күп еллар үткәч кенә, Миләүшә Маннурова турында бераз мәгълүматлы булдым. Миләүшә Шәйхиевна Казан дәүләт университетында югары белем алган. 1970 елдан, ягъни Казан дәүләт мәдәният институты ачылганнан башлап, әдәбият һәм сәнгать тарихы кафедрасында эшләгән (хәзер әдәбият һәм татар теле кафедрасы). Идел буе халыкларының мәдәнияте һәм сәнгате, әдәби багланышларның бер-берсенә тәэсире турында фәнни эшчәнлек алып барган, мәкаләләр язган. Фән белән нәтиҗәле шөгыльләнгән. Монография, дәреслек, методик кулланмалар авторы буларак, республика күләмендә киң танылу алган. Институтта «Совет культурасы кадрлары өчен» исемле стенгазетаның мөхәррире вазыйфасын башкарган. Филология фәннәре докторы, доцент М.Ш.Маннурова турында КДУның 200 еллыгына багышлап нәшер ителгән «Казан университетын тәмамлаучылар» исемле белешмә-сүзлектә дә мәгълүмат бирелгән. Мәдәният институтында 1985-1990 елларда читтән торып белем алган бер танышым түбәндәгеләрне сөйләде. Миләүшә Шәйхи кызы Маннурова студентларга чит ил әдәбиятыннан лекцияләр укыган. Чит илләрдә алган сәяхәт тәэсирләре белән уртаклашкан. Мәсәлән, Голландия турында бик яратып, андагы муллыкка шаккатып сөйләгән. Чит ил язучыларының исемнәрен дөрес әйтелеш белән кулланырга өйрәткән. Үзе бик зыялы, укымышлы, әдәпле булган. Зәвык белән киенгән. Төскә-биткә дә бик чибәр, сөйкемле булган...

Кырыс табигатьле, ләкин гадел аксакал язучы белән якыннан аралашу бәхетенә дә ирештем. Түбән Камада шин заводында, аннары күрше авыл мәктәбендә эшләгәндә Казан дәүләт университетының татар журналистикасы бүлегендә читтән торып укыдым. Сессия вакытлары башлангач, Шәйхи аганың рөхсәте белән аның фатирында туктала торган булдым. Галактионов урамыннан университет якын. Транспортларда газап чикмичә, лекция һәм имтиханнарга җәяү генә йөрим.

Төгәл режим белән яшәгән язучының эш графигы алдан билгеле: иртәнге чәй, иҗат, «Татар ашлары йорты»нда төшке аш, шахмат клубы, кичке чәй... Мин белгәне шулар. Искәрмәләр дә булгандыр, әлбәттә. Тормыш бит... Ул шахмат клубында тоткарланса, күрше Рәбига апаларга кереп утырам. (Шәйхи Маннурның «Чын сөю бармы?» әсәрендә шул шахмат клубына йөргән картлар сурәтләнгән.)

Шәйхи ага миңа гел әдәбият, аның кануннары турында сөйли иде. Яшь кешенең фикерен ишетәсе килепме, миңа сораулар да биргәли. Әдәби процесстан хәбәрдар булуымны белгәч, йөзенә канәгатьлек билгесе чыга иде. «Кешене кабатлама. Озын-озак булса да, үз сукмагыңны сал», – дип әйтергә ярата иде ул. «Өйрәнчек шигырьләр – иҗатның караламасы. Аларны чиле-пешле килеш дөньяга чыгарырга ашыкма. Кат-кат эшкәрт. Ювелир да тупас әйбер тәкъдим итми, аны нәфисли, аңа күңел матурлыгын сала», – дип өйрәтә иде. Үзем белгәнне, үз күзем белән күргәнне, үз йөрәгем белән

тойганны, үз күңелем аша кичергәнне генә язарга куша. Шулай эшләгәндә генә, язган әйберемнең укучыны ышандыру көче бәхәссез булуына төшендерә иде.

Шәйхи ага: «Яшь вакытта күбрәк укып өлгерергә кирәк», – дип әйтеп килде. Безнең буын болай да яшьтән үк китап укып үсте. Хәреф таный башлауга, китапханәдән «Уф, арыдык» исемле матур рәсемле, йөгерек тел белән язылган китапны алып укуым әле дә хәтеремдә. Ул минем беренче китабым булды. Әлеге озын шигырьдә әсәр геройлары – кечкенә балалар – күп уйнап арыйлар. Сурәтләнгән һәрбер кыска эпизодтан соң, җырдагы кушымта кебек, «Уф, арыдык!» дигән тәгъбир кабатланып килә.

Шакмаклар тездек –
Уф, арыдык! –

дигән өлеше хәтеремдә аеруча уелып калган. Бу кызыклы китап китапханәдә бер генә данәдә булганлыктан, мин илтеп тапшыруга, башкалар да чираттан, формулярларына яздырып алып, бик яратып укыдылар. Еллар үткәч, кызыксынып, ул авторның кем булуын белә алдым. «Әдипләребез» биобиблиографик белешмә китабында Сафа Гыйльфан (1902-1950) турында шактый мәгълүмат бар. «Татар балалар поэзиясе антологиясе»ннән (ТКН, 1980) 8 куплетлы ул шигырьне, балачагыма кайткандай, яратып укыдым:

...Йөгердек,
Сикердек,
Уйнадык.
Бакчада
Саф һава
Суладык.
Уф, арыдык!
Җырладык,
Биедек,
Куандык.
Хәрефләр
Тезгәләп
Юандык.
Уф, арыдык!

Үзе дә бик күп классикларны татарча «яңгыраткан» олпат язучы, «ике телне дә яхшы үзләштерү өчен, практик күнекмә кирәк» дип, миңа тәрҗемә эшенә игътибар итәргә кушты. Шин заводында «Яшьлек» исемле стенгазетаны татар һәм рус телләрен бердәй кулланып чыгаруым гына җитмәячәк. (Алга китеп булса да әйтим: мин, гомумән, кайда эшләсәм яки яшәсәм дә, стена газеталары чыгарырга яраттым.) Телләрне исә, калын фәнни сүзлекләрдән файдалана-файдалана, чагыштырып өйрәнү кирәк булачак. Чыннан да, татар яисә рус телендә аерым-аерым, үзбаш язу күпкә җиңел шул. Чөнки син анда ак шигырьдәге кебек ирекле. Ә тәрҗемәдә автор белән ярышырга кирәк. Производстводагы социалистик ярыш кебек булып чыга инде бу. Эшемдә «Коммунистик хезмәт ударнигы» исеменә лаек булсам да (Гайҗан бабай алдынгы колхозчы булган кебек), Шәйхи ага «димләгән» ярышка кушылмыйчарак тордым. Әмма институтта укыганда, тел галиме Рүзәл Йосыпов – «Чагыштырма грамматика» дәресләрендә, шагыйрь һәм әдәбият укытучыбыз Әмир Мәхмүдов «Илһам» әдәби-иҗат түгәрәгендә бездән А.С.Пушкин, А.А.Блок, А.А.Ахматова һәм башкаларны барыбер тәрҗемә иттерделәр...



Шәйхи ага минем читтән торып укуымны ошатып җиткермәде. Ныклы белем алырга кайчан да соң түгел, дип, көндезге бүлектә укырга киңәш бирде. Университетның татар теле һәм әдәбияты бүлегенә керергә тәкъдим итте. Ләкин татарча да, русча да яхшы белергә кирәк, диде. Берьюлы ике телне дә шәпләп өйрәнү өчен, август аенда яңабаштан имтиханнар тапшырып, 21 яшемдә мин КДПИның I курсына барып кердем. Кызганыч ки, Шәйхи ага шул елны, ягъни 1980 елның 10 июнендә вафат булды, минем көндезге бүлек студенты булуымны күрә алмады...

Аның хәер-фатихасы белән, чирек гасыр укыту чорында мәктәп укучыларына туган телебез бизәкләрен, шигырь серләрен бирүгә ирештем. Шәйхи аганың алтынга тиң киңәшләре белән аларны да таныштырдым. Аксакал язучының васыять кебек сүзләрен намус белән үтәдем. Шуңа күрә рухы шат булуына да ышанычым зур.

Бер тармакта гына көч куеп эшләгәндә, эш җиңелрәк бара, минемчә. Шул өлкәне генә тирәнтен өйрәнеп, зур уңышларга да ирешергә мөмкин. Киңлек колачлырак булган саен, вакыт та, көч-куәт тә күбрәк сарыф ителә.

Шәйхи Маннур – әдәбиятта барлык жанрларда да диярлек үзенең каләмен сынап караган язучы, дүрт дистәдән артык китап авторы. Шигърияттә – шигырьләре, сонетлары, мәхәббәт лирикасы, мәсәлләре, эпиграммалары, шигъри повесте, баллада һәм поэмалары... Атаклы «Гайҗан бабай» үзе генә дә ни тора! Прозада – хикәяләре, автобиографик әсәре, лирик повесте, романы... Тәрҗемәдәге уңышлары... Көчле сатирасы... Балаларга багышланган әсәрләре... Публицистик язмалары... Тәнкыйть мәкаләләре... Һәм, ниһаять, үзенең сөйләме кебек, үткен телле каләме!

Шушыларны язганнан соң, Шәйхи аганың «ликбез» дәресләрендәге: «Язучының каләме үткен булырга, төрле жанрда язып, һәрьяклап чарланырга тиеш», – дигән сүзләре искә төште... ■

Безнең мирас №6 июнь 2018

САНДУГАЧ

Габдулла Галиев



Бүгенгедәй хәтеремдә, көзнең ачы җилле шимбә киче иде. Медпунктка килгән соңгы авыруны тикшереп озаттым да өйгә кайтырга җыена башладым. Шул вакыт пункт ишеге ачылып китте. Күрше авылдан Сания апа ашыгып килеп керде.

– Апаем, – диде ул, сүзләрен йота-йота кабаланып. – Абдулла абзыеңның хәле көйсезләнеп китте бит әле. Иртә уңмаган – кич уңмас, дигәндәй, үзебезнең филшер кызыбыз районга киткән икән. Сине чакырырга килгән идем. Рәнҗеми генә безгә барып кайтсана... – Сания апа, җавабымны көтеп, яшьләнгән күзләрен мөлдерәтеп миңа карады. Мин аны тынычландырырга ашыктым:

– Әлбәттә, барам, – дидем. – Авыру ярдәм көтеп ятканда нинди сүз булырга мөмкин?!

Мин, ишектән керү белән чишендем дә, Абдулла абзый янына ашыктым. Хуҗа кеше, аякларын идәндәге мендәргә куеп, койкада утыра. Гәүдәсен бераз аска таба иеп, куллары белән тезләренә таянган. Ябыгып, сөяккә калган иңбашлары җиңелчә калтырый. Көзге тупыл яфрагы кебек саргайган йөзен бөрчек-бөрчек салкын тир баскан. Эчке әгъзаларына кислород җитмәүдән, аның борын очы, иреннәре күгелҗем бөрлегән төсенә кергән. Сулыш алганда тамак төбе, күкрәгенең өске өлеше мәче туен хәтерләтеп, төрле тавышлар чыгарып сызгыра. Эчкә баткан зур зәңгәр күзләреннән үзәкне өзә торган сагышлы моңсулык сирпелә.

Мин, сумкамнан фонендоскоп алып, Абдулла абзый янына килдем. Күкрәген тыңларга теләп, өстендәге күлмәген салырга булыша башладым. Күлмәген баш очына кадәр күтәргәч, хәрәкәтсез калдым. Шул хәлдә күпме торганмындыр, белмим.

– Нәрсә, энекәш, аркама гашыйк булдыңмы әллә? – дигән тавышка сискәнеп киттем. Исемә килеп, күлмәген башыннан тартып чыгардым да Абдулла абзыйның алдына куйдым. Ул соравын яңадан кабатлады:

– Әллә минеке кебек арканы бер дә күргәнең булмадымы?

– Булмады, Абдулла абзый.

Аның сары йөзенә җиңелчә генә кызыллык йөгерде.

– Күргәзмәгә генә куя торган инде ул, энем. Призлы урын алырга, – дигән булды. Үзе хәлсез тавыш белән кеткелдәп көлеп алды. Шаярып сөйләгәндә аның күзләре очкынланып, яктырып киткәндәй булды. Ләкин һавада атылган йолдыз яктысы кебек, бик тиз сүнеп тә куйды. Чыннан да, гади арка гына түгел иде ул. Мин һаман да Абдулла абзыйның аркасыннан күзләремне ала алмадым. Әйтерсең аның өстеннән рәхимсез бәндәләр, җир өстен актаргандай, куәтле бульдозерлар белән имгәтеп-җимереп узганнар. Бөтен аркасы төрле зурлыктагы җәрәхәт җөйләре белән тулган. Икенче караганда,

соргылт-зәңгәрсу төскә кергән бу тубырлы җөйләр җир өсте рельефын күрсәткән география картасын хәтерләтә. Күкрәк читлегенең хәле бик тә аяныч. Ике якта икешәр кабырга юк. Ул алынган кабыргалар өстендәге тире сулыш алганда, җимерелгән иске гармун күреге кебек, бер эчкә батып, бер кабарып тора. Бу күренеш күңелемнең әллә кай җирләрен актарып ташлады. Йа, Хода, бар икән кешеләр! Ничек түзә алды икән адәм баласы бу җәрәхәтләргә? Ә бит күрсәтеп, зарланып йөргәне дә булмады. Мин авырсынып кына сорадым:

– Абдулла абзый, бу кадәр итеп сугышта бизәделәрме?

Ул, миңа карап елмайгандай итте дә:

– Кабыргалар – фронт истәлекләре. Мина кыйпылчыклары иде аркамда. Аркамдагы җөйләр әсирлек ядкәрләре, энекәш.

Мин Абдулла абзыйга укол салдым, дару эчердем. Аның хәле күзгә күренеп рәтләнде, сулышы ачылып китте. Борын очындагы, иреннәрдәге күгелҗем төс әкренләп кызгылт төскә керде.

– Абдулла абзый, – дидем мин кыюсыз гына, – гафу итегез, сезне борчу була инде бу... Миңа үзегез турында сөйләгез әле. Шундый җәрәхәтләр белән сугыштан ничек исән-имин кайта алдыгыз? Гомумән, кем Сез? Кайдан Сез? Бала-чага сезне Сандугач бабай дип йөртә. Ничек Сандугач булып киттегез? Аның тарихын да сөйләсәгез, мин бик шат булыр идем.

Абдулла абзый шактый вакыт зәңгәр күзләрен бер ноктага төбәп, уйга калып торды. Аннан башын югары күтәрде дә кинәт сандугач булып сайрап җибәрде. Бу тавыш мине сихри гүзәллек дөньясына алып китте. Күз алдыма җәйге айлы кич, бөдрә талларга төренеп утырган бакчабыз артындагы инеш буе килде. Янәсе, мин инеш буена чыкканмын да сихри моң дулкынында тибрәлеп сандугач сайравын тыңлыйм. Ә сандугач сайрый да сайрый. Йә ул бервакытка кыска-кыска итеп чутылдый, йә шул арада ничәмә-ничә борылышлар ясап, сызгыруга күчә. Янәдән чүт-чүт итеп, тел белән әйтеп бирә алмаслык гүзәл авазлар чыгара. Аннан тагын чутылдауга күчә. Янәдән берсеннән-берсе матур бормалар ясап, дөньядагы бер генә музыка коралы да әйтеп бирә алмый торган иң нечкә аһәңле, нәфис тавышы белән бөтен тирә-якны моңга күмә. Йа, Хода, булса да булыр икән адәм баласында шундый кодрәт! Булса да булыр икән осталык! Могҗиза бит бу! Чын могҗиза!

Абдулла абзый сайравыннан туктады. Өй эче кинәт тынып калды. Без, башларыбызны иеп, байтак кына сүзсез тордык. Колак төбемдә һаман да сандугач тавышы. Мин, бәлзәм эчкән кеше төсле, шул тылсымлы аһәңнән айнып җитә алмыйча утырам. Ниһаять, тынлыкны бозып, Абдулла абзыйга дәштем;

– Чыннан да сандугач икәнсең бит син, Абдулла абзый. Ихлас!

Тыңлаганым юк иде. Бер аермаң да юк икән бит синең сандугачтан!

Абдулла абзый, куллары белән ияк астын сыпырып куйды да, кәефләнеп көлемсерәде:

– Юк, энекәш, адәм баласы күпме генә тырышса да кошлар алиһәсе – сандугач була алмас. Сандугач – сандугач инде ул...

Мин җир төзелеше техникумы студенты идем. Әйбәт техникум иде ул. Аның шаушулы тормышы мине дә өермәдәй бөтереп, үз эченә алып кереп китте. Бирелеп укый да, күңелле итеп ял да итә белдек без ул елларда. Концертлар, спектакльләр куйдык. Барысына да өлгерергә, барысына да җитешергә тырыштык. Минем кошларга, терлекләргә охшатып кычкыра белү сәләтем дә шунда ачылды. Шулай бервакыт «Галиябану»ны куярга репетицияләр ясап йөрибез. Хәтерлисеңдер пьесаның беренче пәрдәсен? Караңгы төшкәч, Хәлил, Галиябану белән очрашу өчен Бәдри абзыйларның тәрәзәләре төбенә килә. Егет белән кыз бер-берсенә мәхәббәтләрен белдереп җырлыйлар, сөйләшәләр.

Шулвакыт сәхнә артында әтәч кычкыра. Бу эшне Рәхимҗан исемле егеткә тапшырган идек. Репетиция башланды, әтәч булып кычкырырга вакыт җитте. Егетебез кычкыра алмый гына бит. Көзге чебештән җитлегеп килүче яшь әтәч кычкырганын ишеткәнең бармы? Тавышы нәкъ шул әтәчнеке моның. Түзмәдем. Кая әле, мин әйтәм, үзем кычкырып карыйм әле. Тамагымны кырып, төкерегемне йотып куйдым да, күңелем белән әтәчкә әйләнеп, кулларым белән кагынып, кычкырып җибәрдем. Сәхнәләр яңгырап китте. Иптәшләрем гөрләтеп кул чапты. Минем әтәч булып кычкыруым барысына да ошады. Китте шул көннән башланып! Миңа гел шундый рольләр тапшыра башладылар. Ул елларда хәзерге кебек магнитофоннар юк иде. Андый рольләрне ул эшкә сәләтле кешеләр сәхнә артыннан торып башкара иде. Мин шулай итеп «подражатель», үзебезчә әйтсәк, «охшатучы» булып киттем.

Әнә шулай күңелле генә укып, матур яшәп ята идек.

Кояшлы июнь аеның якшәмбе көнендә без – техникум студентлары Агыйдел буена ял итәргә төштек. Бигрәк матур, бигрәк ямьле иде ул көнне Агыйдел буе! Без аннан көн кичкә авышкач кына кайттык. Тулай торак алдында директорыбыз көтеп тора иде. Үзе яланбаш, күлмәгенең сәдәпләрен ычкындырган, пинжәге дә төймәләнмәгән. Ул бер урында гына басып тора алмый, әрле-бирле йөренә. Бик төгәл, галстуктан гына йөри торган бу кешенең килеш-килбәте, борчулы чырае безне сагаерга мәҗбүр итте.

– Балаларым! – диде ул, кайгылы итеп, йөрәккә шом сала торган тавыш белән. – Мин сезне күңелсез хәбәр белән көтәм. Бүген таңда, һөҗүм итәсен дә кисәтеп тормастан, фашистлар Германиясе безгә басып кергән. Немец самолетлары шәһәрләребезне, чик буе авылларын бомбага тота. Илебезнең көнбатыш чикләрендә каты сугышлар бара. Бүген хәрби хезмәткә яраклы барлык совет кешеләренә мобилизация игълан ителде. Миндә кайберәүләрегезгә повестка да бар, – диде дә, сөйләвеннән туктап, костюмының куен кесәсеннән кәгазь алып, военкоматка бүген үк барырга тиешле студентларның исем-фамилияләрен атады. Алар арасында минем дә фамилиям бар иде.

Безне икенче көнне үк озаттылар.

Мине полк разведкасына алдылар, күзәтүче сыйфатында файдалана башладылар. Разведкага баргач куркыныч янаса, йә бер җиргә җыелырга кирәк булса, алдан сөйләшкән буенча, берәр төрле кош булып кычкырыр идем. Разведканың уңышлы чыгуына охшату сәләтем күп тапкырлар ярдәм итте. Әмма көннәрнең берендә без засадага

эләктек. Без, дигәнем – Уфа егете Саша Алешин һәм мин. Шул көнне полк командиры блиндажына чакырып алдылар. Полк командиры, шактый өлкән яшьтәге, озын буйлы, кара мыеклы кеше. Өстәлгә картасын җәеп салды да безне үз янына чакырды.

– Менә бу елга аша салынган күперне күрәсезме? – диде ул, картага карандаш очы белән төртеп.

Без Саша белән картага иелдек. «Күрәбез, иптәш полк командиры», – дидек.

– Менә хәзер бу күпердән безнең гаскәрләр чыгып бара. Запаста бер генә саперым да юк. Шул күперне шартлатуны сезгә тапшырам. Хәзер үк приказны үтәргә керешегез! – диде.

Без, җилкәбезгә шартлаткыч асып, юлга чыктык. Күпер янына җитәрәк куак артына посып, тирә-якны күзәттек. Һәр тарафта тынлык, шикләнерлек нәрсә юк. Шартлаткычны җилкәдән алып көйләдек тә күпер астына төшеп киттек. Безгә шартлаткычны күмәргә кирәк иде. Мин, шартлаткычны куярга урын эзләп, күпер астыннан бара башладым. Ләкин берничә адым гына атларга өлгердем. Башыма ниндидер авыр әйбер белән китереп суктылар. Мин чайкалып тордым да ава башладым. Егылганда күпер почмагыннан Сашага таба автомат көпшәсеннән ут бөркелгәне, Сашаның чалкан авып төшкәне күземә чалынды.

Аңыма килгәндә, кайда ятканлыгымны белә алмыйча, шактый озак җәфаландым. Чатнап баш авырта. Көчле җилдә шаулап утырган нарат урманы төсле, колакларым шаулый иде. Кулларым белән як-ягымны капшый торгач, ниндидер цемент идәнле подвалда ятканымны абайладым. Көнме бу, төнме – һич кенә дә аңлый алмадым. Торып утырырга теләп, башымны күтәрдем. Тик үземне дулкын уйнаткан көймәдә кебек хис иттем. Кинәт башым әйләнеп, күңелем болганып китте, ыңгырашып, яңадан урыныма аудым. Ята торгач, әкренләп аңым ачыла башлады. Мин ничек монда килеп эләктем соң? Томан аша гына күз алдыма күпер асты... ут ыргыган автомат тавышы... Сашаның чалкан авып төшүе килде. Кинәт йөрәгем «жу» итеп китте. Хәтеремә, баш миемнең һәр күзәнәген көйдереп, коточкыч сүз калкып чыкты. Әсир? Димәк, мин әсир?! Аркам буйлап кайнар ток үтте. Бөтен буыннарым хәлсезләнде. Ярылырдай булып, яңадан башым авырта башлады. Чигәләремдәге кан тамырларым бертуктаусыз шул коточкыч сүзне кабатлый: әсир, әсир, әсир! Качарга! Әйе, әйе, тизрәк качарга! Мин, стена кырыена шуып барып, салкын таш стенага тотына-тотына әкрен генә торып бастым. Капшап бара-бара подвалның ишеген эзли башладым. Тик шулвакыт подвалга якынлашучының аяк тавышын ишетеп, туктап калдым. Дагалы итекнең ташка бәрелеп чыңлавыннан солдат итеге икәнлеген абайладым. Менә ул, ишек янына тукталды да, шалтыр-шолтыр китереп ишек йозагын ача башлады. Ул арада авыр шыңгырдап тимер ишек ачылып китте. Подвал эченә яктылык сибелде. Аның артыннан, яктылыкка кара күләгә салып, җилкәсе аша автомат аскан немец солдаты килеп керде. Кинәт иңгән яктылыктан күзләремне ача алмыйча, кулларым белән яктылыкны каплап, чүгәләргә мәҗбүр булдым. Немец солдаты яныма килде дә дагалы күн итеге белән аркама тибеп кычкырды:

– Вставай, Иван! Марш! – Кулы белән ишеккә таба күрсәтте. Без тар гына ярым караңгы коридор буйлап киттек.

Мине бик каты кыйнап, берничә тапкыр сорау алдылар...

Салкын подвалда берничә көн яттым. Биредә көн икәнлеген дә, төн икәнлеген дә белгән юк. Шунысы гаҗәп: кабат сорау алырга чакыручы юк. Немецлар, нишләптер, минем белән кызыксынмый башладылар.

Нәрсә булды? Миңа хәзер шул сорау тыңгылык бирми иде. Немецлар фронтны өзеп тагын да алгарак үрмәләделәр микәнни? Безнең дивизия, солдат иптәшләрем кайда икән? Исәннәр микән? Үземнең хәлем исемә төшә дә эчем өзелеп китә. Әсирлек

халәтемә өзелеп-өзелеп йөрәгем әрни. Бер генә нәрсә хәлемне җиңеләйтә кебек: фашист, күпме генә үҗәтләнсә дә, рухымны сындыра алмады. Барыбер бирешмәдем, хәрби антыма тугрылыклы булып калдым.

Берникадәр вакыттан соң мине подвалдан алып чыктылар. Башка әсирләргә кушып, каядыр алып киттеләр. Бер кечкенә станциядә безне товар вагоннарына төяделәр. Поездыбыз көнбатышка таба кузгалып китте.

Бара торгач, безне Белоруссиянең Слуцк шәһәре янындагы хәрби лагерьга китерделәр. Икенче көнне үк сафка тезеп эшкә йөртә башладылар. Лагерь бик нык саклана иде. Әсирләрне иртән эшкә киткәндә дә, кич кайткач та санап кертәләр. Мин барыбер качарга җай эзлим. Бу уем башымнан бер генә минутка да чыкмый.

Көннәрдән беркөнне бу хыялым тормышка ашты. Без ул көнне автомашиналарга вак таш төйи идек. Кич иде. Инде караңгы төшеп килә. Кинәт көнбатыш яктан күкне томалап кара болыт күтәрелеп чыкты. Тузан өермәләрен актарып, җил-гарасат купты. Без соңгы машинаны төяп ята идек. Шулчак ут сүнде. Без караңгыда калдык. Сакчылар кычкырына башладылар. Берничә урында кесә фонарьлары кабынды. Нәрсәдер булыр, ахры! Сакчылар бер җиргә җыелды. Овчаркалар өрә башлады. Миңа бу уңайлы вакытны ычкындырырга ярамый иде. Күз ачып йомганчы машина кузовына сикереп мендем дә сузылып яттым. Иптәшләрем мине вак таш белән күмеп тә куйдылар. Бәхетемә, машина шунда ук кузгалып та китте. Тыным бик нык бетсә дә, түзәргә тырыштым. Күпмедер вакыттан соң башымны вак таш арасыннан чыгардым. Кузов кырыена шуып килеп, як-ягымны күзәттем. Машина олы юлдан элдертә иде. Димәк, куркыныч зонадан чыкканбыз. Миңа хәзер ничек тә сикерергә кирәк. Вакытны аз гына ычкындырсам да, барысын да харап итүем бар. Машина кузовы артына шуышып килдем дә җиргә сикердем. Сикергәндә аягымны кузов почмагына бәрдем. Сул як аягымның тез башы бик нык авыртып китте. Әмма аңа игътибар итеп торырга вакыт юк иде. Аксый-аксый бар көчемә йөгердем, тизрәк юлдан читкә ычкынырга кирәк.

Ахыры бар ■

ЗӨФӘР РӘМИЕВКӘ – 80 ЯШЬ!

ОЛПАТ ГАЛИМ *

Резеда Ганиева

Рәмиев Зөфәр Зәйни улы (1938), әдәбият галиме, текстолог, филология фәннәре докторы, профессор. Аның күп санлы мәкаләләре Тукай әсәрләренең текстологиясе мәсьәләләрен (төп текст, хронология, атрибуция, комментарий һ.б.) тикшерүгә багышланган. Ул шагыйрь күптомлыкларында басылып килгән ике текстның («Сөй гомерне...», «Экспромт (Мин катам...)») Тукай каләме белән язылмавын, беренчесенең авторы С.Сүнчәләй, икенчесенең Н.Думави булуын раслады. Рәмиев Тукайның ачык һәм яшерен имзаларын (псевдонимнарын) барлап, җыйнап чыкты (алар 65) һәм һәрберсенең кулланылу үзенчәлеген, яшерен имзаларының исә ачылу тарихын нечкәләп тикшерде.

Рәмиев хезмәтләрендә Тукайның замандаш шагыйрьләре, тәнкыйтьчеләр (Х.Искәндәров, Н.Думави, З.Бәшири, М.Укмасый, З.Ярмәки, З.Сәгыйдә һ.б.) белән мөнәсәбәтләренә дә игътибар ителә. Рәмиев Тукай әсәрләренең фәнни басмаларын матбугатка әзерләү мәсьәләләре белән дә шөгыльләнә: шагыйрьнең 2006 елда басылып чыккан ике томлы «Сайланма әсәрләре»нең 2нче томы аның катнашында төзелде, фәнни редакторлыгында басылып чыкты. 2010 елда Рәмиев җитәкчелегендәге (төзүчеләрнең берсе, фәнни редактор) бер төркем әдәбиятчы-текстологлар, Тукай әсәрләренең тулы академик басмасын матбугатка әзерләүгә алынып, аны шагыйрьнең 130 еллык юбилеена багышлап төзеп бетерделәр. Рәмиев, Тукай тормышы, иҗаты, традицияләре мәсьәләләре тикшерүгә куелган күп санлы халыкара фәнни-практик конференцияләрдә (мәс., Казан, Уральск, Истанбулда) катнашып, гыйльми эзләнүләренең нәтиҗәләре белән дә даими таныштырып тора.

Әсәр.: Рәмиев З.З. (1-12); аныкы. «Тукай энциклопедиясе»ндә әдәби топографияне бирүгә карата // ФТ. 2014, №1. Б.62-65
Әдәб.: Әдәбиятчы, текстолог Зөфәр Рәмиев. – К., 2008.84 б.

*Басмага материал «Габдулла Тукай» энциклопедиясеннән алынды.

Абай*

Зөфәр Рәмиев

Абай (Ибраһим Кунанбаев; 1845-1904), казакъ шагыйре (акыны), мәгърифәтче. Галимнәр казакъ әдәбияты тарихын тикшергәндә – Тукай иҗатына, ә татар әдәбияты үткәне турында сүз барганда Абай шигъриятенә дә игътибар итәләр. Тугандаш ике халыкның бу бөек шагыйрьләре, бер үк чорларда иҗат итмәсәләр дә, үз милли әдәбиятларының үсешендә бик охшаш вазыйфаны үтиләр: Абай казакъ язма әдәбиятына һәм әдәби теленә, Тукай исә хәзерге заман татар әдәбиятына һәм татар әдәби теленә нигез салучы булып тора. Аларның бер-берсен белү-белмәүләре хакында сүз йөртү мөмкин дә түгелдер. Абай бакый дөньяга күчү елында (1904) Тукай әле 18 яшьлек шәкерт кенә, әле аның казакъ шагыйре игътибарын җәлеп итәрлек шигырьләре язылмаган. Абай әсәрләре дә укучылар арасында телдән яисә язма хәлендә генә таралган чаклар. Дөрес, бу елларда Тукай Уральскида яши, 1905-1907 елгы инкыйлаб елларында әдәбият мәйданына аяк баса, бер-ике ел эчендә татар дөньясында шагыйрь һәм ялкынлы публицист булып танылып та өлгерә. Шәһәрдә яшәүчеләрнең руслардан кала күпчелеген тәшкил итүче казакълар булганлыктан, аралашу нәтиҗәсендә Тукай бу төрки халыкның акыннары иҗатыннан да хәбәрсез булмаган. «Шигырьләребез» мәкаләсендә (1908) мисал итеп казакъча бер «үләң» – шигырь китерүе (*«Күрдегезме? Бу казакъ шагыйре үзенең мәхбубәсен ничек мактый белгән!»*), шулай ук *«Безнең татарлар шигырь ягыннан казакълардан да артта калган икән»*, дип язуы, Акмулла иҗатыннан *«казакъ исе, күчмә халык исе чыгып торадыр»,* дип әйтүе, Н.Думави һәм М.Гафурилар *«шигырьләрен галибән шул казакъ бәхре белән»* язалар дип санавы Тукайның инде казакъ шигъриятенә хас үзенчәлекләрне таный башлаганлыгы турында сөйли (казакъ әдәбиятчысы, шагыйрь С.Сеитов аның бу елларда ук казакъ поэзиясе белән танышлыгы шөбһәсез дип саный).

1908 елда «Вакыт» газетасының 11 июль (№338) санында «Ибраһим бине Кунанбаев» исемле мәкалә белән янәшәдә аның 3 строфалы шигыре китерелә. Абай шигыре дә («Сылу кыз») кергән казакъ телендәге бер җыентыкның 1909 елда Тукай яшәгән Казанда басылуы да мәгълүм. Билгеле, бу Абай турындагы мәкалә һәм аның шигыре белән татар матбугатын даими рәвештә күзәтеп барган Тукай таныш булгандыр дип ышанасы килә. 1911 елда «Дөньяда бик аз булыр чын шагыйрь Габдулладай; / Ул – караңгы төндә яктырткан матур, ак тулган ай», – дигән Ш.Бабичның 1913 елларда Абайны «татарның Тукае, гарәпнең Имрелкайсы дәрәҗәсенә мендердем», дип язуыннан да бу

*Басмага материал «Габдулла Тукай» энциклопедиясеннән алынды.

чорда Абай шигырьләренең татар әдәби җәмәгатьчелегенә таныш булуы аңлашыла. Казакъ әдәбиятчысы Б.Искаков та Абай иҗатының татар җәмәгатьчелегенә, аеруча шагыйрь-язучыларына мәгълүм булуын яза, аерым алганда, *«татар мәгърифәтче-демократ шагыйрьләре»* (Тукай, Гафури, Бабич һ.б.) мәгърифәтче Абайның шагыйрьлек тәҗрибәсеннән күп нәрсәгә өйрәнгән, Абай башлаган мәгърифәтчел-демократик яссылыкта алга карап үстергән, дигән фикер әйтә. Казакълар үзләре дә Тукайны Уральск чорыннан ук белә башлыйлар. Мәс., Нәзыйфә Колҗанова 1916 елда «Казакъ» газетасында *«Көнчыгыш романтизмыннан килә торган традицияләрне Европа һәм рус реализмы казанышлары белән уңышлы үреп бирүнең классик үрнәге итеп, Абай һәм Тукай иҗатларын саный һәм замандашларын да бу ике зур төрки шагыйрь башлаган критик реализм юлын дәвам итәргә чакыра»* (Р.К.Ганиева). Октябрьдән соңгы елларда да тугандаш ике халык шагыйрьләре һәм галимнәренең бу ике шагыйрьне янәшә куеп күзаллаулары, фикер йөртүләре әледән-әле очрап тора. Мәс., М.Ауэзов, Тукай басмаларын югары бәяләп, аның Абай поэзиясе белән рухи якынлыгын атап күрсәтә. Р.Башкуров Абай белән Тукайның тәрҗемәчелек принципларын чагыштыра, аларда охшаш урыннар булуга игътибар итә. Ике шагыйрь дә Крылов, Пушкин, Лермонтов әсәрләреннән ирекле тәрҗемәләр биргәннәр, икесе дә рус әдәбияты үрнәкләренә назыйрә язу традициясенә нигез салганнар. С.Хәким: *«Абай әйтерсең лә берүзе казакъ халкының бөек рухын формалаштыруны үз өстенә алган. Бу – авыр юл. Борчу һәм һавалану, яну-көю, күңелнең төрле чактагы авыр кичерешләре аша уза бу юл. Тукайның «Бетте көч, сынды кылыч, шул булды эш, / Керләнеп беттем үзем, дөньяны пакьли алмадым» кебек юлларына аваздаш юлларны Абай да әйткән. Абай белән Тукай иҗатына хас күп уртак кичереш һәм бик күп уртак хисләрне табарга мөмкин»* – дип яза, Абай иҗатының халыкчанлыгына соклануын белдерә. Казакъ язучысы Г.Мөсрепов татар шагыйре Тукайны, Абай кебек үк, казакъ язучыларының әдәби остазы итеп саный.

Билгеле, бу ике бөек шагыйрь бер-берсеннән шактый дәрәҗәдә аерылып торган иҗтимагый-тарихи шартларда яшәгәннәр һәм иҗат иткәннәр. Әле яңарак кына Россия империясе составына кертелгән казакъ җирендә иҗат иткән Абай әсәрләрендә, чыннан да, мәгърифәтчелек карашлары шактый зур урын били, мәхәббәт темасына гүзәл әсәрләр күбрәк языла, ә инкыйлаблар, иҗтимагый-тарихи бәрелешләр дәверендә яшәгән Тукай күптөрле вазыйфалар үти, аңа лирик, сатирик шагыйрь һәм публицист та булырга туры килә. Абайның «Гаклия»сендәге кебек, Тукай да иҗатының Җаектагы мәгърифәтчелек чорында *акыл культы ярдәмендә дөньяны үзгәртергә мөмкин,* дип саный.

Әдәб.: Башкуров Р. (6). Б. 119; Ыскаков Б. Казакъ-татар әдеби байланысы. – Алматы. 1976. Б.73-76; Хәким С. Могҗизалар тудыра торган җир // Абай. Шигырьләр һәм поэмалар. Хикмәтле сүз. – К., 1981. Б.5-6; Гыйльманов Г. Кояшлы шигърият // Бабич Ш. Зәңгәр җырлар. К., 1990. Б.9; Исхаков Б. Тукай. Шигырьләр // КУ. 1974. №12. Б.96; Сеитов С. Татар әдәбияты // Абай. Энциклопедия. – Алматы, 1995. Б.538-539; Хамидуллин А. Токай Габдолла // Шунда ук. Б.549; Ганиева Р. (4). Б.62; её же. Традиции Восточного Ренессанса в тюркских литературах Средневековья и Нового времени. – К., 2014. С.206-208; Минвалеев А. Габдулла Тукай глазами немецкого ученого // Восточный экспресс. 2004. 23 апр.; Миннегулов Х.Ю. Абай и Тукай: сравнительно-типологический анализ // Абай-элемдiк феномен, Халықаралық конф. мат-ры. – Астана, 2015. С.15-22.

РЕДАКЦИЯДӘН:

Күренекле әдәбият галиме, журналыбызның даими авторы ***Зөфәр Зәйни улы РӘМИЕВКӘ*** *25 нче июньдә 80 яшь тула. Аны гомер бәйрәме белән ихластан котлап, сәламәтлек, иминлек һәм игелекле олы хезмәтендә уңышлар теләп калабыз!* ■

Безнең мирас №6 июнь 2018

ҖАМАЛ ВӘЛИДИ
(1887-1932)

Җамал Вәлиди җәмәгате Ләйлиҗиһан ханым белән. 1912 ел

Татарстанның КГБ архивларында сакланган документларга караганда, тәнкыйтьче, әдәбият тарихчысы һәм тел галиме Җамал Вәлидине (Җамалетдин Җәләлетдин улы Вәлидовны) ГПУ органнары 1931 елның 6 маенда кулга ала.

Аны нәрсәдә гаеплиләр соң?

Тулаем алганда, ошбу күренекле шәхесебезнең гаебе «солтангалиевчелек» дигән уйдырма «хәрәкәткә» нисбәт ителә. Мондый яланың ни-нәрсә икәнен яхшылап белмәгән, мәгәр «партия әйтсә, хак әйтә» дип инанган, шулай инанырга мәҗбүр булган гомум җәмәгатьчелектә ул чорда тырнак астыннан кер эзләү күренеше гаҗәп дәрәҗәдә киң тарала.

Бу җәһәттән, Җамал Вәлидигә мөнәсәбәтле бер гыйбрәтле документ сакланып калган. Ул, академик Миркасыйм Госманов «Җамал Вәлиди: язмышы һәм урыны, яки оныттырылган олы мирас» мәкаләсендә искәргәнчә, Хәсән Гали[1] исемле галимнең язма-

[1] Хәсән Гали (Хәсән Шәяхмәт улы Галиев, 1878-1940) – тел галиме, әдәби тәнкыйтьче, педагог.

ларыннан гыйбарәт. Язылу тарихы бигүк ачык булмаган тексттан (ул донос рәвешендә язылганмы, әллә берәр җыелышта ясалган чыгышмы, яки үзен саклар өчен алдан ук эшләп куелган «алиби»мы – болары әлегәчә ачык түгел) шул елларда хөкем сөргән гомум вазгыять, галим-голәмә һәм әдипләрне нәрсәләрдә, ничегрәк гаепләү алымнары хакында ярыйсы гына мәгълүмат алырга мөмкин[2].

Хәзер исә галимнең кызы Әминә ханым Рафаэль Мостафинга сөйләгән истәлекләргә күз салыйк: «Әтине Черек күлдәге әчке төрмәнең ялгыз камерасына урнаштырганнар. Башта аның эшен (фамилиясен белмим), яхшы, димәсәм дә, адәм рәтле кеше алып барган. Сорау алганда кыйнамаган, кимсетмәгән. Туганнары белән күрешергә рөхсәт иткән. Хәтерлим әле: без әти янына төрмәгә әнием һәм ике абыем белән килә идек. Әти төсе качкан авыру кыяфәтендә – төрмә беркемне дә бизәми шул. Әмма безнең алда яхшы кәефле күренергә, шаярырга, күңелебезне күтәрергә тырыша иде. Аңа китергән әйберләребезне дә тапшырып бардылар, көчебездән килгәнчә ризыклар да китерә идек...

Әнием белән беркөнне әти янына килсәк – ул юк. Әнигә тоткыннарның берсе Бикчәнтәев фамилияле яңа тикшерүче килүе турында хәбәр итеп өлгергән. Үлгәндә дә бу кешене каргап үләрмен... Куллары корысын! Ул әтине аякка басмаслык хәлгә җиткәнче кыйнаган.

Берәр ай узгач, безгә тагын күрешергә рөхсәт иттеләр. Ә әти кыйнаулардан утырып та тора алмас хәлдә, баскан килеш кенә сөйләшә. Тикшерүчесе турында: «Ничек аны җир йотмый?! Кабахәт!» – дип әйткәнен хәтерлим. Ул кадәр кыйнаулардан соң әти бөтенләй йоклый алмас булды. Ябыкты, күзгә күренеп картайды. Яңаклары эчкә батты, кырылмаган сакаллары агарды... Ул миңа бик карт кеше булып тоела иде. Югыйсә, аңа ул чакта бары тик 45 яшь кенә булган бит!

Бу тикшерүче әтине тагын нишләткәндер, анысын белмим, әмма кыйнау һәм мәсхәрәләү дәвам иткән. Беркөнне әти, түзә алмыйча, өченче кат тәрәзәсеннән ташланган. Газапларга чик кую өчен, үзен үтермәкче булган. Каты килеп төшсә дә, исән калган, ләкин аяк-куллары сынган. Шуннан соң аны Вахитов урамындагы төрмә хастаханәсенә (бераз соңрак анда Галимҗан Ибраһимов вафат булачак) күчергәннәр. Шуңа күрә күрешүләр беркадәр вакытка өзелеп торды. Ә берничә айдан соң безгә яңадан очрашырга рөхсәт иттеләр. Әти яныбызга таякларга таянып чыкты. Сынган аяк-куллары нык сызлау сәбәпле, көч-хәл атлый. Аны хәтта урамга да сакчысыз чыгардылар – бу хәлендә кая кача алсын инде ул?

Менә, ниһаять, аны ике сакчы... атлатып (!) алып чыкты. Әтием хәлсез, бөтенләй бара алмый. Өстәвенә – бозлавык. Ике атлый да бозлы тротуарга ава. Аны торгызалар, ул тагын ике адым атлый да ава. Монда инде әни, түзә алмыйча: «Нишлисез сез, кансызлар?!» – дип кычкырып, әтигә таба ташланды. Ләкин бер сакчы, винтовкасын әнигә төбәп: «Тукта, атам!» – диде. Минем котым очты. Әти нидер әйтте дә, әни туктап калды. Аннары сакчылар янәшәдән узып бара торган җигүле атны туктаттылар, әтине шунда салып алып киттеләр. Без хастаханәгә кадәр артларыннан ияреп бардык.

Аның гомере бик аз калган иде инде. Гангрена башланган. Әгәр вакытында операция ясасалар, исән дә калыр иде. Әмма «халык дошманы» белән кем мәшәкатьләнсен? 1932 елның 29 ноябрендә әнигә әти белән соңгы тапкыр очрашу рөхсәт иттеләр. Ул вакытта әти инде аңында булмаган, алар сөйләшә алмаганнар. Ә икенче көнне әтием аңына килмәгән хәлдә үлеп киткән. Бәлки, аңына килгәндер дә. Янәшәсендә беркем булмаган бит...»

Революциягә кадәрге чор тәрбиясен алган зыялы, туры сүзле Җамал Вәлиди сорау

---

[2] Хәсән Галинең Җамал Вәлиди турындагы ошбу язмасы журналның киләсе битләрендә тәкъдим ителә. – **Р.М.**

алу барышында үз карашларын яшереп торуны кирәк тапмый: ул бу илдә урыс булмаган халыкларның, аерым алганда татарларның, милли киләчәкләренә куркыныч янавын әйтә. Большевиклар аз санлы халыкларның милли-территориаль автономияләрен сүздә генә таныйлар, хәтта аерылып чыгуга кадәр үзбилгеләнү хокуклары турында лаф оралар. Ә чынлыкта исә Украина Радасын тар-мар итәләр, бәйсезлеккә омтылган Төркестанны буйсындыралар. Башка милли республика һәм өлкәләрдә дә шул ук хәл күзәтелә, ди.

Тикшерүче боларның барысын да түкми-чәчми язып бара, «каләмемне большевикларга каршы юнәлттем», дип, үзеннән дә өстәп куя. Әмма сорау алу беркетмәсен укып чыккан Вәлиди моның арттырып җибәрү икәнлеген әйтә: «Уйлап карагыз инде: большевистик карашларга каршы мин кайда һәм ничек чыгыш ясый алыйм? Большевик газеталары шуны бастырамы?» (Бу сүзләрне ул беркетмәгә үзе өстәп куя.)

Нәтиҗәдә, тикшерүче тагы да мәкерлерәк юл сайлый: Җамал Вәлидигә үз сәяси карашларын язма рәвештә аңлату мөмкинлеге бирә...

«Эш»кә теркәлгән аңлатма язуында галим үзенең беркайчан да Совет властена каршы булмавын белдерә. Хәтта яңа хакимиятнең халык файдасына башкарган эшләрен хуплый да. Әмма җитәкчелекнең барлык чараларын да якламавын, аерым алганда, бернинди нигезсез кулга алулар һәм гаммави репрессияләргә каршы булуын ассызыклый, «чөнки алар Совет хакимиятенең халык һәм Көнбатыш илләр «буржуаз демократиясе» алдында абруен төшерә», ди.

Большевикларның тагын кайсы адымнарын кабул итмәве турындагы сорауга җавап итеп, ул милли интеллигенциягә артык кырыс мөнәсәбәтне, матбугатта яла ягуны, язганнарны бастыра алмауны атый.

Авыллардагы күмәкләштерүгә мөнәсәбәте турында язганда, эре күмәк хуҗалыкның вак хуҗалыктан икътисади яктан отышлырак булуы белән килешүен белдерә. Әмма күмәкләштерүне мондый тиз арада һәм мәҗбүри төстә үткәрү кирәкмәс иде, чөнки бар җирдә дә күмәкләштерү өчен уңай шартлар әлегә юк, алга киткән игенчелек һәм интенсив терлекчелек районнарында гына (ягъни якынча 30% хуҗалыкта) шундый уңай шартлар күзәтелә, дип исәпли.

Алга китеп, Вәлиди гаммави «раскулачивание»гә каршы булуын яза. Ни өчен хезмәт сөючән, тырыш крестьяннарны гаиләләре белән Себергә сөрергә соң? Аларны үз урыннарында калдырып, колхозларда эшләргә тәкъдим итү яхшырак булмас идеме?

Ул елларда «дингә каршы алып барылган көрәш»нең колачына һәм формаларына каршы булуын да искәртә. Галим карашынча, тиешле мөнәсәбәт булганда, муллаларны һәм динне «социализм төзү эшендә» файдаланып булыр иде.

Тикшерүче, язылганнарны укып, «Советка каршы»лыгы ярылып яткан урыннарның астына сызып бара – бу аның эшен шактый җиңеләйтә. Ул Вәлидидән «солтангалиевчеләр белән элемтәсе» турында яхшырак, җентекләбрәк язуны таләп итә. Әмма Җамал Вәлиди бернинди дә бәйләнеш булмавы, Мирсәет Солтангалиевнең үзе белән дә, аның тарафдарлары белән дә беркайчан очрашмавы, язышмавы һәм алар турында, гомумән, матбугат аша гына белүе турында хәбәр итә: «Әгәр дә алар турында матбугатта дөрес язсалар, бу – утопия», – ди. Хәзерге шартларда аерым мөселман яки Азия социалистик илен төзеп булмавын белдерә.

Тикшерүче аны төрки халыкларны берләштерү турындагы идеяләрен ачып салырга этәрү омтылышы да ясый. Җамал Вәлиди әлеге карашларны уртаклашмавын әйтә: «Төрки халыкларны берләштерү хәзерге шартларда мөмкин хәл микән? Алар тел ягыннан да, башка өлкәләрдә дә бер-берсеннән шактый ераклашкан. Мәдәниятләре, территорияләре, икътисадлары, сәяси мәнфәгатьләре дә төрле. Әлбәттә, кайберләрен, мәсәлән, татар һәм башкортларны яки казакъ һәм кыргызларны берләштереп карар-

Җамал Вәлидинең тоткынлыкта төшкән фоторәсеме. 1931-1932 нче еллар

га мөмкин. Әлеге халыклар бер-берсенә якын. Ә башкалар исә бик нык ераклашкан, якын киләчәктә аларны берләштерү мөмкин хәл булмаячак».

«Сиксән икеләр хаты»на[3] имза салуын ул яңа әлифба кертелүнең милли мәдәният өчен чып-чын фаҗига булачагы, элекке традицияләрнең тулысынча өзелеп калачагы белән аңлата. Бөтен халык кисәк кенә наданга әвереләчәк, ди. Әмма тикшерүчене башка сорау борчый: аннан кул куйдырырга дип әлеге хатны кем алып килгән? Кем «башлап йөргән», кем «котырткан»?..

Шушы урында язмалар өзелә, мөгаен, «җитдирәк» дәлилләр эшкә җигелгәндер. Сорау алу бары тик 1 айдан соң гына яңадан башлана. Бу очракта инде тикшерүче үзе язып бара, Вәлиди кул гына куя. Аның почеркы үзгәрә: хәрефләрен тигезсез итеп, өйрәнчек балалар кебек яза...

Тикшерүче, күпме тырышуына, кыйнау һәм газаплауларына карамастан, «ТАССРда солтангалиевчелек үзәге филиалы»н формалаштыра алмый. Аңа нindидер бер «оештыручы үзәк» турындагы төгәл булмаган тәгъбир белән чикләнергә туры килә. Алай да, «үзәк» эшендә катнашкан өчен (монысы да расланмаган), тикшерүгә дучар ителгән затларны 5 елга сөргенгә хөкем итәләр һәм Беломор-Балтыйк каналы төзелешенә җибәрәләр. Әлеге «гомумхалык төзелеше»ннән кайберәүләр бөтенләй кайта алмый, кайтканнары да авырулардан арынмый – гарипләнеп беткән була.

1931-1932 елларда иҗат әһелләренең иң күренекле вәкилләрен – язучыларны, галимнәрне, нәшрият хезмәткәрләрен – «бернинди сәбәпсез» 5 елга хөкем итүне Совет мәхкәмәсенең ул чактагы «кешелекле мөнәсәбәте» белән аңлатырга мөмкин. Соңрак шул ук «гаеп» тагылучыларга кимендә 10 ел бирә башлаганнар. Хәер, Вәлиди өчен моның бернинди әһәмияте калмый. 1932 елның 30 ноябрендә ул Пләтән төрмәсе хастаханәсендә үлеп китә. Җирләнгән урыны билгесез.

Галимнең кызы Әминә ханым сүзләренә караганда, әтисе үлеп 3 атна узгач, 1932 елның декабрь ахырында, аларга Мәскәүдән бер кәгазь килеп төшә. Ул хәбәрдә Җамал Вәлидинең ватан алдындагы барлык «гаебе» кичерелү турында язылган була[4].

Әдәбият:

1. Рафаэль Мостафин. Һәрберсен исемләп искә алыйк. – Казан: Татарстан китап нәшрияты, 2014. – Б.200-203.
2. Җамал Вәлиди: әдәби һәм тарихи-документаль җыентык / төз. Диләрә Абдуллина, Җәүдәт Миңнуллин. – Казан: Җыен, 2010. – 624 бит.

Рүзәл Мөхәммәтша *әзерләде.*

---

[3] Татар интеллигенциясе вәкилләренең (табиблар, журналистлар, инженерлар, педагоглар, язучылар, рәссамнар – җәмгысе 82 кеше) 1927 елда И.В.Сталинга һәм ВКП(б)ның Татарстан өлкә комитетына юлланган хаты. Текст авторлары татар теленең латин графикасына (яңалифкә) күчерелүенә каршы чыга. – **Р.М.**

[4] Объектив булыр өчен, бу «фактның» академик Миркасыйм Госманов тарафыннан шиккә алынуын искәртик. Аның фикеренчә, Җамал Вәлидинең 22 декабрьдә «шартлы рәвештә вакытыннан алда азат ителү»е – фәкать «имеш-мимеш», тиешле оешмаларның «эз яшереп» матташу галәмәте генә. – **Р.М.**

Безнең мирас №6 июнь 2018



Җамал Вәлиди. 1920-1930 нчы еллар

Җ.Вәлиди турында[1]

Хәсән Гали

Җамал Вәлидинең сәясәттән читтә, совет партия юлыннан тыш, хәтта совет теләгенә каршы мисаллар яздыруы аның ачыктан-ачык контрлык линиясендә йөргәнлеген күрсәтә.

Вәлидинең 31 нче ел март аенда гына яздырган дәресләре кулыма төште.

1931 нче елга кадәр мәктәп-укыту дөньясында совет власе күп эшләр эшләде: мәктәпләргә комплекс система керде. Политехнизация урнаша башлады. Вәлиди педагогия техникумында укыта. Тәрбиячеләр хәзерли. Вәлидинең дәресләренә карасагыз, совет турында, партия турында, социализм турында бер сүз дә юк. Барлык дәресләрен карап чыкканда Вәлидинең контрреволюцион йөзен түбәндәгеләрдән ачык күрергә була:

1. Вәлиди мәктәптә укытканда партия-совет сәясәтеннән читтә йөри, якын бармый. Бу – партиягә, совет властена кирелектән, аны танымаганлыктан. Грамматика дәресләрендә мисалга алган җөмләләре – «кәҗә усал була», «ат йөри», «кара ат шәп йөри». Бу мисалларда нинди сәясәт бар да, нинди совет директивалары бар?

Болар кайда: a[2]) социализм төзелеше, b) бишьеллык план, c) заем, g) социаль ярыш, d) ударчылык, e) колхозлашу, ә) илне саклау, f) Кызыл Армия, g) революция бәйрәмнәре. Янә башка бик күп моментлар берсе дә юк, чөнки Вәлиди аларның барына да дошман, аларны кирәк дип танымый. «Кәҗә усал хайван», – ди. Нигә: «Кулак усал кеше», – дими? Нигә: «Буржуй кабахәт», – дими? Андый җөмләләр дә мисал булырга ярый ла ләбаса. Яшь буынга мондый мисалларның тәэсире ифрат көчле булачак бит. Вәлиди әнә шуңардан курка да, сыйнфый дошманга каршы андый яман караш

[1] Текст чыганактагыча («Шәхесләребез» сериясеннән «Җамал Вәлиди» китабы) бирелә. Авторлар искәрткәнчә, Хәсән Гали фондында саклануычы бу язмага латин хәрефләре белән татарча «Хәсән Гали Җ.Вәлиди турында. 1932 елда язылган» дигән язма теркәлгән.– **Р.М.**
[2] Чыганакта хәрефләр шушы рәвештә һәм шушы тәртиптә язылган. – **Р.М.**

тудырырга теләми. Ул яшьләрнең дикъкатен ул якка борырга теләми. Менә мондый хәлләрне барын да контрлык дип санарга туры килә.

2. Җамал Вәлиди хәзерге хөкүмәт башындагы җитәкчеләрне куркыныч бер халык итеп күрсәтергә тырыша. Ул укучыларга мондый мисал яздырган: «Иртәгә бу фәкыйрьне шүрәлеләр тиргиләр». «Бу фәкыйрь» дигәне – үзе. «Шүрәлеләр» дигәне – беләсең, хөкүмәт башлыклары була инде. «Тиргиләр» дигәне – җавапка тарталар дигән сүзе. Моны укучылар ни дип аңларга мөмкин? Һәрбер сүзнең астында нәрсә ятканны укучылар бик яхшы сизәләр. Вәлиди аны бик яхшы исәпкә алып яздыра. (Чөнки белә ул – иртәгә аны арестовать итәчәкләр. Гәрчә «карак башында ут яна»).

3. Җамал мисалга сүзне сайлый белә: «Сак утырыйк, сак булыйк, саклыйлар бит көн дә кич», – ди. Хәзерге көндә кемнәр саклыйлар? Беләсең, хөкүмәт кешеләре саклыйлар – күзәтәләр. Ул укучыларны куркыта, сакланырга куша, имтихан бирә, конспирация белән эш итәргә өйрәтә. Советка ачык йөз күрсәтмәскә өнди. Укучылар бу хәвефле заман икән, бу заманда сакланып эш итәргә кирәк икән, дип төшенсеннәр, ди Вәлиди.

4. «Ашыйк, эчик, уйныйк, көлик бу газиз бәйрәмнәрдә» дигән шигырьдән татар рамазан, корбан бәйрәмнәрен ирадә кыла. Җамал Вәлиди әнә шул газиз бәйрәмнәрдә генә уйнап-көлеп, ашап-эчәргә тәкъдим итә. Революция бәйрәмнәре кайгы белән үтсә дә ярый була. Үктәбер бәйрәме, май бәйрәме турында мисаллар күп, тезмә, дисәң, чәчмә, дисәң, тулып ята. Аларның барлыгын, кайдан табарга икәнлеген Җамал[ның] күрми торганы юк, күрә-белә. Ләкин аларны алырга теләми. Чөнки Үктәберләр Җамалның барлык милли вак буржуачылык әмәлләрен мәңге кайтмаслык итеп җир астына күмгән. Шулай булгач, ул нигә Үктәберне бәйрәмгә санасын.

5. «Бәйрәм җиткән, шуңа күрә акча кирәк, әмма касса коры». Бу мисалны Җамал 1931 нче ел 30 мартта яздырып укыткан. Ул вакытта ураза бәйрәме яңа үткән иде. Бәйрәм алдыннан кайберәүләрнең акча эзләп йөргән булулары, аны укучылар белгән булулары бик мөмкин. Җамал шуңа реагировать итә: «Акча эзләмәгез, советның кассасы корыды», – ди. Шул моментны тотып алып, аңардан пилюль ясап, укучыларга йоттыра.

6. «Уфтанмыйк без, дуслар, мал беткәнгә. Маллар кыйммәт түгел, баш кыйммәт». 1931 нче елны кемнең малы бетте, билгеле, советның малы беткән юк. 31 нче елны советның малы артты гына. Әмма буржуйның, часникның малы бетте. Часник, корымаса да, кимеде. Менә шул хәлне күреп, Вәлиди белә: «Уфтанмыйк, дуслар», – дип, мал иясе дусларының күңелләрен күтәрә. «Башыгыз сау булсын, тагы мал табарсыз», – дип, аларны юата. Совет-партия җәмәгате җан талашып социализм төзү өчен көрәшеп ятканда, часникның малы беткәнгә җаны әрнеп, Җамал Вәлиди совет мәктәбенең трибунасына менеп, укучыларны янына җыеп, часникның малы беткәнгә елап утыра.

7. Янә бер урында: «Аталары тапкан малны балалары бетереп баралар», – дигән мисал тора. 1931 нче елда ата малын бетереп йөргән баланы Җамал кайда күрде икән? Моны укучылар болай төшенәләр, Вәлидинең сәяси традициясенә караганда, бу җөмләне болай аңларга туры килә: «Капиталистлар тапкан малны – байлыкларны большевиклар гомумиләштереп җәмәгатьнеке итәләр», – дип төшенмәскә, башкача төшенергә мөмкин түгел.

8. «Без сугышка өйрәнгән инде. Сугыш чыга калса, тагын китәрбез». Монда нинди сугыш турында сүз барганлыкны Җамал әйтми. Пролетариатны яклап, сыйнфый дошманга каршы сугышка өндәве бик шөбһәле. Монда укучыларны пролетариатка каршы булган сугышка кебек итсә. Чөнки [аның] пролетариат сафында бер дә сугышканы юк. «Без сугышка өйрәнгән инде», – дип, үзенең Үктәбергә каршы сугышып йөргәнен әйтмәкче, алар да шундый сугышны уйлыйдыр, дип төшенергә мантыйк сыйдыра. ■

Безнең мирас №6 июнь 2018

ИСТӘ,
ҺАМАН ДА ИСТӘ!

Язучы Флүс Латыйфиның тууына 75 ел

Язучы-прозаик, Татарстан Республикасының атказанган мәдәният хезмәткәре (1993) Флүс Фатих улы Латыйфи (Латыйпов) 1943 елның 3 июнендә Татарстан Республикасының Мөслим районы Мөслим авылында хезмәткәр гаиләсендә туа.

1990 елда язып тәмамлаган һәм әүвәл «Казан утлары»нда (1991, №№11-12) дөнья күргән, 1993 елда исә аерым китап булып Татарстан китап нәшриятында басылып чыккан «Хыянәт» романы язучыга киң танылу китерә.

2010 елның 16 февралендә Казанда вафат була һәм Мөслим зиратында җирләнә.

Ф.Латыйфиның кайбер әсәрләре: «Кырагай» (1988), «Ак-карага тимәскә» (1992), «Уяну» (1998), «Әманәт» (2001), «Ишелеп төшкән бәхет» (2001), «Бәйсез этләрне атарга» (2002).

«Флүс Латыйфи – урта буын язучылар исемлегеннән өлкән буынга күчеп баручы әдипләребезнең берсе. Аның «Хыянәт» романы Казан ханлыгының мөстәкыйль дәүләт булып яшәгән 15-20 елына арналган. Әсәр мәктәпләрдә өйрәнелә. Укучылар аның белән таныш инде... Казаныбызның меңьеллыгын каршыларга җыенганда романның әһәмияте тагын да мәртәбәлерәк».

Мөдәррис Әгъләмов. *Мәйдан тота мөслимнәр.*
//Мәгърифәт. – 2002. – 13 апрель

Шагыйрь Рифкать Закировның тууына 80 ел

Лирик шагыйрь Рифкать Хәйдәр улы Закиров 1938 елның 16 июнендә Татарстанның Актаныш районы Усы авылында туа. 2007 елда вафат була һәм Актаныш районының Киров авылы зиратында җирләнә.

1968 елда иллеләп шигыре «Беренче карлыгачлар» җыентыгында, аннан соң зур бер шәлкеме «Юл башы» (1972) исемле күмәк җыентыкта (Флера Гыйззәтуллина, Фәннур Сафин шигырьләре белән бергә) урнаштырыла һәм, ниһаять, 1983 елда Татарстан китап нәшриятында «Шахтер моңы» исеме белән мөстәкыйль китабы дөнья күрә.

«Рифкать Закиров – 1988 елдан Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы. «Кәккүк моңнарын тыңларга» дигән бик матур җыр язды композитор Ренат Еникеев шагыйрь сүзләренә. Моң һәм Көч. Табигать һәм Күңел. Шагыйрь һәм кырыс чынбарлык. Болар

бәрелеше – Рифкать Закиров шигырьләренең канына сеңгән. Алар – гаҗәеп тыгыз фикерле, халыкчан, җырга тартым ритм-агышлы, сагышлы шатлык белән өретелгән шигырьләр...»

***Рәдиф Гаташ.** Авыл улы, шахтер, шагыйрь... // Казан утлары. – 1998. – №6. – 36-38 б.*

Театр сәнгате белгече Габдрахман Кәрамнең тууына 140 ел

Театр сәнгате белгече, тәнкыйтьче һәм тәрҗемәче Габдрахман Кәрам (Габдрахман Хәбибулла улы Рәхмәтуллин) 1878 елның 26 июнендә Казан шәһәрендә туа.

«1926 елда татар театрының 20 еллыгы ил күләмендә зур итеп билгеләп үтелә. Мәдәният тарихыбыздагы бу күренекле вакыйга уңаеннан «Татар театры (1906-1926)» дигән зур җыентык әзерләнеп бастырып чыгарыла. Анда күп авторлар катнаша. Ләкин гомер буе театр турында язып килгән Г.Кәрам бу эштән читтә калдырыла. Яңа власть вәкилләре Г.Кәрамның сәүдәгәр нәселеннән чыгышын, атаклы байлардан Апанаевлар белән тугандашлыгын, озак вакытлар «пантюркизм», «панисламизм» оясы итеп каралган «Шәрык клубы» белән бәйләнешен, «Йолдыз»да язышуын, хезмәттәшлек итүен кичерә алмыйлар. Г.Кәрам озакка сузылган дәшмәүгә мәҗбүр ителә, ул матбугатта катнашудан бөтенләй читләштерелә. Ахыр чиктә Г.Кәрам К.Якуб исемендәге полиграфия комбинатында вахтер булып эшли, шактый кыен шартларда яшәп, 1947 елда йөрәк авыруыннан вафат була...»

***Айгөл Салихова.** Театр тәнкыйтьчесе. //Мирас. – 1996. – №9. – 69-72 б.*

Артист Хәй Мушинскийның тууына 110 ел

Артист, иллюзионист-манипулятор, драма актеры Хәй Мушинский (Габделхәй Хафиз улы Мөхәммәтшин) 1908 елның 27 маенда Уфа губернасы Стәрлетамак (хәзерге Башкортстан Республикасының Стәрлебаш) районының Тәтер-Арыслан авылында туа. 1920 елда авылда чыккан янгында өйләре яна. Әтисе, туганнары үлә. Әнисе белән урманда, землянкада яшәргә мәҗбүр була.

1994 елда Казанда вафат була.

Күренекле язучы Әхәт Мушинский – атаклы артистның улы.

«Балачакны алма белән чагыштырсаң, минем алма кызыл түгел иде, яшел иде, әче иде».

***Хәй Мушинский.** Балачак хатирәләреннән* ■

Безнең мирас №6 июнь 2018

ӘЗ-МӘЗ ҮЗЕМ ТУРЫНДА

Равил Шәрәфи

Жиләкле, өмет белән дә тулы июнь аенда сугыш башлап җибәрүчеләр минем этием кебек гади кешеләр турында уйлап карадымы икән?! Ә менә минем этием тылда калган хатыны, балалары, авылдашлары турында бер дә онытмагандыр кебек. Бу җәһәннәмнән нинди генә юллар белән булса да котылып кайтып, җиңү көннәрендә мактанып һәм макталып яшәрмен, дигән максат та куймаган икән, эти, диясем килә. Минем үземә бүгенге Җиңү көннәрен чамасыз шау-шу белән тутырулары бер дә ошамый. Әгәр дә мәгәр шапырынуларны бер дә яратмаган этием исән кайткан булса, бу шау-шу тудырып мактанучыларга ни әйтер икән, дип уйлап утырдым да, 1943 елда этигә багышланган мәкалә белән чыккан бер фронт газетасын тагын да алып карыйсы иттем. Гвардия капитаны Егоровның «Татар халкының улы Шиһабетдин Шәрәфетдинов» дигән баш астында урнаштырылган әлеге язмасы газетаның «Безнең геройлар» дигән сәхифәсендә басылган икән. «Безнең мирас» журналы укучыларына шуннан берничә кыска-кыска өзекләрне урысчадан тәрҗемә итеп бирәм: «...Совет танкы миналанган кыр буенча зур тизлек белән алга ыргыла, чөнки бу танкның бронясы өстендә утыручы сапер өлкән сержант Шәрәфетдинов танкны йөртүчегә миналарны ничек әйләнеп узарга икәнен күрсәтеп бара. Немец артиллеристлары танкны күпме генә утка тотсалар да, снарядлар, миналар бер-бер артлы танк тирәсенә төшеп диярлек ярылсалар да, танк алга баруын дәвам итә. Әнә ул төгәл ачкан уттан дошманның батареясы тынып калды. Үлем

Дәвамы. Башы журналның 4 нче (2018) санында.

чәчкән пулеметның да бугазы тыгылды. Әмма дошман як та йоклап ятмый бит. Якыннан ук төбәп аткан снарядларның берсе танкка тиеп шартлый сугыш машинасына ут кабына. Ялкын шундук Шәрәфетдиновны да баштанаяк чолгап ала...

...госпитальдән чыккан Шәрәфетдинов кабат сугыш эченә барып керә. Ул куйган миналарның берсе дошман танкының башына җитә.

...Гитлерчыларны чолганышта калдыралар. Шәрәфетдинов, автоматын тоткан хәлдә, ике дә уйлап тормыйча, фашист ерткычларының өннәренә бәреп керә. Ә алар анда күбәү. Шулчаклы дошман алдында япа-ялгыз басып торса да, Шиһабетдин каушап калмый, автоматыннан тегеләр баш очына бер очередь биреп, гайрәтле тавышы белән җикеренеп ташлый, шаккатып калган немец солдатлары, ирексездән, коралларын ташлап кулларын күтәрәләр. Әсир итеп алган бу төркемне, ә анда барлыгы 50 кеше булган була, Шәрәфетдинов үзе белән барырга мәҗбүр итә».

Мәктәп елларында

Менә мәкаләдәге берничә кечкенә өзектән дә этинең «гомеремне дә бирәм халкыма», дигәндәгедәй эш йөртүе күренә. Госпитальдән чыккач, этигә, бәлкем, отпуск та тәкъдим итеп караганнардыр, ә ул, безнең янга кайтып, безнең янда ял итеп, һич булмаса бер күренеп тә китмәде... Бигрәк тә миңа кирәк булыр иде бит бу очрашу... Юк шул, кабат сугыш эченә кереп китәсе иткән эти... Инде безгә эти турында утырып уйлар уйларга гына калган.

Этинең гомерен өзгән сугыш үзе дә бетте. Ниһаять, авылыбызның яшел хәтфә үлән белән капланган урамнарына ачыдан да ачы күз яшьләренә олы шатлыгы да кереп буталган Җиңү көне килде. Хәтеремдә сакланып калган бу истәлекле көн, шулвакыттагы май аеның башка көннәре кебек, бик җылы һәм җилсез иде. Хәзерге май айларында гына бит ул кеше үтерә торган җилләр исә. Ә балачакның майлары башка иде – табигатькә, экологиягә хәзерге сыман зыян салып өлгермәгән иде әле комсыз, акылсыз адәм баласы.

Җиңү бәйрәме безнең өй каршында гына узасы икән – элекке мәчетнең сүтеп алынган урынында. Хәзергесе көндә дә анда, шөкер, мәчет торгызылган, таштан салып куелган мәчет. Әйткәнемчә, 1945 елның Җиңү көнен бәйрәм итүчеләр элеккеге мәчет урынына яңа такталардан төзеп куелган бик зур трибуна каршына җыелдылар. Күңел күтәренке, кайгы- хәсрәт дигән нәрсәләрне белмәгән чакларым. Әни әнә сугышка чаклы бүлеп бирелгән бодайның соңгы бөртекләрен тарттырып кайткан да зур төшләр пешергән. Аларны тотып урамга чыгып чаптым. Шул бәхетле көннән соң инде 1955 елга кадәр без андый ипи заты күрмәдек. Бәрәңгене кыргыч белән уабыз да шуның крахмалыннан табактан авызга кадәр сузылып килә торган ботка пешерәбез. Ә сыгылган түбеннән исә ипи дигән нәрсә салган булабыз. Ипигә тәмсез дип әйтергә ярамый, дисәләр дә, башка сүз таба алмыйм. Тәмсез генә дә түгел, ул бик тә тәмсез була иде. Кыскасы, ун ел шул бәрәңге ипие белән «сыйландык». Авылда бер көтүче Мостафа абыйлар гына оннан пешкән ипи ашадылар.

Безнең мирас №6 июнь 2018

Шушы сугыш беткән елны мин мәктәпкә киттем. Ике классны бер китапсыз укып чыктым. Икенче класста укыганда укытучы Разия апа миңа бер шигырь ятлап килергә кушты. Мин, ятламыйм, дигәч, 7 генә класс бетереп укытучы булган Разыя апабыз, әй, сакау тәре, мин аны сиңа үзем дә бирмим, дип, гаҗәп педагогик вердикт чыгарды. Мин ул чакта «ш» авазын «с»лаштырып әйтә идем. Бик ятлар идең дә, китабын каян алырга?! Гаделлек өчен шуны да өстим, соңрак, китаплы булгач диюем, әдәбият дәресләрендә гел шигырь ятлап кына да «5»леләр алып бардым.

Бала җаны өчен бик күңелле бернәрсәне әйтми калдырганмын икән. Беренче класста укыганда мәктәптә 1946 елны каршылап, Яңа ел чыршы бәйрәме үткәрделәр. Безнең якларда чыршы булмау сәбәпле, аның урынына нарат куясы иткәннәр иде. Ул хуш исле наратка ап-ак мамыклар асып, төрле-төрле кәгазь кисәкләре белән дә бизәп бетергәннәр. Авылга электр кермәү сәбәпле, чыршы-нарат торган залны керосин лампалары белән генә яктыртсалар да хәтер түремдә моңардан да матуррак, моңардан да күңеллерәк чыршы бәйрәме булмады, дигән уй саклана. Әллә, дим, ул бәйрәмне чын бәйрәм иткән нәрсә һәр укучыга йодрык хәтле (анысы, табигый, минем 7 яшьтәге йодрык кына инде) помадка өләшү булмады микән? Без бит өч бала: нәни абый, апам һәм мин бирелгән бүләкне, ялап та карамаган килеш, әнигә алып кайтып тапшырдык. Әни инде аны кеше башына бик әз-әзләп кенә бүлеп биреп, безне бик озак вакытлар бәхетле итте.

Сугыштан соң авылның Борахау башындагы хәзерге көндә мәктәп булган урынындагы бинага әсир немецларны урнаштырдылар. Алар, шунда төннәрен кайтып кунганнан соң, студабеккер дигән зур йөк машинасына утырып, каядыр эшкә китәләр иде. Киткәндә дә, кайтканда да авыз гармуны уйнап, «Ах майн либер, Аугустин» дигән җырны җырларлар иде. Беркөнне, кич тегеләр ашап-эчеп алгач булса кирәк, «мимеч»ләр карарга барасы иттем. Болар ишегалдына чыгып басканнар, кайсы шунда тәмәке тарта, кайсы уйланып кына тора, шунда арадан берсе, минем хәтеремә аеруча кереп калды. 35-40 яшьләрдәге какча, төз гәүдәле, бик пөхтә, сөйкемле генә немец, һич фашист дип тә уйламассың үзен, миңа бик озак сагышлы боек күзләре белән карап торды, аның күзләрендә миңа бернинди дошманлык юк, киресенчә, алар бик миһербанлы, кызгану белән тулы иде. Мөгаен өс-башымдагы киемнәр дә, ябык-нәзек гәүдәм дә бик мескен булып күренгәндер. Аннары аның да бит Германиядә үз балалары калгандыр.

Әле шушы арада гына, Себернең кайсы каласы икәнен онытгым инде, кайбер тити башлар Германиягә барган бер мәктәп баласын Бундестагтагы чыгышында немец солдатларының бер гаебе дә юк, дип сөйләгәне өчен тинтерәткәннәр иде. Андый бушбугазларга ачуың килмәслекмени?!. Алар юлыннан барсаң, кая барып чыгарсың? Безнең солдатларга да гаеп өсте гаеп тагарга була. Ә чынлыкта, әнә шул искедән исерүче башак башларының үзләрен җәмәгать хөкеменә тартырга кирәк.

Тагын бер шушыңа охшаш вакыйганы искә алып үтим әле. Сугыштан соңгы чорлар инде бу. Таракан Вәли бабайлар янында, бүрәнәгә тезелешеп, ир-атлар утыра. Кем икәнен хәтерләмим хәзер, арадан берсе әсирлектәге чагын тәмләп сөйли башлады. И-и, рәхәт тә яшәп калдым соң мин анда, дип, сиптерепме-сиптерә: «Ну, егетләр, безнең фрауның әйбәтлекләре!» – дип тә май өстенә май өсти. Сугыштагы немец офицерының хатынына хезмәтче итеп куйган булсалар кирәк моны. Ул чакта әле фрау дигән сүзне мин үземчә генә аңлыйм. Мәйтәм, Фрау дигәне бу әсир хезмәтчене сыйлап, яхшы гына карап торган әйбәт хатынның исеме икән дип. Ә ул исә ханым дигән мәгънәне аңлаткан сүз икән. Моны мин ни өчен сөйлим, югыйсә НКВДның галәфи чалбар киеп планшет таккан агентлары бик еш кына халыкның котын алырга дип килеп чыга иде. Тыңлаучыларның берсе моның сөйләгәннәре турында ым гына каксын, шундук тегене тотып алып кеше тиз әйләнеп кайта алмый торган яки бөтенләй кайтмас тарафлар-

Безнең мирас №6 июнь 2018

га алып китәрләр иде. Ләкин мондый хәл булмады. Димәк, безнең авылда стукачлар булмаган. Шуңа күрә авылым халкына олы хөрмәт саклыйм.

Мәктәп елларыннан тагын сугыш темасына кереп киткәнмен икән бит. Ә сүземне сугыштан соңгы еллардагы ачлы-туклы, такы-токы гына ашап торуларыбыз турында әйтермен дип башлаган идем. Сугыштан соң ун ел буе оннан пешергән икмәк күрмәдек шул. 1949 елда мине, әле нибары 11 яшь кенә иде, сигез чакрым ераклыктагы чиркәүле урыс авылына җибәрделәр. Ни өчен баштан узган вакыйганы сөйләп киткәндә чиркәүне искә төшереп башладыммы? Чөнки чиркәү өстендәге әллә каян күренеп торган дәһшәтле тәреләрне күргәч, котым ботыма төшеп киткән иде. Шулай итеп, кулыма акча тоттырып, елгалар, үрләр аша урман буеннан ничек адашмый гына бару юлларын өйрәтеп озатсалар да, хәтер капчыгыма салган киңәшләре тәмам онытылды. Нәкъ «Кәҗә белән сарык» әкиятендәге мәхлук җаннар кебек хис итә башладым үземне. 11 яшьлек ябык, нәзек малайны кырлар, урманнар аша, әле ул чакта сугыш барган җирдән качып килгән бүреләрне дә искә алсаң, шактый хәтәр юлга озатканнар икән. Ярый, шөкер, ничек тә барып җиттем. Өйдән өйгә кереп сатлык он турында шактый сорашып йөргәннән соң, минем кулымдагы бар кебек акчага мәрхәмәтле җаннар бер пот он тутырып җибәрделәр. Ничек кайтып җиткәнмендер, белмим, әмма әниемнең минем өчен орден-мадальләрдән дә кадерлерәк булган тагын бер «мулуҗис»ына лаек булдым. Ләкин көн дә оннан пешкән ипи ашый башлаячак көннәребезгә кадәр әле тагы алты ел көтәсе бар иде.

Минем Казан каласын бик тә күрәсем килә иде. Шул турыда әйтсәм, әни мине: «Синең, улым, бер яшьлек чагыңда ук Казанда булганың бар инде», – дип юата иде. Бу сүзләр, нишләптер, чыннан да миңа юаныч булды. Ниһаять, дәү абыем 1949 елны Казанга алып барды. Казанда бераз йөргәч: «Йә, ничек, Казан ошадымы? – дип сорады. Яраткан абыемның кәефен җибәрмәс өчен: «Әйе», – дип ялганладым. Чөнки Казан каласы дигән башкала күңелемдә йөрткән әкияти кала булып чыкмады.

http://prokazan.ru сайтыннан алынган

Дәвамы бар ■

РӘШИТ ВАҺАПОВ ЯДКӘРЛӘРЕ

1908 елның 7 маенда Нижгар губернасының Сергач өязе Актук авылында туган Рәшит Ваһапов 1926 елда Түбән Новгород педагогика техникумын, 1938 елда Мәскәү музыка училищесын тәмамлый. Шуннан соң Казанга килә, 1941-1962 елларда Татар дәүләт филармониясендә эшли, гомеренең төп өлешен татар халык җырларын һәм татар композиторлары әсәрләрен халыкка җиткерүгә багышлый. Ул бу чорда татар эстрада җырчылары арасында иң актив концерт эшчәнлеге алып баручылардан санала, халыкта зур популярлык казана.

Бүген Габдулла Тукай исемендәге Татар дәүләт филармониясе архивында биредә эшләгән һәр артистка багышланган тупланмалар, папкалар саклана. Аларда – газета мәкаләләре, фоторәсемнәр, рәсми документлар, мәшһүрләрнең кульъязмалары...

Шул исәптән, Татарстан Республикасының халык артисты Рәшит Ваһаповка кагылышлылары да бар.

Архивта 1941 елның 27 маенда чыккан боерык та саклана. Аның 2 нче параграфында мондый сүзләр теркәлгән: *«Тов. ВАГАПОВА Рашида Вагаповича зачислить в ансамбль песни и пляски ТАССР в качестве хориста и солиста со дня получения аванса с 19/V-41 г. с окладом 600 руб. в м-ц, по смете декады. ОСНОВАНИЕ: заявление т. Вагапова с резол».*

Күренекле нәфис сүз остасы, Татарстанның атказанган артисты Әзәл Яһүдин Рәшит Ваһапов турында болай дип язып калдырган: *«1952 елда Рәшит, үзенең бригадасын төзеп, мине эшкә чакырды. Менә шуннан безнең дуслык еллары башланды һәм ул 1962 елга кадәр – Рәшит дус бу дөньядан киткәнче дәвам итте. Булды төрле хәлләр: ачысы да, татлысы да, авырлыгы да, җиңеллеге дә, кайгысы да, шатлыгы да!*

Ул сәхнәгә чыга. Төз, мәһабәт гәүдәле, мөлаем көләч йөзле, ачык чырайлы. Залны яңгыратып җырлап җибәрер иде, халыкны үзенең җыры белән тәмам әсир итәр иде. Бер мәртәбә, әле миңа кадәр, Рәшитнең сәхнәгә 14 мәртәбә кабат чакырылып чыгарылганын ишеткән идем.

Татарстанның халык артисты дәрәҗәсенә ирешәчәк Рәшит Ваһаповның Түбән Новгород педагогика техникумында укыган чагы. 1922 ел

Бер төркем татар сәнгатькәрләренең Урта Азия буйлап гастрольләре вакыты. Сулдан уңга: Сәгыйт Алиев, Камил Басыйров, Әзәл Яһүдин, Зифа Басыйрова, Рәшит Ваһапов. Карши шәһәре (Үзбәкстан). 1960 ел

Бигрәк тә «Әлфия», «Урман», «Нурия» һәм башка күп җырларны тыңлаганда халык тәэсирләнүенә чыдый алмый, нишләргә белми, үкереп кул чаба иде».

Әзәл Яһүдиннең Рәшит Ваһаповка салган котлау открыткасы да ике күренекле зат арасындагы җылы мөгамәләне раслый: *«Якын дустым – мишәрем Рәшит!*

Сине чын йөрәктән Бөек Октябрь Социалистик революциясенең 45-еллыгы белән котлыйм. Исән-сау терелеп, тынычлыкта киләчәк бәйрәмнәрне дә каршыларга насыйп булсын.

Үзең көлеп сөйләгән «тешсез калып, шәлперәйгән карт булганчы» яшәвеңне телим.

Сине истә тотучы, терелүеңне теләүче, мишәрлеген саткан, бригада буенча якын, һәм көлешеп, һәм талашып яшәгән дустың Әзәл. 4/XI-62 ел».

Бусы – Рәшит Ваһаповның улларына язган хаты: *«Рөстәм, Зөфәр! Сезне тәбрик итәм уку елының башлануы белән. Сезнең гел «5»ле билгесенә генә укуыгызны телим. Мин сезне бик каты сагынам. Рөстәм! Бу хатны алгач та хат яз. Кайчан дачадан кайттыгыз? Зөфәр кайсы мәктәптә укый? Һәрберсен яз. Сезне сагынып – папагыз».*

Рәшит Ваһаповның хатыны Зәйтүнәгә җибәргән телеграммасы: *«Поздравляю с сорокалетием со дня рождения. Желаю здоровья и бодрости, сил в усердном воспитании детей. Крепко целую. Твой Рашид».*

Габдулла Тукай исемендәге Татар дәүләт филармониясе архивында җырчыга мактаулы исемнәр бирелү турындагы документлар да саклана. Шуларның берсен сезгә дә тәкъдим итәбез:

«Тов. Вагапов Рашид Вагапович!

Президиум Верховного Совета Татарской Автономной Советской Социалистической Республики в связи с декадой татарского искусства и литературы в гор. Москве и учитывая заслуги в развитии татарского советского искусства и литературы присвоил Вам звание «Народного артиста Татарской АССР».

Рәшит Ваһапов һәм аның җәмәгате Зәйтүнә Ваһапова-Фәткулова. Ленинград шәһәре. 1952 ел

Председатель Президиума Верховного Совета Татарской АССР С.Низамов.

Секретарь Президиума Верховного Совета Татарской АССР Г.Галеев.

Казань. Кремль. 8 июня 1957 года».

Җырчы Динә Сиражетдинованың «Ватаным Татарстан» газетасында (10 октябрь 1998 ел) урын алган мәкаләсе дә игътибарга лаек:

«Кайчакта аңа (Рәшит Ваһаповка. – **З.Г.***): «Син тавышыңны сөйләшүләргә күп сарыф итәсең, кичен нихәтле җырлыйсың бар бит әле», – ди идек. Моңа каршы ул: «Минем тавыш көнгә дә, төнгә дә, кичкә дә җитә, – дип көлә генә. – Тирәмдә шулкадәр кызыклы кешеләр булганда сөйләшми тора алмыйм», – ди торган иде.*

...Соңгы концертларыбыз Актаныш районында булды. Ул чакта Рәшит инде авыру, алай да сер бирмәскә тырыша иде. Шуннан Казанга кайткач, ялга киттек. Аннан соң Украина белән Башкортстанга барырга тиеш идек. Ял беткәч, аның хастаханәдә ятуын белдек (ә декабрь аенда инде ул арабыздан китеп тә барды)[1].

Безне, Украина белән Башкортстанга ул терелеп чыккач барырлар, дип, вакытлыча республикабыз районнарына җибәрделәр. Шунда бер концерт вакытында безгә аның вафаты турында телеграмма китереп бирделәр. Ул концертны ничек куеп бетергәнбездер, хәтерләмим, концерттан соң тамашачыларга телеграмманы сәхнәдән укыдык. Зал аягүрә торып, елый-елый тыңлады...»

Бер төркем зыялылар Татарстан Президенты М.Ш.Шәймиевкә адреслаган һәм 1997 елның 5 декабрендә «Мәдәни җомга» газетасында басылган ачык хаттагы юлларга күз ташлыйк:

[1] Рәшит Ваһапов 1962 елның 14 декабрендә вафат була. – **Ред.**


Рәсәм зудәр! Сезне тәбрик итәм
уку елының башлануы белән.
Сезнең 4ле 5ле билгеләренә генә
укуыгызны телим.
Мин бик каты сезне сагынам.
Әнисе бу хатны алгач тиз
хат яз. Кайчан дачадан кайттыгыз
зудәр кайсы мәктәптә укый?
Һәр берең яз сезне сагынып
калабыз.

Жырчының улларына язган хаты...

Горький филармониясе залы сәхнәсендә. 1957 ел.
Сәйяр Сабиров фотосы

«Хөрмәтле Минтимер Шәрипович!

Р.Ваһапов халкыбыз өчен иң авыр елларда, милли сәясәттә сталинизм хөкем сөргән елларда иҗат итте. Авылдан авылга, шәһәрдән шәһәргә йөреп, татар моңының, татар сәнгатенең илчесе булды. Шулай итеп, татарның татарлыгын саклауда ул искиткеч зур роль уйнады.

Беркемне дә кимсетмичә, ышанып әйтергә мөмкин: халкыбызның гаҗәеп олы мәхәббәтен казанган Р.Ваһапов – үз заманында татарның иң яраткан җырчысы, легендар шәхесе иде.

...Безнең уебызча, җырчының исемен мәңгеләштерү җәһәтеннән түбәндәге чараларны күрү зарур:

1. Казан урамнарының берсенә Р.Ваһапов исемен бирү;

2. Аның иҗаты һәм тормышы турында китап чыгару, фильм төшерү, радио-телевидение тапшырулары әзерләү;

3. Җырчының язмалары тупланган компакт-диск чыгару;

4. Казанда Р.Ваһаповның музей-квартирасын булдыру;

5. Татар җырлары фестивале үткәрү;

6. Музыка сәнгате әһелләре өчен Р.Ваһапов исемендәге Дәүләт бүләген булдыру.

Рәшит Ваһапов, Динә Сираҗетдинова. 1960 нчы еллар башы

Имзалар:

Татарстанның халык язучысы Гомәр Бәширов, Татарстанның һәм Россиянең халык артисты Илһам Шакиров, Татарстанның халык, Россиянең атказанган артисты Хәйдәр Бигичев, драматург, Татарстанның халык депутаты Туфан Миңнуллин, композитор, Татарстанның һәм Россиянең халык артисты Фасил Әхмәтов, профессор, философия фәннәре докторы Казбек Гыйззәтов, музыка белгече Зәйнәп Хәйруллина, «Мәгърифәт» гәзитенең баш мөхәррире Рифат Фәттахов».

Ошбу хатның эчтәлеген йомгаклап, шуны әйтик: бүгенге көндә Казанда Рәшит Ваһапов исемендәге урам, җырчыга багышланган мемориаль билге, аның язмышын, иҗатын чагылдырган саллы китаплар, телевидение тапшырулары, Рәшит Ваһапов исемендәге фонд һәм җыр фестивале бар.

Остазларыбызның башка хыял-тәкъдимнәре дә берәр кайчан чынга ашырылыр дип ышаныйк.

***Зимфира Гыйльметдинова** әзерләде.* ■

Безнең мирас №6 июнь 2018

МИЛЛИЯТ СҮЗЛЕГЕ

Адлер Тимергалин



ЯТГАК *бор.төр.* – Каравылчы, каравыл. «Ятгак» сүзенең төп мәгънәсе – «ятучы». Мәс., **Мәхмүд Кашгари**да: «ятгак ятты» дигән гыйбарәгә тап булабыз. «Котадгу белек»тә исә мәгънә тагы да ачыграк: «Төнлә ятты ятгакта, көндез үрә [аягөсте булды]». Моннан электә каравылчыларның посып ятканлыгын аңлыйбыз. Төнге каравылны башкача *кәбтәул, тургаул* һәм *төнкатар* дип йөрткәннәр.

«Башкорт теленең диалектлары сүзлеге»ндә теркәлгән «йатак» сүзенең бер мәгънәсе «җәйләүгә чыга алмыйча авылда калган кеше» дип бирелә. Ләкин, безнеңчә, монда авылны сакларга калган махсус кеше турында сүз бара.

ЯТИМ, ЯТИМӘ г. – Үксез ир яки кыз бала. *//Дөньяга тулган хисапсыз күп ятимнәр ник бүген? Үксеп-үксеп егълашалар ул ятимнәр ник бүген?* Мөнәҗәттән. *//Ятим үз кендеген үзе кисә.* **Ризаэддин Фәхреддин** фикеренчә, бу сүзләр **Әбелгазый**ныкы (Һива ханы, 1603-1663). *Казан ятимнәре* – Казан ханлыгы Явыз Иван тарафыннан буйсындырылгач, православие диненә күчкән татар мор-

Дәвамы. 2014 елның 3 нче саныннан басылып килә.

залары, авыр язмышларыннан зарланып, мескенгә салышып, рус патшаларыннан төрле җиңеллекләр алырга тырышканнар. Мәскәүләр боларны «казанский (казанская) сирота» – *«казан ятиме»* дип атаганнар. (Вл. Даль буенча.) Торабара бу фразеологизм, үзенең беренчел мәгънәсен җуеп, гомумән мескен һәм ярдәмгә мохтаҗ булып кыланучыларга карата әйтелә башлый.

«Татарстанда әти-әнисез 11 меңнән артык сабый теркәлгән. 2007 елда гына да 1500 бала ятим калган. 9726 ятим татарстанлыларның гаиләләрендә тәрбияләнә, 2686сы уллыкка алынган, 5615е туганнары тәрбиясендә, 1425е гаиләдә тәрбияләнә». (**«Идел»** журналы, 2008, 7 сан.)

«Ятим» дигән чи гарәп сүзен «ят»+-«им» сүзләренә таркатып, чит-ят әниие имеп үскән үксез бала дип этимологизацияләү фәнни нигезгә корылмаган, ул халык этимологиясеннән башка нәрсә түгел.

*Ятим*нең күплек саны шәкеле – *әйтам* (ятимнәр).

ЯУЛЫК – Гадәттә хатын-кызлар башка бәйли яки бөркәнә торган кием, төрле формадагы материя кисәге. Охшаш сүз күп кенә төрки телләрдә дә күзәтелә. **Р.Әхмәтьянов** бу сүз гомумтөрки *йаг* – май сүзеннән булса кирәк, дип исәпли. Яулык, димәк, әүвәле ашаганнан соң кул сөртү өчен кулланылган *йаглык* булып чыга (сөлге, тастымал, кулъяулык). *Ашъяулык* (эскәтер) сүзе бу фаразны раслый да шикелле. Шуннан соң *башъяулык* (баш яулыгы), *борын яулыгы, бит яулыгы* сүзләре барлыкка килгәнгә ошый.

Электә татар хатыннары бүрек астыннан да баш яулыгы бәйләгәннәр.

Баш яулыкларының төрләре һәм атамалары байтак: *акча яулык* – ак яулык; *дарай яулык* – парчалы ефәк яулык; *куш яулык* – зур яулык, аны иргә чыккан хатыннар бәйләп йөргән; *кыекча яулык* – өчпочмаклы яулык; *кычыткан яулык* –

кытай кычытканыннан сугылган яулык; сакалтайлы җаулык – «шау тәңкәле яулык»; *тамбурлы йаулык* – себер татарларында зур чәчәкләр төшкән яулык; *тешле яулык* – төрек яулыгы; *түгәрәк яулык* – кара ефәк җеп белән чигелгән, маңгай турысына тәңкәләр тезгән озынча яулык (аны яшь киленнәр бөркәнгән); *түгәрәк яулык*; *кәбинәт яулык* – бөркәнчек, фата; *француз яулык* – эре ак бизәкле кызыл яулык, асылда чуар азиат яулыгы; *хатыннар җаулыгысы* – Чистай керәшеннәрендә тар озынча сөлге кебек ак яулык, тастар; аның баш-башлары чигүле һәм чуклы булган; *чибәр яулык*, *фелүр яулык* – бизәкле ефәк яулык (флеровый/фуляровый платок); *шартланка яулык* – диалектта *шотландка яулык*, шакмаклы яулык; *шәльяулык*, *тасмал*, *өрпәк*, *мәндил (г.)* һ.б.

Яулык (җаулык) чөю – яулыкны артка бәйләү. *Бийатай, бийанай җанында җаулык чөйү җуг инде.* Минзәлә ягы сөйләшеннән. *Яулык тарту* – электә Пермь якларында ирләр каршында хатын-кызның йөз яшерүе. ■

Безнең мирас №6 июнь 2018

Татарстан Республикасының Милли китапханәсе

РУСЧА ИСКЕ БАСМА КИТАПЛАР ТУПЛАНМАСЫ (1830 ЕЛГА КАДӘР)

Сирәк китаплар арасында русча иске басма китаплар аерым урын били. Бу тупланмадагы китаплар саны 1481 данәгә җитә. Русча иске басма китаплар тупланмасына И.А.Второв һәм И.А.Сахаров китап тупланмаларындагы китаплар да керә. XIX гасырда ук инде алар сакланып калган сирәк нөсхәләр исемлегенә кергән. Хәзерге көндә исә, китап-һәйкәл саналып, федераль әһәмияткә ия булып торалар.

*Дәвамы. Башы журналның 2017 елгы 10 нчы санында.

Иң бәһалесе – «Номенклатор» («Лексикон») – латин, алман һәм рус телләрендә 1700 елда Амстердамда Петр I күрсәтмәсе буенча бастырып бирелә. Түбәндәге ике китап Россиядә чыга: «Циркуль һәм линейка ысуллары яки җир үлчәү эшен яңача, җиңел башкарырга мөмкинлек бирердәй, математика сәнгатенең сайланма башлангычы һәм моңардан чыгасы бүтән сәнгатьләр» (М.,1709), Петр дәверендәге дипломат П.П.Шафировның «Бөек Петр патша җәнапларының швед короле Карл XIIгә каршы сугыш башлар өчен нинди законлы сәбәпләре булганлыгы хакында фикер йөртү» (СПб, 1722). Бу икенче китап та Петр кушуы буенча язылган, «укучыга йомгаклау сүзе» дә – аныкы. Ул – 1556-1714 еллардагы рус-швед мөнәсәбәтләрен яктырткан, халыкара-сәяси теманы күтәргән беренче рус язмасы, Петр эпохасы публицистикасының үрнәге.

Иске басма китапларның күбесе рус һәм чит ил әдәбиятына карый: «М.Н.Загоскинның «Галимнәр кичәсе» (1820), «Богатонов яки Башкалага чит төбәктән килүче» (1823), «Богатонов авылда яки Үз-үзенә көтелмәгән хикмәт» (1826) комедияләре; Д.И.Фонвизинның «Бригадир» исемле комедиясе (1817), А.С.Пушкинның «Граф Нулин»ы (1827), И.Ф.Богдановичның ирекле шигырь белән язган бәяны – «Җанкисәк» (1824), Гораций Флаккның «Одалар»ы (1823). Тәрҗемә әсәрләрдән мондый исемле-сен мисалга китерергә була: «Пансалвин – караңгылык кенәзе. Булган хәлме? Булмаганмы? Ә шулай да әкият түгел» (1809). Әлеге әсәр – алман актеры Альбрехт китабыннан тәрҗемә. Монда Екатерина II хакимлек иткән чор усал көлеп сурәтләнә. Пансалвин исеме артында кенәз А.Г.Потёмкин-Таврический күз алдында тотыла. Баш

каһарманның интим мөнәсәбәтләре, мәхәббәт бәйләнешләре, сарай мәкеренә корылган болганышлары автор тарафыннан әхлакый-сатирик роман калыбында мавыктыргыч итеп тасвирлана. Потемкин һәм Екатерина IIдән кала, романда граф Н.И.Панин, П.А.Румянцев-Задунайский, Г.Г.Орлов һ.б. сурәтләнә. 6 «дистә»-бүлектән торган китапның тексты зәңгәр кәгазьгә басылган.

Иске басма китапларның шактые тарихка һәм географиягә карый. Мисал өчен, «Кытай империясенең һәм Кытай Татариясенең географик, тарихи, хронологик, сәяси һәм физик яктан тасвирламасы. И.Б.Дюгальд әсәре, француз теленнән И. де Теильс тәрҗемә кылган» (1775-1777) дип аталган күләмле әсәр ике бүлектән тора; форзацлары төсле эшләнгән, карта һәм сызымнар өстәлгән. Беренче бүлекнең беренче битенә император Канси сурәте төшерелгән.

И.Ф.Крузенштернның «1803, 4, 5 нче һәм 1806 нчы елларда «Надежда» һәм «Нева» корабларында дөнья тирәли сәяхәт» (1809-1812) өч томлыгы үзенчәлекле. Бу хезмәттә, И.Ф.Крузенштерннан тыш, шул сәяхәттә катнашучыларның язмалары, табигать белеменә һәм этнографиягә караган күзәтүләре, төрле халыклар белән аралашудан җыелган сүзлек тә бирелә.

Санкт-Петербургта 1818 елда басылган китап «Төньяк Америка буйлап кызыклы сәяхәт тәҗрибәсе» дип атала. Аны язучы, журналист һәм рәссам П.П.Свиньин язган. Яшьлегендә Филадельфиядә рус консуллыгы хезмәткәре, сәркатип буларак аңа төрле илләрне күрергә туры килә. Үзенең тәэсирләрен язып, П.П.Свиньин берничә китап чыгара. Ә бусы – кереш сүз һәм алты бүлектән гыйбарәт. Һәр бүлек авторның аерым биткә граверлап эшләгән үз рәсемнәре белән бизәлгән.

Тагын бер аеруча кыйммәтле китап... Аның титул битендә хуҗасының кара төсле кара белән язып калдырган сүзләре ансат укыла: «Дворяннар башлыгы Иван Николаевич Владимировныкы». Бу китапның исеме «Рус-татар сүзлеге, Тоболдагы төп училищеда татар теле укытучысы рухани Иосиф Гиганов җыйган һәм Йорт татарлары муллалары тарафыннан расланган». Китапның күләме 680 бит, 1804 елда Санкт-Петербургта басылган.

Иске басма китаплар тупланмасындагы басмаларның яртысыннан күбрәге Санкт-Петербургта Фәннәр академиясе, Глазунов, Смирдин, Шнор һәм тагын Театр типографияләреннән дөньяга чыккан. Мәскәү басмалары да хәтсез, күп китапларда Мәскәү университеты, Селивановский, Ридигер һәм Клаудия, Семен, Решетников, Сенат, Новиков типографияләренең тамгасы тора. Уннан артык исемдәге китаплар Казан типографияләреннән юл алган. ■

Безнең мирас №6 июнь 2018

Гаилә-нәсел мохитендә символлар һәм тамгалар теле

Фәнис Нәбиуллин

Гаилә-нәсел тарихларында кан-кардәшләрнең туу һәм үлү көннәре тап килүе кебек гайре табигый күренешләр (мәсәлән, бабасы вафат булганнан соң икенче елда нәкъ шул көнне оныгы дөньяга аваз сала), әледән-әле исемнәр кабатлануы, нәселдән-нәселгә күчә килүчән чирләр, фаҗигале хәлләр белән күпләрнең очрашканы, бәлки әле моңа игътибар иткәне дә булгандыр.

Бу очракта күпләргә серле булып калган «бәхет» һәм «бәхетсезлек» төшенчәләренең чикләре чагыштырмача үтә күренмәле икәнлеген искәртү кирәк. «Аңлы» һәм «аңсыз» мәгънәләренең дә кеше акылы иңләмәстәй төсмерләре бар. Аң белән кабул итеп бетерә алмаслык, ягъни аңнан өстен көч дөнья киңлегендә бердәнбер Башлангычка буйсына һәм тормыш-яшәү рәвешен туу-үлем чикләрендә раслый. Бу Башлангычны – гайре табигый көчне без Аллаһ, Илаһ, Ходай, Ходай Тәгалә, Тәңре, Яралтучы яки Бөек (фән телендә – Абсолют) дип атыйбызмы – монысы мөһим түгел, адәм баласы иртәме-соңмы аның асыл мәгънәсе иҗаттудыру барышының үзгәртелә алмавында икәнлегенә инана («язмыштан узмыш юк», «тәкъдиреңә ни язганны күрәсең»). Бар тереклек ияләренә берөзлексез камилләшү таләбен куйган Эволюция үзе авырту кичерү, тәҗрибә туплау һәм, әлбәттә, ярату – әнигә, әтигә, гаиләгә карата, күңелгә якын туган якка, сөйгән кешеңә, балаларыңа мәхәббәт аша эзлекле юл салып, әйдәп бара. Боларның барысын бер төенгә җыйган иң югары нокта – Аллаһ Тәгаләгә табыну-сыену, олы Мәхәббәт хисе.

Сүзебезнең башына кайтып, «тарих кабатлану» синдромы турында иркенләбрәк сөйләшик әле.

Гаилә-нәсел мохитендә көннәр, айлар, еллар кабатлану феноменын тирәнтенрәк аңлар өчен, аның көй-музыка өлкәсендәге яңгыраш алу (резонанс) күренешенә туры килүе белән тиңләштереп карау кирәк. Әйтик, бер музыка коралының аһәңе икенчесенең эзенә басып, беренче «скрипка»ның яңгырашын баета, аны көчәйтә, матурлыгын арттыра, шулай итеп, әйләнә-тирә дөнья белән аваздашлыгы аркасында, тыңлаучының игътибарын җәлеп итә. Ел тарихының (даталарның) кабатлануында нинди матурлык һәм тулы яңгыраш булсын, дип әйтүегез бар. Әмма ашыгыч нәтиҗәләр ясаудан тыелып торыгыз әле. Билгеле булганча, мәрт(кә китү), март, mortal, рус телендәге смерть, мёртвый – болар барысы да тамырдаш сүз-төшенчәләр. Әйе, әйе, нәкъ менә март – яз килүе, табигать терелүе, тормышның яңа көч белән уянуы билгесе булган ай да – шул тәсбихнең бер төймәсе! Яшәү – үлемнән аерылгысыз, аннан башка бу тәсбих өзелер иде.

Һәр үлемнең асылына төшенү, һәр корбанның тормыш чылбырындагы тирән мәгънәсен аңлау һәм яд итү лазем. Үлемне хөрмәт иткәндә генә яшәүдән курыкмаска мөмкин. Шулчакта гына язлар кабатланачак.

«Тарих кабатлану» төшенчәсе бик киң кулланылыштагы мәгънәләргә ия. Кайбер мисаллар китерим:

– кешегә әҗәл ул туган көнне килә (берничә көнгә генә алданрак яки соңрак булырга мөмкин);

– онык бабасының вафатыннан соң бер ел яки берничә елдан нәкъ ул үлгән көнне дөньяга аваз сала;

– ике-өч буында беренче кыз бала 12 яшендә үлеп китә (бу сан төрлечә булырга мөмкин);

– нәсел тормышындагы күп кенә фаҗигале хәлләрнең билгеле бер сан белән бәйле булуы (мәсәлән, 13 яки 21);

– ниндидер яшьтә (мәсәлән, 31дә) нәселнең һәр буынын авыр вакыйга-сынаулар көтеп тора;

– гаиләдә яки нәселдә төрле еллар дәвамында үлем-китем яки авыр чир-сырхаулар бер үк көнгә яки айга туры килә;

– иң яраткан угыллары әнисенең туган көненә бер көн кала һәлак була.

Мондый мисаллар бихисап.

Тик шунысы гына бар: күренешләрне бербөтен система итеп өйрәнүче, үзен күп еллар дәвамында шул эшчәнлеккә багышлаган белгеч, тикшеренүләр, чагыштырулар нәтиҗәсендә, аларда мәгълүм бер закончалыкны күрсә, әлеге система вәкиле булган аерым зат монда очраклы туры килүдән башканы күрми, аны берничек тә аңлата алмый һәм хәтта аңларга тырышмый да, шуңа күрә еш кына бу хәл-вакыйгага аша «атлап» кына уза, аңа бөтенләй илтифат итмәве дә бик ихтимал. Шул ук вакытта биредә бик мөһим мәгълүмат яшеренеп ятарга мөмкин.

Нәсел бизәк-чигелешләре үзләренә генә хас булган тамгалары, символлары, билгеләре белән төгәл бер системага салынган төзелеш-структурага ия (бу, гыйльми тел белән әйткәндә, генограмма яки геносоциограммаларда, ягъни агач кәүсәсе эчендәге боҗралар сыман, ел арты ел йомыла барган тәкъдирдә дә, нәсел яшәешен теркәп калдырган, гади күзгә чалынмый да торган язмаларда аеруча ачык күренә). Нәсел чылбырында игезәкләр, Даун билгеләре (синдромы) белән, шулай ук тома сукыр яки саңгырау балалар туу һ.б. күренешләргә бәйле, аларның сәбәбен аңлатуны сорауга җавапларны психогенетика (тамыр-яшәеш психологиясен өйрәнү) фәнендә табарга мөмкин. Бу чишелеш-җаваплар системаны өйрәнү белән шөгыльләнгән белгечләр кулында түгел, ә шул тарихны дәвам итүче затларның үзләрендә үк яшеренеп ята, белгечләр ул «яшерен» язмаларны укып-шәрехләп кенә бирәләр. Һәр очрак үзенчә кабатланмаслык, монда бер аршын белән генә үлчәү, ашык-пошык нәтиҗә ясау мөмкин түгел. Нәсел бизәкләре тәрәзә пыяласына суык төшергән рәсемнәрне хәтерләтә. Аларның тәртибе үзгәреп торучан. Һава температурасына, дымлылыкка, җил исү юнәлешенә бәйле рәвештә, пыяладагы чигеш башка төс ала бит. Нәсел сабаклары яңабаштан күздән кичерелә, зиһен иләгеннән иләнеп, система эчендәге мөнәсәбәтләр алышынуы аңлашыла икән, шуңа карап, нәсел бизәге дә үзгәрә, Галәм яңа буында алгарыш-үсеш-үзгәреш таләпләрен куя.

Күз алдына ачыграк булып килсен өчен, үзем өйрәнгән хәл-әхвәлләрдән кайбер үрнәкләр белән уртаклашыйм әле. Аларда аерым язмышларны бер җепкә теркәгән система эчендә кабатланып баручы, күңелне кузгата, нәселнең тере дәвамчыларын әле дә булса шомландыра торган, әмма аң ирешмәслек дәрәҗәдә тетрәндергеч фаҗигале вакыйгалар теркәлеп калган.

Урта яшьләрдәге ир-ат үз нәсел-нәсәбенә кагылышлы, хикмәтен таба алмаганга, үзен еллар дәвамында борчып торган бер мисалны китерә. Әтисенең абыйсын 1939 елның 22 июнендә нахакка атып үтерәләр, ә ике елдан, 22 июнь таңында миллионлаган шәһитләрнең җанын кыячак сугыш мәхшәре башлана. Инде чагыштырмача тыныч дип саналган 80 нче елларда, 22 июнь көнне әлеге ир-егетнең (ул чакта үзе дә әле бәләкәй малай гына була) яраткан абыйсын урам сугышында үтерәләр, гәүдәсен өйгә дуслары алып кайта...

Үзенә 11 яшь чагында әнисе үлгән өч балалы хатын һәр баласына 11 яшь тулган елда күңел төшенкелегенә бирелә, «ычкынып» та алгалый.

Каты авыруга дучар булган икенче бер хатынның сүзләренә караганда, әтисен 31 июль көнне, күпфатирлы йортларының ишегалдындагы эскәмиядә утырганда, артка таба чигенүче йөк машинасы таптап үтерә. Бер ел узгач, 31 июльдә аның улы туа. Бүген инде 30 яшькә җиткән малае чирле әнисен үлемнән саклау өчен бөтен көчен куя икән.

Яшьлегендә көче-дәрте ташып торган, бик һавалы булган хатын, эчкечелеккә сабышкан иренең төшенкелеккә бирелеп, дөньядан туеп яшәве белән көрәшүдән тәмам арып-алҗып, күңеле белән аңардан читләшергә тырыша. Ир исә, моңа үпкәләп, үз эченә тагын да ныграк йомыла һәм асылынып үлә. 25 елдан соң бу хатынның бик яраткан, терекөмеш кебек хәрәкәтчән оныгы, кинәт кенә үпкәсе ялкынсынып, хастаханәдә үлеп китә. Бу хәл кайчандыр бабасының асылынган вакытына бер көн кала була.

Яшь хатын баласын төшергән һәм бер ел узгач ире белән аерылышкан вакытларның нәкъ менә үзенең туган көне (22 июль) белән туры килүенә сәерсенә. Бу өч тапкыр кабатлануның серен ача башлагач, нәсел бизәгенең «теле» болай чишелә: 22 июльдә, хатын-кыз табигатенә капма-каршы көндә туып, ул үзендәге хатын-кыз башлангычының шактый өлешен «үтергән», шуның аркасында, үз карынындагы дөньяга киләсе җанның да шәмен сүндергән, иренең аңа тартылу көче дә киму әлеге хәл-халәт белән бәйле. Моңа карап кына, әлбәттә, бу хатынның ирен бөтенләй гаепсез дип санап булмый.

Истә калганнардан ел билгесе булган тарихлар белән бәйле тагын өч-дүрт дистә мисал китерә алыр идем, тик хикмәт – саннар (айлар, көннәр) кабатлануында түгел, ә аларның мәгънәви егәрлегендә. Алар, мәктәп мөгаллиме мөстәкыйль башкарып чыгу өчен өйгә эш биргән кебек, һичшиксез, сабак булып киләләр, киләчәкне, күрәчәкне кисәтү рәвешен алып, хәтер төпкелендә калалар. Әйтергә кирәк, монда, адәм баласының шәхси вөҗданы булган кебек, нәсел агымнарын текә ярлар арасында тотучы ыругнәсел вөҗданы да мөһим роль уйный. Кайда гына яшәмәсен – Актанышта, Америкада, Аляскада яки Австралиядәме – шул сабак, «кара сакал» булып, аңа ияреп бара, чөнки башы-ахыры чиксез, күзгә күренмәс нәсел «төш»е үзенең эшен дәвам итүен белә. Сәбәп һәм нәтиҗә канунын беркем дә үзгәртә алмый. Без, ошыймы алар, юкмы, әби-баба, атааналарыбызның асылы, дәвамчы үсентесе, чынбарлык «телим»-«теләмим» диюдән күп мәртәбәләр өстен тора. Нәселгә берекән булу язмышын яки хокукын һичкем сайлап ала яки үзгәртә алмый.

Менә бу гаилә – төрки халык вәкилләре, әмма төрле милләт кешеләре арасындагы дәртле мәхәббәт җимеше булып яралган. Ике балалары бар. Ата-ана ду килеп әрләшә, аннары ярсый-ярсый килешә. Шундый бер «фикер алышу»ларның иң югары ноктасында ир дигәнебез чыгырдан чыга: «Бу орышш-талашлардан арыдым, юл билеты алам да Бакуга очам!» – ди. Очу аланына барып җиткәнче фаҗигагә юлыгып, һәлак була. Берничә елдан әлеге сүзләрне аның улы үзенең хәләл җефетенә кабатлый һәм шул ук көнне, әтисен гүргә алып киткән чатта, аны әҗәле көтеп торган икән. Тагын ничәдер ел үткәч, сеңлесе иренә шундый дәгъва белдерә һәм, сүз сөрешеннән аңлыйсыздыр, ул утырган машина авариягә очрый (тик башка урында), һәм, аның сүзләренә караганда,

үзе исән калса да, автомобиль тимер өеменә әйләнә. Кыскасы, уеннан – уймак, ягъни сабак гел каршыга чыгып, бармак янап тора.

Мондый «йогышлы»лык фәндә трансгенерация дип атала (транс – күчерү, ә генерация – кайчандыр бирәү тарафыннан кем беләндер үзара яки эчке бәрелешкә-конфликтка керү нәтиҗәсендә туган энергия, бу очракта – «кара көч»).

Трансгенерация күчешләренең әһәмиятен күңеле белән тойган Фрейд «Тотем һәм табу» дигән хезмәтендә болай дип язып калдырган: «Әгәр бер буындагы психик процесслар икенчесенә тапшырылмаса, һәркайсына яңабаштан тормыш-яшәешкә өйрәнергә туры килер, бу исә һәртөрле прогресс һәм үсешне туктатыр иде. {...} Бер буын, үзенең психик халәтен киләсе буынга тапшыру өчен, нинди чаралар куллана? {...} Басым никадәр генә көчле булмасын, тенденция беркайчан да үзеннән соң нindидер субститут калдырмас дәрәҗәдә юкка чыкмый, ә бу субститут, үз чиратында, кайбер реакцияләрнең башланып китү ноктасы булып чыга».

Күчемлелек мәсьәләсен Платон « Эрр Памфлиен мифы» дигән хезмәтендә үк куйган. Ул җаннарның хәтере җуелуын һәм үзләре яралганчы күргән бар нәрсәне хәтердән җуюларын тасвирлап язган. Без исә, алдарак булган белем-мәгълүматны оныту бүгенге хәяттә, үткәннәрнең күләгәсеннән беркадәр котылып, шәхси киләчәгеңне төзеп яшәү мөмкинлеге бирә, дип әйтә алыр идек. Зирәк акыллы Табигать ярдәмендә теге яки бу нәсел дәвамчысы шәхси язмышы аша үзенең элгәреләренә (авырту-әрнүләренә) тоташу-ялгануны бөтен тирәнлеге белән тоя ала кебек (бер варис та моны үзе теләгәнчә сайлап ала яки үзгәртә алмый).

Трансакт анализ, ягъни күчешне тикшерү күзлегеннән чыгып фикер йөрткән психик процессларны һәм мотивацияләрне өйрәнүче галим (психоаналитик) Фанита Инглиш, «кайнар бәрәңге»дән котылыр өчен, аны ябык система эчендә буыннан-буынга тапшыралар, ди.

Октаваның тулылыгы җиде нотадан тора, бербөтен көч туплау өчен дә, җиде буынның сабак алуы кирәк. Әмма бер көй һәрвакытта да бер октава белән генә чикләнми.

Минем эш тәҗрибәсендә атасы үлгән көнне үк улы туган очраклар да бар. Монда шулай ук мәгънәви тамга салынган. Һәм ул беркатлы гына түгел. Бу – нәселнең яңа җанга урын бушатуы, шул бушлыкны тутыруы кебегрәк. Монда шулай ук бертөрле генә җавабы булмаган гаҗәеп күренеш белән очрашабыз. Кайчакта ул – вафат булган атасын алыштыручы бала, ә кайчакта яңартучы-торгызучы, алмашка килүче җан буларак туган бала белән бергә яшәешнең кабат кайтуы, көч туплавы һәм куаныч китерүе билгесе. Теләсә кайсы очракта да биредә сабак бар һәм әлеге мәсьәләләрне без үзебез чишәргә тиешбез.

Алмаш булган күп кенә балалар үзләреннән алданрак дөньяга килгән сабыйның туган яки (әгәр ул чакта әниләре җеназа укытмаган, югалту белән килешеп, күңелен тынычландырган булмаса) үлгән яки күмгән көнендә туалар. Күңел төшенкелегенә бирелгән, боек яки үлем ачысыннан кайгырып йөрүче ананың алмашка киләсе сабые туганда шизофрения (психик авыру) белән чирләп китүе дә еш очрый. Бу күренеш «Үле ана» дип атала торган синдром белән билгеләнә.

Ел тулу синдромы (авыру халәте) туу яки үлү белән генә түгел, бала төшерү, үле бала табу, туйлар, аерылышулар, хыянәт итү, армиягә алыну, сугышка китү, никах укыту һ.б. вакыйгалар белән бәйле булырга мөмкин. Әби карчыкның әрнүле шәхси тарихын үзе үләр алдыннан, алмашка килүчесен сайлаган кебек, бер иң яраткан оныгына гына сөйләгәненә дә мисаллар күп.

Кайбер кешеләр һәр елны бер үк вакытта, ни өчен икәнлеген үзләре дә аңламыйча, курку һәм күңел төшенкелегенә бирелә торган була. Алар бу көннәрнең якын кешеләре

– туганнары яки сөйгәннәре вафат булган чорга туры килүен хәтерләмиләр, шуңа күрә әлеге кабатлана торган халәтнең моңа бәйлелеген аңламыйлар.

Тагын шуны искәртү кирәк: һәр милләт, дини төркем, һәр гаилә диярлек, килешәме-килешмиме, үзенең ышану-риваятьләре белән яши. Әгәр кемдер нәсел таләпләре-йөкләмәләрен үти алмаса, үзен гаепле итеп сизә башлый. Бу – башкара алмаган бурыч белән үзенә күрә тискәре элемтә урнашу дигән сүз.

Күпләрне уйландырыр әле, дигән ният белән язылган шушы кечкенә мәкаләдә туу һәм үлемгә бәйле һәркегә таныш символик көннәрне дә билгеләп үтәсем килә. Сугышлар узганнан соң 9 майда яки 22 июньдә (плюс-минус 1-2 көн булырга мөмкин) үлем-китем хәлләре белән очрашкан саен, нәсел төркеменең геносоциограммасын тикшергәндә, байтак очракларда яуга китеп хәбәрсез югалган бабай яки әбинең ир туганы кайгысы кайчандыр гаилә тормышына кара күләгә булып ятканын ачыкларга мөмкин. Бу системадагы үлем куәтен яңа дәвамчы күтәреп китә алмаган булып чыга. Кабатланып килә торган дата әнә шуны искә төшерә.

Еш кына күзәтелә торган тагын бер кызыклы хәл игътибарга лаек: уллары әнисенең туган көненә бер көн кала һәлак була (машина бәрдергән яки башка фаҗигале очрак). Монда ел тамгасы (синдромы) ничек аңлатыла ала? Җавап шулай ук гаҗәп, әмма алдан ук әйтеп була торган. Тикшереп караганда, бу – ананың горурлыгы саналган иң яраткан улы булганлыгы ачыклана. Кызларына ул азрак игътибар биргән икән. Хатын үзе яшь чагында йөргән егетен югалтуга китергән вакыйгалар аша узган. Соңыннан кияүгә яратып чыкмаган. Язмышындагы шушы борылышны ул улына мәхәббәт белән төзәтергә омтылган. Үз тәкъдире белән килешмәве ярылып ята. Истә тотарга кирәк: үз тормышыңда ирешә алмаганны балалар өстенә ирексезләп йөкләргә ярамый. Сусанин кешеләрне үзе булмаган җиргә ияртеп бара алмый.

Соңгы вакытта туган тел мәсьәләсендә бик күп сораулар күтәрелә. Телнең җәлеп итү көченә ясалма рәвештә ирешеп булмый. Аның мәгънәсен үзең өчен тирәнтен аңлау-төшенү әһәмиятлерәк. Туган телдә безнең фикерләү рәвешенең, гомум рухи уртаклык сыйфатының (ментальлекнең) табигатьтән килүче шартлы билгесе (коды) яши һәм ул тормыш агымын юнәлтүдә мөһим рольләрнең берсен уйный. Бу уңайдан күпләргә үземнең теләк һәм тәкъдимнәремне җиткерәсем килә.

Туган телегезне онытмагыз, кулланыгыз һәм үстерешегез. Ул – сезне нәселегез белән бәйләп торучы буын, үткәннең тәҗрибәсен тапшыручы мөһим юлларның берсе. Нәселнең бай тормыш сабаклары безнең өчен йөрәк тибеше кебек кирәк. Алар иң кыен чакта күз ачып йомганчы дөрес карарга, чишелешкә ирешү мөмкинлеге бирә. Бу ярдәмнең иң зур өлеше үткәннәрдән килә. Нәсел өчен безнең шундый җиңүләребез кирәк, чөнки аның тормышы бездә дәвам итә.

Хисләрегезне берәүдән дә тыярга тырышмагыз, хәтта кичерешләр авыр-авыртулы булган очракта да. Авырту – Ходайдан килгән чара, аңардан качып котыла алмыйсың. Авыртуны кабул иткәндә генә аңа яшерелгән хәбәрне ачыкларга мөмкин.

Сүземнең ахырына якынлашканда, үз тәҗрибәмнән чыгып, сабак булырдай гыйбрәтле бер тарихны сөйләп китәсем килә. Ул – бер буын эчендәге күчеш яки трансгенерация мисалы. Күп еллар элек мин бер әби (90ны узган) янына барган идем. Ул кечкенә генә авылда иске-таушалган йортта берьялгызы яшәп ята иде. Үзе уку-язуны яхшы таныган, шактый зирәк акыллы әбекәй булып чыкты. Ул кызыклы әңгәмәдәш тә иде. Зирәк кешеләр – иң әүвәл заманында күп авырлыклар кичергән, зур тормыш сабагы алган затлар алар. Андыйларның шәхси тәҗрибәсен халкыбызның чын хәзинәсе дип атарга мөмкин. Озын гомер юлында булган, еш кына сынаулар, хәсрәтләр белән тулы вакыйгаларны сөйләү әбинең үзенә дә ошый иде (әмма ул аларны елый-елый яки

бизәкле-чуклы итеп искә төшерми, бары тик тормышындагы гади булмаган «кыйпылчыкларны» чыгарып сала гына).

Ахыр мәртәбә күрешкәндә, Мәрҗән әби (исемен аз гына үзгәртеп язам) соңгы 2-3 атнада көн саен диярлек тәрәз төбендә җиңел ак күлмәкле хатынны күрүен сөйләде. «Ул бернигә дә кагылмый-тими, әмма мине көтеп торган, хәтта чакырган кебек. Кая дәшкәнен-чакырганын аңлыйм инде». Мин, ахирәткә китәсен белгән хәлдә, аның өчен бу иң мөһим сөйләшү булганлыктан, әбекәйгә шактый четерекле сораулар бирәсем килгәнен әйттем. Ул җавап бирергә риза булды. «Әйт әле, син иреңне яратып яшәдеңме?» «Әйе», – дип кистереп-ныгытып әйтте әби. «Сүзең хакмы? Үләргә өч көн кала да ихластан танырга мөмкин мөһим хакыйкать була бит». Беравык тын торгач, әбекәй болай диде: «Юк, мин аны беркайчан да яратмадым. Мин бүтән кешене ярата идем. Тик аңа кияүгә чыгарга ярамый иде». Шуннан соң Мәрҗән әби үз тормышындагы шактый кызыклы киеренке тарихны бәян итте: «Миңа 12-13 яшь чамасында беренче тапкыр әти-әниемнең күзендә шундый курку күрдем: «НКВДчылар кулакларны ауларга килгән. Әлегә олы урамнан баралар, ди. Бөтен нәрсәне талап алалар!» «Кызым, оегың өстеннән тагын бер парны, кофтаңны да икенче кат ки, югыйсә, бөтенесен алып китәчәкләр!» – диделәр миңа. Күзләре, тавышлары курку, каушап-югалып калу белән тулы. Башымдагы кан тамыры бер уй белән тибә башлады: әти-әниемнең котын алырлык нинди куркыныч бәндәләр икән соң алар? Өстемә киенү белән, шулхәтле эссе булып китте, елга булып тир ага башлады. Озак та үтми, ишектә каешлар таккан хәрби киемле абыйлар күренде, берсенең билендә кылыч, галифе чалбарлары, мыеклары, фуражкалары бик нык истә калды. Берсе өстемдәге киемемне тарткалый һәм тупас итеп кычкыра: «Нәрсә кәбестә кебек киендең?!» Өйдәге бөтен нәрсәне җыеп, сыерны да алып киттеләр... Аннары Казакъстанга, Үзбәкстанга юл тотуыбыз... Наманганны хәтерлим, бер кечкенә балчык өйдә тордык, анда бик каты үтәли җил иде. Әти-әнинең кичен, авыр сулап, туган авылны сагынып яшь аралаш сөйләшкәннәре исемдә. Без күп күчеп йөрдек, төрле җирләрдә яшәп торырга кертүләрен сорадык. Мин инде яшь укытучы идем. Бер егет үземә гашыйк булды. Аның белән төрле хәлләр турында туйганчы сөйләшә идек. Тик кайбер нәрсәләргә кагылганда, ул дәшми кала иде. Мин аның әтиәнисе белән яучыларга киләсен белдем, без шул көнне көттек, миңа ак күлмәк тектек. Әни ашарга-эчәргә әзерләп торганда ишек шакыдылар. Мин ачарга йөгердем һәм... Ул НКВД киемендә иде, кулына чәчәкләр тоткан, артында әтисе белән әнисе басып тора. Мин катып калдым, ташка әйләндем, аннары корычтай тавыш белән: «Ычкын моннан! Күземә күренмә!» – дип кычкырдым да ишекне шап иттереп яптым. Сәкегә йөзем белән егылып еларга керештем. Әнием йөгереп килеп җитте: «Ни булды, кызым?!» «Тәрәзәдән кара, барысын да аңларсың». Ул карады һәм миңа кушылып еларга тотынды... Бүтән кешегә кияүгә чыгып, кыз бала тапкач та, егетем, һаман да яратуын һәм көтүен белгертеп, балам белән алырга риза икәнлеген язып, төрле кешеләр аша хатлар җибәрде. Мин әти-әниемнең газаплануын һәм күз яшьләрен кичерә алмадым. Бу хәлләрдән «атлап чыгар» хәлем булмады». Мәрҗән әби берничә көннән бакый дөньяга күчте.

«Ел тамгасы (синдромы)» темасын бөтен тулылыгы, тирәнлеге белән ачу өчен, әле күп вакытлар, күп эзләнүләр таләп ителер һәм барыбер сораулар калыр, дип уйлыйм. Катлаулы мәгълүмат белән укучыбызның башын тагын да әйләндермәс-катырмас өчен, мәкаләмне түгәрәкләп куярга дип, гаилә-нәсел бәйләнешләрен (системаларын) өйрәнүче дөньякүләм танылган психолог-галим Берт Хеллингер сүзләрен кабатлыйм: «Үзенең гаебе (авыртуы) белән күзгә-күз очрашкан-терәшкән кеше генә бу хәлдән көч алырга сәләтле булачак». ■

«СОВЕТ МӘЙДАНЫ» – ТАРИХЫБЫЗНЫҢ ӨЧ ЧОРЫ

Мәйдан уртасына куелган «768 верст» дип язылган багана безне тарихи юл белән таныштыра. Нәкъ менә бирелән Мәскәүне Муром, Казан, Пермь, Екатеринбург, Төмән, Томск, Иркутск калалары аша Кытай белән тоташтыручы, ягъни Европа белән Азияне үзара бәйли торган 9500 чакрым ераклыктагы Себер тракты узган. Бу юл Емельян Пугачев, Себергә сөрелгән каторжаннар, декабристлар һәм аларның хатыннары, атаклы рус язучылары А.Н.Радищев, А.И.Герцен, Н.Г.Чернышевский исемнәре белән дә бәйле. Нәкъ менә хәзерге «Совет мәйданы» җирләре заманында шәһәрнең чите дип саналып, әсирләр Себер юлын җиңелрәк һәм тизрәк узсын өчен, биредә аларның тимер богауларын салдыра торган булганнар.

«Совет мәйданы» узган гасырның урталарында шул исемдәге район оешканда бар-

лыкка килеп, 1962 елда рәсми рәвештә теркәлгән. Иң яңа тарих – 2015 елда биредәге сквер һәм фонтан төзекләндерелде, 400 төп куак утыртылды. Шуның өстенә, тәүлек буе эшли торган видеокүзәтү җайланмалары, Wi-Fi, таксофон да куелды, юллар яктыртылды. Кыскасы, хәзер биредә халыкка ял итү һәм күңел ачу өчен бөтен мөмкинлек тә бар.

Патша Россиясе тарихы, Совет чоры белән иң соңгы казаныш-технологияләрне берләштергән скверны төзекләндерү, Себер трактына һәйкәл – «768 верст» язулы багана кую эше «Таттелеком» АҖнең генераль директоры Лотфулла Нурислам улы Шәфигуллин һәм аның җитәкчелегендәге егетләр ярдәмендә башкарылды. ■

КУКМАРА МИРАСЫ

Киез итекләр иле

Әгәр Кукмараны үзенә күрә бер кечкенә ил дип гоман кылсак, аны, һичбер икеләнүсез, «Киез итекләр иле» дип йөртергә булыр иде.

В.М.ВАВИЛОВ ФАБРИКАСЫ

XIX гасыр ахырында, ягъни 1895 елда Кукмара авылында Алабуга купецы Василий Макарович Вавилов киез итек басу эшен оештырып җибәрә. 1897 елда инде Вавилов фабрикасы ак, кара һәм шома киез итекләр җитештерә башлый. Болардан тыш, фабрикада галошлар, штиблетлар, хатын-кызлар өчен резин ботинкалар, туфлиләр, төрле күн итекләр дә әзерләнә. Елына 280 эш көне булып, фабрикада 25



В.М.Вавилов фабрикасы. XX гасыр башы. Хәзер биредә Кукмараның 4 нче микрорайоны урнашкан

В.М.Вавилов фабрикасының бүгенге көнгәчә сакланып калган бер бинасы

кеше – 20 ир-ат һәм 5 үсмер хезмәт куя. Фабрика үз эшчәнлеген киң җәелдерә. Аның бүлекчәләре Уфа, Чиләбе һәм Алабугада да ачыла. Фабрика җитештергән продукция 1896 елда Түбән Новгородта узган күргәзмәдә яхшы бәя ала, ә Киевта (1897), Санкт-Петербургта (1898) һәм Парижда (1900) узган күргәзмәләрдә исә махсус медальләргә ия була.

1902 елда Василий Макарович Вавилов вафат була. Аның эшен Кукмарада улы Пётр Васильевич дәвам итә. Бертуганы Павел Васильевич исә Уфадагы бүлекчәне җитәкли. Әмма В.М.Вавиловның улларына фабрика эшчәнлеген тиешле дәрәҗәдә тоту насыйп булмый – Уфадагы бурычлар күбәю һәм дөрес идарә итмәү сәбәпле, судка нисбәтле вакыйгалар куера башлый. Фабрикалардагы эшчеләр саны яртылаш кими. Шул ук вакытта бертуган Родигиннар фабрикасында эшчеләр саны бермә-бер арта.

1907 елның 28 маенда Кукмара фабрикасының җитәкчесе Пётр Васильевич Вавилов бакыйлыкка күчә. Шул елның 4 июнендә фабрика идарәсе управляющий итеп В.М.Вавиловның хатыны Александра Степановнаны раслый. Ләкин ул да бөлгенлеккә төшеп барган фабриканы коткарып кала алмый. Шулай итеп, 1909 елның 23 февралендә кайчандыр данлыклы булган фабрика үз эшчәнлеген туктата. Нәтиҗәдә, Вавиловлар фабрикасын бертуган Родигиннар сатып ала.

БЕРТУГАН ВОЙДИНОВЛАРНЫҢ ОСТАХАНӘЛӘРЕ

XIX гасырның 80 нче еллары башында чыгышлары белән крәстиән булган бертуган Войдиновлар киез итек басуга нисбәтле берьюлы ике остаханә ачып җибәрә. Аларның берсенә – Егор Петрович, икенчесенә Алексей белән Михаил хуҗа була.

Егор (Георгий) Петрович Войдинов үзе эшен 1881 елда оештыра. 1887 елда аның остаханәсендә 16 кеше (10 ир-ат һәм 6 үсмер) эшли. 1890 елда остаханәдә 15 мең сумлык 4000 пар итек җитештерелә. 1910 елда исә 100 кеше хезмәте белән 40000 мең сумлык 7000 мең пар киез ката әзерләнә. Эшчеләрнең хезмәт хакы аена 10-25 сум тәшкил иткән. Сүз уңаеннан: узган гасыр башларында яшәү өчен үтә мөһим саналган азык-төлек бәясе мондый: бер ак батон җиде тиен торган, 1 кг арыш оны – алты, 1 литр сөт – 14, 1 кг яңа суелган тавык ите – 80, 1 кг сыер ите – 45, 1 кг балык (җәен) 20 тиен булган. Иң

кыйммәт продукт булып чәй һәм кофе саналган, аларның килосы ике һәм өч сум торган.

Егор Петрович Войдиновның йорты һәм остаханәсе Нурминкә елгасының уң ягында – Зур урамда урнашкан була. Хәзер биредә Кукмараның полиция бүлеге.

1980 елда оештырылган икенче остаханәгә Алексей һәм Михаил Войдиновлар җитәкчелек итә. 1887 елгы мәгълүматларга караганда, аларның остаханәсендә 18 эшче эшләгән. 20 кеше исә үз өендә торып хезмәт куйган. Бар эштә дә кул хезмәте кулланылган. Елына 280 көн эшләп, 4500 сумлык киез итек җитештергәннәр. 1890 елда бертуган Войдиновларның остаханәсендә 25 эшче тарафыннан 13000 меңлек 5000 мең пар киез ката җитештерелгән. Ул елларда киез итекләр киң кулланышта булган. 1900 елда бер пар итек 1 сум 50 тиен торган булса, 1912 елда – ике, 1916 елда исә 12-18 сумга җиткән.

Егор Петрович Войдинов

XX гасыр башында фабриканың хуҗасы булып Алексей Войдинов саналган. Ул үз остаханәсе (хәзерге Ленин урамы, 1 нче йорт) янында урнашкан ике катлы агач өйдә яшәгән. Бу өйгә соңыннан район азык-төлек комбинаты хуҗа була. Хәзер монда «Забава» комбинаты урнашкан.

1917 елда бертуган Войдиновлар да Россиядәге күпчелек фабрикантларның язмышын кабатлый. 1858 елда туган Егор Петрович Войдинов йөзләгән эшчене эшле итеп, туендырып торган остаханәсен 1916 елда яба. 1918 елда үзе теләп Кызыл гаскәргә языла, соңыннан төрле совет берләшмәләрендә тире һәм йон эшкәртү белгече вазыйфаларын башкара. Репрессиягә эләгүе сәбәпле, күрәсең, 1928 елда сайлау хокукыннан мәхрүм ителә. Е.П.Войдиновның уллары төрле совет оешмаларында эшли, кызы Елизавета Кукмарада теш табибы булып хезмәт куя. Соңыннан ул Чуашстанның Канаш шәһәренә күченеп китә.

Е.П.Войдиновның йортында Кукмара район эчке эшләр бүлеге урнаша. 1970 елда йортка икенче кат өстиләр. Бүгенге көндә йортның элекке кыяфәте бөтенләй сакланмаган.

Алексей Петрович Войдинов 1919 елда дәүләт карамагында булган 3 нче киез

Е.П.Войдинов йорты. 1960 елгы фото. Хәзерге вакытта монда Россия Эчке эшләр министрлыгының Кукмара бүлеге урнашкан

Кукмара район полиция бүлеге урнашкан Е.П.Войдинов йорты

итек фабрикасында товаровед булып эшли. Бертуганы Михаилның улы Николайны тәрбияләп үстерә. 1932 елда вафат була. «Пләмәш» Николай Алексеевич (ул хөрмәт йөзеннән Алексей дәдәсенең исемен атасының исеме итеп йөртә) Кукмара хастаханәсендә – хирург, Казанның тимер юлчылар хастаханәсендә баш табиб булып эшли. 1947 елда вафат була. Михаил Петрович Войдинов турында исә, аның берара Родигиннар йортында (хәзер анда туган якны өйрәнү музее урнашкан) яшәве мәгълүм.

ФОТОХӘТЕР

Шамил Әхмәтшин (1954-2017) Универсиадага килгән кунаклар белән. Казан Сабан туе. 2013 ел

Язманы ***Ләбиб Лерон*** *әзерләде.* ■

МАЙ

Фотолар һәм видео beznenmiras.ru сайтында

● 3 майда «Казан утлары» һәм «Безнең мирас» журналларының баш мөхәррирләре Рөстәм Галиуллин һәм Ләбиб Лерон Кукмарада булып, район хакимияте башлыгы Сергей Димитриев белән очрашты һәм аның белән эшлекле әңгәмә үткәрде.

● 3 майда «Казан утлары» һәм «Безнең мирас» журналлары хезмәткәрләре Р.Галиуллин, Л.Лерон, Л.Гобәйдуллин Кукмараның Туган як музеенда төбәкне өйрәнүчеләр, музей хезмәткәрләре, китапханәчеләр һәм мәктәп укытучылары белән очрашты.

«Түгәрәк өстәл» кысасында узган әлеге эшлекле һәм кызыклы очрашу турындагы язма журналыбызның алдагы санында басылачак.

● 3 майда Г.Камал театры бинасында Татарстанның халык язучысы Рабит Батуллага 80 яшь тулу уңаеннан зур әдәби-музыкаль кичә булды.

Милләтебезнең күренекле шәхесләре, әдәбият-сәнгать әһелләре, киң катлам китап сөючеләр катнашында узган кичәне әдипнең уллары Нурбәк белән Байбулат Батулла алып барды.

● 3 майда Казанның Г.Тукай исемендәге Татар дәүләт филармониясе бинасында «Ватаным Татарстан» газетасының 100 еллыгы тантаналы төстә билгеләп үтелде.

● 4 май көнне, каты авырудан соң, шагыйрь һәм прозаик Ринат Гыймазетдин улы Батталов (Ринат Баттал) вафат булды.

Мәрхүм 6 майда Әгерҗе районының Уразай авылы зиратында җирләнде.

● 9 майда Казан урамнары аша «Үлемсез полк» үтте. Чарада Татарстан Республикасы җитәкчелеге белән бергә җөмһүриятебезнең күренекле әдәбият һәм сәнгать әһелләре катнашты.

● 18 майда Казанның «Пирамида» күңел ачу үзәгендә «Бәллүр каләм» бәйгесенең йомгаклау тантанасы булды.

● 20 майда кичке сәгать 6да Казанның Тинчурин мәйданында татар телен яклап митинг оештырылган иде. Митингта язучы-шагыйрьләребез һәм сәнгатькәрләребез Ф.Бәйрәмова, Р.Зәйдулла, В.Имамов, Л.Лерон, Миңгол Галиев, Ф.Гыйләҗев һәм башкалар катнашты һәм чыгыш ясады.

● 21 майда Татарстан Язучылар берлеге идарәсенең чираттагы утырышы булды. Анда Гавриил Державин һәм Саҗидә Сөләйманова исемендәге премияләргә кандидатлар тәкъдим ителде.

● 21 майда бер төркем татар зыялылары шушы көннәрдә генә Казанда фаҗигале төстә вафат булган мәрхүм шагыйрь, әдәбият галиме Әмир Мәхмүдовның җәсәден туган ягына – Башкортстанның Әлшәй районындагы Әбдерәшит авылына озатып калды.

● 22 майда Татарстан Язучылар берлеге рәисе Данил Салихов, «Казан утлары» һәм «Безнең мирас» журналларының баш мөхәррирләре Тукай район хакимияте башлыгы Фаил Камаев һәм Мөслим муниципаль район хакимиятенең аппарат җитәкчесе Азат Әхмәтҗанов белән очрашып сөйләште. ■

Безнең мирас №6 май 2018

Мирасворд

Туку станогы детале

Нәҗип Җиһанов операсы

Туку станогында буй җепне күтәрү-төшерү өчен махсус кыса

... Садриев

Атилла Расих романы

Япониядәге янартау

... Дәүли

Нур, Әхсән

... Зөлкарнәй

Одиссей Ватаны

XIX йөзгә кадәр рус империясендә татар-башкорт морзалары титулы

Тамак, бугаз (диал.)

Ашлык бурасы

Эмиль Золя романы

Ат муенына тагыла торган дүртпочмаклы кыңгырау

Вольтер трагедиясе

Ялган гаеп, гайбәт

Менделеевск районындагы мари авылы

Тәүлекнең бер өлеше

Патша армиясендә кавалерия солдаты

«... хикәяләре» (Ибраһим Салахов)

Борынгы Римда көмеш акча

... Баһман

Әйткән сүздә тору, тугрылык (иск.)

Драматург Гамир ...

Перу каласы

Бишташ уйнаганда уенның беренче баскычы

Сугарга дигән көлтәләрне киптерү корылмасы

Чүпрә, камыр башы

Рейн елгасы буйлап шәраб ташу өчен кулланылган җилкәнле судно

Күк йөзе, күк гөмбәзе (иск.)

... юлны якын итеп

Шарсыман бактерия

Борынгы римлыларда ирләр киеме

Гарәп хәрефе

Урта Азия халыкларында шагыйрь-импровизатор, җырчы

Грузиядәге елга

Борынгы грекларда алтын акча

Италиядәге шәһәр

Фатих Кәрим шигыре

Кытай шашкасы

«Рено» моделе

Америка пионеры

5 нче санда дөнья күргән мирасвордның җаваплары:
Сулдан уңга: балкар, Кашшаф, аяз, Җиһанов, йолт, какы, Радик, ошбу, нар, Ык, сыбай, кол, бавырчы, хан, даһи, Биишева, «Яра», ырыс, «Һәнәк», Оша, би, әгәр, Роза.
Өстән аска: Һади, иравыл, Әрә, Борһан, бәк, акинак, ирәбә, Азнакай, Якир, Кояш, баб, кашавыч, Ани, Ив, Рәфыйков, ышкы, Оноре, лыбы, чавыш, Укчы, асаба.

Рәис Габдулла төзеде.

Казанда
Салих Сәйдәшев
һәйкәле

«БЕЗНЕҢ МИРАС»
ЕЛЪЯЗМАСЫ / ИЮНЬ

● **665 ел элек (1353)**

Урта гасыр әдәбияты шагыйре Харәзми «Мәхәббәтнамә» поэмасын иҗат итә.

● **580 ел элек (1438)**

Казан ханлыгы барлыкка килә.

● **100 ел элек (1918)**

15 июньдә «Правда» газетасында Владимир Ленин һәм Мулланур Вахитов имзалары белән Хөкүмәт исеменнән «Барлык мөселман хезмәт ияләренә мөрәҗәгать» басыла.

Мөрәҗәгатьтән: «Кадерле иптәшләр, әгәр дә сезнең авыр газаплар белән туып килүче Татар-Башкорт Совет Республикасы гражданнары буласыгыз килә икән, әгәр дә сезнең күңелләрегезнең өмете милионнарча җәберләнгән һәм изелгән халыкларның изге өметләре белән бергә бара икән, мөселман Социалистик Армиясенең Кызыл Байраклары астына ашыгыгыз!»

● **95 ел элек (1923)**

17 июньдә тарихчы Шамил Мөхәммәдъяров (1923-2005) дөньяга килә.

● **90 ел элек (1928)**

Һади Такташ Әстерханга сәяхәт кыла. Бу сәяхәте хакында шагыйрь «Кызыл Татарстан» газетасында (29 июнь) «Сагынылган җырләрдә» исемле язмасын бастыра.

● **85 ел элек (1933)**

Галиәсгар Камал (1879-1933) вафат була.

● **70 ел элек (1948)**

«Совет әдәбияты» журналында Кави Нәҗминең «Язгы җилләр» романы басыла башлый.

● **65 ел элек (1953)**

Татарстан Республикасының Мәдәният министрлыгы оештырыла.

● **55 ел элек (1963)**

24-30 июньдә Казанда казакъ әдәбияты атналыгы уздырыла.

● **50 ел элек (1968)**

23 июньдә татар совет шагыйре Әнвәр Давыдов (1919) вафат була.

● **45 ел элек (1973)**

21 июньдә Чаллы шәһәренең яңа урамына Г.Тукай исеме бирелә.

● **25 ел элек (1993)**

25 июньдә башкалабыз Казанның М.Горький урамындагы 13 нче йортта Салих Сәйдәшев музее ачыла.

Журналга ***Айдар Закиров*** *әзерләде.* ■

СОДЕРЖАНИЕ. ИЮНЬ 2018

В мире останется слово моё…: Фаннур Сафин
Историческое наследие: «Нурсултан». О.Иванова; «Татары на пути прогресса». И.Тагиров; «Шыгырдан». П.Салихов; «Платок – украшение женщины». Т.Шайхнурова; «Деревня Мансурово»; «Суфии Кулатки». И.Сафин; «Периодическая печать в Татреспублике». А.Рахим.
Тюркский мир: «Любимый поэт узбекского народа»; «Codex cumanikus» – тюркское наследие». И.Гафаров.
Религиозное наследие: «Исламский мир». Г.Ибрагимов.
Литературное наследие: «Аяз Гилязов и я». Ф.Кутлу; «Советы на вес золота». Р.Ахунзянова; «Соловей». Г.Галиев; «Известный учёный». Р.Ганиева; «Абай». З.Рамиев.
В глубине памяти: «В памяти, до сих пор в памяти!»
Художественное наследие: «Немного о себе». Р.Шарафи; «Памяти Рашита Вагапова».
На страже памяти: «Национальная библиотека Республики Татарстан»; «Семья – язык символов и знаков на фоне рода». Ф.Набиуллин; «Советская площадь – три эпохи нашей истории»; «Страна валенок».

Журнал регулярно освещает все значимые события в жизни нашей нации.

CONTENT. JUNE 2018

There are left my words in the world: Fannur Safin.
Historic heritage: «Nursultan» by O.Ivanova; «Tatars are on the headway»; by I.Tagirov; «Shigirdan» by P.Salikhov; «The woman's attire is kerchief» by T.Shaykhnurova; «Mansurovo village»; «Sufis of Kulatka village» by I.Safin; «The mass media in Tatarstan» by G.Rakhim.
Turkic world: «The precious poet of the Uzbek people»; «Codex cumanikus» is the Turkic world's heritage» by I.Gafarov.
Religious heritage: «Islamic world» by G.Ibragimov.
Literary heritage: «Ayaz Gilyazov and me» by F.Kutlu; «To the advice that worth its weight in gold» by R.Akhunzyanova; «Nightingale» by G.Galiev; «Authoritative scholar» by R.Ganieva; «Abay» by Z.Ramiev.
From the deepest storage of memory: «Keeping in mind, still keeping!».
Creative heritage: «Something about myself» by R.Sharafi; «To the memory of Rashit Vagapov».
On the guard of the memory: «The National library of the Republic of Tatarstan»; «Family is the language of symbols and signs on the background of clan» by F.Nabiullin; «The Soviet Square is three epochs of our history»; «The felt-boots country».

The magazine constantly brings to light all the most important events of our nation life.

«Карт алмагач төбендә».
Киндер, майлы буяу. 1978

«Татарның борчусыз дөньясы».
Киндер, майлы буяу. 1995

Шамил Шәйдуллин

1947 елның 1 августында Тәтеш районының Берлек авылында туган. Казан сәнгать училищесын (1968), И.Е.Репин исемендәге Ленинград сәнгать институтын (1974), Казанда Русия сәнгать академиясенең иҗат остаханәсен (1980) тәмамлый. Татарстан сынлы сәнгате тарихына портрет, натюрморт, пейзаж һәм темалы картиналар ясау остасы булып керде.

Татарстанның халык рәссамы (1997), Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе (1991), Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты (2000).

«Басудан кайту».
Киндер,
майлы буяу.
1987

АЛДАГЫ САНДА УКЫГЫЗ:

Курган өлкәсенең Әлмән районындагы Өчкүл авылы мәчете

Эчкен татарлары. Рафаил Исакаев

Казан ханлыгы. Булат Хәмидуллин
Гәүһәршад. Ольга Иванова
Бакыр бабай.
Чуашлар. Зариф Бәшири
Эчкен татарлары. Рафаил Исакаев
Икшермә чиркәве. Гөлүсә Закирова
Катай авылы һөнәрчеләре. Таһир Кәримов
Бер хатирә. Зәки Зәйнуллин
«Түгәрәк өстәл»: Хуҗахәсән – керәшен авылымы?
Генерал Мәхмүд Гәрәев

ИНДЕКС:
ТАТАРСТАНДА – 54132 (П-2343)
РОССИЯДӘ – 70275
www.beznenmiras.ru

***«БЕЗНЕҢ МИРАС»* журналына башкача язылу:**
• *www.uslugi.tatarstan.ru сайты ярдәмендә*
• *редакциядә*
• *www.tatpodpiska.ru сайты ярдәмендә электрон версия*

4 612750 670172

*«**БЕЗНЕҢ МИРАС**» журналын башкалабыз Казандагы «Книги-Китаплар» кибетеннән (Бауман ур., 19 һәм 29/11), «ТАТМЕДИА» бинасының китап кибетеннән (Декабристлар ур., 2), республикабыз киоскларыннан сатып алырга мөмкин.*